## БУ САНДА


### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Бәширова И.Б.* Төрки-татар язма әдәби теле нәзарияте: Фатих Әмирхан әсәрләре теле үзенчәлекләрен өйрәнү мәсьәләсенә карата . . . 7

*Миңнуллин Б.К.* XX гасыр башы татар газетасында аналитик жанрлар . . . 20

*Мирхәев Р.Ф.* XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләре телендә хәл фигыль формалары . . . 27

*Денмөхәммәтова Э.Н.* Хәзерге татар шигъриятендә синонимнар . . . 38

*Миргалимов И.Ф.* Татар телендә *пространство* концептының вербальләшү үзенчәлекләре . . . 44

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Марцин Байко.* Тадеуш Мицинский хатларында ислам, төрекләр һәм татарлар . . . 48

*Хәлиуллина А.Г.* Әдәбият галиме Суфиян Сафуановның әдәби-тәнкыйди эшчәнлеге . . . 59

### ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВКА – 130

*Харрасова Р.Ф.* «Яңа театр эстетикасы» тәҗрибәләреннән: Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» драмасы . . . 65

*Габидуллина Ф.И.* Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы: жанр үзенчәлекләре . . . 74

*Минһаҗева Р.Ә.* Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәренең беренче вариантына бер караш . . . 80

*Абдуллина Д.М.* Суфиян Поварисовның иҗат хәзинәсе һәм Г. Ибраһимов мирасын өйрәнүдәге эшчәнлеге . . . 91

*Хәбибуллина Л.Г.* Галимҗан Ибраһимов әсәрләре телендә аныклаулы мөнәсәбәт бирелеше . . . 96

*Әхмәтова Д.И.* Сынлы сәнгатьтә Галимҗан Ибраһимов образы . 99

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Ситдиков А.Г., Кәримов И.Р.* Татарстан Фәннәр академиясе А.Х. Халиков исемендәге Археология институтының 2016 елдагы фәнни эшчәнлегенең төп нәтиҗәләре турында . . . . 104

### ВАСИЛИЙ РАДЛОВКА – 180

*Ф.Й. Йосыпов.* В.В. Радлов – Россиянең күренекле тюркологы . 112

### МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Максимов Н.В.* Татар телен чит тел буларак укыту мәсьәләсенә карата . 127

*Чугунов А.С.* Инглиз теле дәресләрендә инглиз һәм татар мәкальләрен куллану . . . 133

## ТАБИГАТЬ ФӘННӘРЕ

*Рәхимов И.И., Шәмсевәлиева Э.Ш.* Татарстан шәһәрләре шартларында йорт хайваннары һәм доместикация (кыргый җәнлекләрне өйдә асрау) проблемалары . . . . . . . . 139

*Миңнуллина Л.Ф., Шәйдуллина Э.Р.* Антимикроб матдәләргә каршы торучанлык: таралу сәбәпләре һәм механизмнары . . . . 144

*Миңнуллина Л.Ф., Мәрданова А.М.* Morganella morganii бактерияләрнең гемолитик активлыгы . . . . . . . . . . . . . . . . 149

## СӘНГАТЬ

*Айдаров Н.Җ.* Җәүдәт Айдаровның блокада эпопеясы Шәһәр-фронттан хатлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155

## ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР

*Сәгъди Габдрахман.* Зур әдипләребездән берсе (аның 20 еллык хезмәте уңае белән) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168

*Нигъмәти Галимҗан.* Галимҗан Ибраһимовның әдәби хезмәтенең егерме елы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172

## ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН

*Москвина А.Р.* Әстерхан татарлары авыл өйләренең декоратив бизәлеше *(Әстерхан өлкәсенең Идел буе районына оештырылган экспедиция материаллары буенча)* . . 177

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Галимуллин Ф.* Тукай фәне тантанасы . . . . . . . . . . . . . . . . . 183

*Сибгатуллина Ә.Т.* Муса Акъегетзадә һәм Йосыф Акчура хезмәтләренең төрекчә яңа басмалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189

*Хәмидуллин С.* Гайнетдинов Айдар. Арча районы эпиграфик истәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

## В НОМЕРЕ

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Баширова И.Б.* Теория тюрко-татарского письменно-литературного языка: к вопросу изучения языковых особенностей произведений Фатиха Амирхана . . . . . . . . . 7
*Миннуллин Б.К.* Аналитические жанры в татарской газете начала XX века . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
*Мирхаев Р.Ф.* Формы деепричастия в языке татарской просветительской прозы конца XIX – начала XX века . . . . . . . 27
*Денмухамметова Э.Н.* Синонимы в современной татарской поэзии . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
*Миргалимов И.Ф.* Особенности вербализации концепта *пространство* в татарском языке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44

### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Марцин Байко.* Ислам, турки и татары в письмах Тадеуша Мицинского . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
*Халиуллина А.Г.* Литературно-критическая деятельность Суфияна Сафуанова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59

### ГАЛИМДЖАНУ ИБРАГИМОВУ – 130

*Харрасова Р.Ф.* Из опыта «Эстетики нового театра»: драма Г. Ибрагимова «Новые люди» . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
*Габидуллина Ф.И.* Роман Г. Ибрагимова «Молодые сердца»: жанровые особенности . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
*Мингазова Р.А.* Взгляд на первый вариант произведения Г. Ибрагимова «Судьба татарки» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
*Абдуллина Д.М.* Творческое богатство Суфияна Поварисова и его деятельность в изучении наследия Г. Ибрагимова. . . . . . 91
*Хабибуллина Л.Г.* Выражение пояснительных отношений в произведениях Галимджана Ибрагимова . . . . . . . . . . 96
*Ахметова Д.И.* Образ Галимджана Ибрагимова в изобразительном искусств . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99

### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Ситдиков А.Г., Каримов И.Р.* Об основных итогах работы Института археологии им. А.Х. Халикова АН РТ в 2016 году . . 104

### ВАСИЛИЮ РАДЛОВУ – 180

*Юсупов Ф.Ю.* Знаменитый тюрколог России В.В. Радлов . . . . 113

### НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Максимов Н.В.* К вопросу обучения татарскому языку как неродному . 127
*Чугунов А.С.* Использование татарских и английских пословиц на уроках английского языка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133

## ЕСТЕСТВЕННЫЕ НАУКИ

*Рахимов И.И., Шамсувалеева Э.Ш.* Домашние животные и проблемы доместикации в условиях городов Татарстана . . . . 139

*Миннуллина Л.Ф., Шайдуллина Э.Р.* Устойчивость к антимикробным веществам: причины и механизмы распространения . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144

*Миннуллина Л.Ф., Марданова А.М.* Гемолитическая активность бактерий Morganella Morganii . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149

## ИСКУССТВО

*Айдаров Н.Җ.* Блокадная эпопея Ж.К. Айдарова. Письма из города-фронта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Сагди Габдрахман.* Один из наших крупных литераторов (к 20-летию его деятельности) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168

*Нигмати Галимджан.* Двадцатилетие литературного труда Галимджана Ибрагимова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172

## ПО СЛЕДАМ ЭКСПЕДИЦИЙ

*Москвина А.Р.* Декоративное оформление сельского жилища астраханских татар *(по материалам экспедиции в Приволжский район г. Астрахани)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 177

## НОВЫЕ КНИГИ

*Галимуллин Ф.* Триумф тукаеведения . . . . . . . . . . . . . . . . . 183

*Сибгатуллина А.Т.* Новые издания трудов Мусы Акъегетзаде и Йусуфа Акчуры на турецком языке. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189

*Хамидуллин С.* Гайнутдинов Айдар. Эпиграфические памятники Арского района . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194

УДК 811.512.145

***И.Б. Бәширова***

# ТӨРКИ-ТАТАР ЯЗМА ӘДӘБИ ТЕЛЕ НӘЗАРИЯТЕ
## Фатих Әмирхан әсәрләре теле үзенчәлекләрен өйрәнү мәсьәләсенә карата

В статье ставится вопрос рассмотрения творчества татарского классика, известного литературного критика и публициста Фатиха Амирхана (1886–1926), как одного из звеньев в истории татарского литературного языка.

**Ключевые слова:** история татарского литературного языка, творчество Фатиха Амирхана.

Бу мәкаләдә классик әдип, танылган тәнкыйтьче, күренекле публицист Фатих Әмирханның (1886–1926) иҗатын татар әдәби теле тарихының бер баскычы буларак карап өйрәнү бурычы куелды. Әлеге юнәлештә түбәндәге мәсьәләләргә игътибар итү зарур: 1) әдипнең үз чоры әдәби теле мәсьәләләренә карата мөнәсәбәтен һәм бу юнәлештәге эшчәнлеген күзаллау; 2) Ф. Әмирханның төрле жанрда (хикәя, повесть, роман, нәсер, драма) иҗат ителгән сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә сүз белән сурәт ясау осталыгын билгеләү; 3) Ф. Әмирханның публицистик мәкаләләренең тел үзенчәлеген башка стильдәге әсәрләре белән чагыштырып анализлау һ.б.

Ф. Әмирхан һәм башка классик әдипләребез иҗат итә башлаган XIX гасыр ахырыннан XX йөзнең беренче чирегенә кадәр, иске язмачылыкка ия булган (старописьменные языки) төрки-татар әдәби теле V–X гасырларда гомумтөрки, XI–XIII йөзләрдә Идел буе төрки әдәби теле (Болгар төркисе), XIII–XV йөзнең беренче яртысына кадәр, кыпчак-татар әдәби теле (Алтын Урда төркисе), XV–XVI йөзнең беренче яртысына кадәр, Казан ханлыгында – иске татар әдәби теле (Казан төркисе), XVI гасыр уртасыннан Россия дәүләтендә классик иске татар теле (Урта Идел буе төркисе) дигән һ.б. исемнәр белән атала [Фасеев, с. 812]. Телебез мең еллык гасырларга сузылган язма традициясен саклаганы хәлдә, абруйлы-аристократ һәм халыкчан-сөйләмә вариантлары белән дә параллель файдаланыла һәм һәр төбәкнең үзенчәлеге белән баетыла бара. Төрки-татар теленең үсеш-үзгәрешендәге катлаулы, әмма нәтиҗәле бу дәверне аның алтын чоры дип атарга кирәк. Язма телебез татар халкының тормыш-көнкүрешен алып бару өчен кирәк булган барлык функциональ стильләрне эчenә ала. Ул рухани-дини һәм дәүләти-дөньяви белем бирү мәктәп-мәдрәсәләрендә укытыла; рус теле һәм гарәп вә фарсы телләре белән чагыштырылып, кулланмалар төзүдә файдаланыла. Аның өстендә төрле фән тармаклары тикшеренүләр алып

бара, фәнни хезмәтләр языла; сәнгати тезмә, чәчмә һәм халык авыз иҗаты әсәрләре иҗат ителә. Якын һәм ерак чит илләрдәге кардәш халыклар белән дипломатик мөнәсәбәтләр алып барыла; татар телендә газета басылырга мөмкинлек алу белән публицистиканың төрле жанрлары барлыкка килә. Шулай итеп, татар халкының иҗтимагый-сәяси, әдәби-мәдәни бәйләнеше аның **үз телендә алып барыла.** Язма әдәби телебез төрле жанр-стильләрнең таләбен канәгатьләндерә торган зыялы катлау һәм гади халыкның сөйләм теле вариантларында кулланыла, норма, норма вариантлылыгы, функциональ-социаль һәм функциональ-стилистик вариантларында яши. Татар милли әдәби теле камил дәрәҗәсендә формалашып җиткән була. Ун гасыр буена гарәп теленең графикасы белән язу дәвам ителә. Гарәп-фарсы алынмалары мул файдаланыла һәм катгый рәвештә үз чыганак теле кагыйдәсенә-нормасына буйсындырылып языла. Нәтиҗәдә, бер яктан, тулаем мөселман дөньясы белән, икенче яктан, төрки дөнья белән бәйләнеш-мөнәсәбәт, бергәлек-аңлашу саклана. Гарәп һәм фарсы алынмалары катгый рәвештә үз чыганак теле кагыйдәсенә нигезләнеп язылырга тиеш булганга, графо-орфографик норманың ныклыгын да хасил итә. Төрки-татар сүзләре дә билгеле бер дәрәҗәдә тәртипкә китерелгән иске имля белән бирелә, имля төзәтүләр нәтиҗәсендә норма вариантлылыгы барлыкка килә.

Шул ук вакытларда, **русларга татар теле укытыла башлагач һәм өч гасыр дәвамында** Россиянең икенче функциональ теле буларак файдаланылганда, рус, латин телләренә мөнәсәбәтле язмаларда төрки-татар теле – татарский язык дип тәгаенләнә: «Азбука татарского языка...» (Хальфин С., 1778), «Татарский словарь и краткая татарская грамматика...» (Хальфин С., 1785, 653 битле кулъязма), «Грамматика татарского языка...» (Гиганов И., 1801), «Азбука и грамматика татарского языка...» (Хальфин С., 1809) һ.б.; «...посланы таковы же грамоты одна латинским, другая татарском языке...», – дип белдерелә [Хисамова, б. 75] һ.б. Шулай итеп, дәверләр буена төрле жанр-стильләрдә яшәп килә торган төрки-татар теле азбука-дәреслекләрдә һәм Көнчыгыш дәүләтләре белән арадашлык вазыйфасы үтәгәндә, **татарский язык** дип аерымланып кулланыла башлый. 1303 елда латинча-фарсыча-кыпчакча «Codex Cumanicus» («Коман мәҗмугасы») язма истәлегендә татарча дигән атама кулланылуы билгеле [Мәхмүдев, 1984, б. 520].

Шуның белән бергә, XIX гасыр урталарында, төрле уку йортларында татар теле укытучылары тарафыннан язма телнең көндәлек тормышта файдаланыла торган тел белән бер үк күренеш булмавын һәм аның төрле темага караган текстларда төрлечә кулланыла алуын яктырткан дәреслекләр төзелә. Нәтиҗәдә, дәверләр буена дәвам итүче иске язулы төрки-татар әдәби теленең табигатенә һәм вазыйфасына төшенү, ягъни төрки-татар әдәби теленең нәзариятен-теориясен күзаллау

башлана. Төрки-татар язма әдәби теленең вазыйфасын өйрәнүгә керешү, асылда, язма телне сөйләмә телдән аерып карау зарурлыгына нигезләнә. Неплюев хәрби урта уку йортында татар теле укытучысы М. Иванов, «Татарская хрестоматия» хезмәтенең керешендә «Оренбург краенда кулланыла торган татар теле ике төп (главный) төргә бүленә – сөйләү теле һәм язу яки китап теле» дип, хрестоматиясенең ике бүлегендә ике төргә караган мисаллар китерә. Сөйләү теле дигәндә, мәкаль, әкият, җыр, табышмаклар белән бергә, «...чыгытай сөйләү теле үрнәге булган Әбелгазихан тарихыннан өзекләр»дә кертелүен белдерә. Аңлашылганча, татар теленең сөйләмә һәм язма төрләргә бүленүе нәзари яктан билгеләнә, әмма гамәли яктан төгәллек саклана алмый, чөнки табигый, җанлы сөйләмә телдән мисаллар китерелми. Шул ук уку йортының татар һәм гарәп теле укытучысы С. Кукляшев, татар теле төрки гаиләгә карый, дип белдерә, язма татар телен гади (простой), эш (деловой), гыйльми (ученый) төргә бүлеп карарга мөмкин булуын теоретик нигезли, әмма әлеге бүленешкә туры килгән текстларны сайлап урнаштыруда төгәл тәртип саклана алмый.

Күпьеллык иҗади эшчәнлегенә нигезләнеп, язма телнең сөйләмә телдән үзгә булган асылын К. Насыйри: «Мәдәниятле һәрбер адәмнең ике төрле теле булып, берсе – анасыннан сөт имгән мөддәтдә үгрәнгән теледер. Икенчесе – дәхи бер остазга тәгълимгә бирелгәч, гыйлем вә фән лөгатьләре белән ачылган теледер», – дип, гениаль фикер әйтә [Насыйри, б. 3]. Төрле фәннәрне өйрәнү тәҗрибәсенә нигезләнеп: «...Һәрбер фәннең үзенә махсус истиляхы бардыр вә үзенә махсус теле бардыр, ...лөгать белән истыйлях арасында, әлбәттә, бер галәкә кирәкдер, һичбер мөнәсәбәтсез бер сүзне истыйлях ясап булмый», – дип, һәр фәннең үзенә хас булган истилях-термины булуын белдерә. «Әбүгалисина кыйссасы»н «...гарәп вә фарсы аз белгән адәмләрдән кыйсса вә хикәят укырга ихласы бар кешеләр өчен, халык аңларлык итеп, рус мәмләкәтендәге мөселманлар теленә тәрҗемә кыйлу»ын махсус искәртә. Шулай итеп, гамәли эшчәнлеккә нигезләнеп, язма телнең вазыйфасын, ягъни кемгә нәрсә турында язуга карап (фәнни хезмәтләрдә, әдәби әсәрдә) төрле сүз һәм сүзформалар кулланылырга тиешлеген аңлатып бирә. Тикшерү эше «татар теле» дип бара, төрки төшенчә-термины файдаланылмый, традиция буенча төрки телдә языла торган башлам, рус мәмләкәтендәге мөселманнар теле дип алмаштырыла. Бөек мәгърифәтче-галим К. Насыйри, чордашлары һәм Казан лингвистика мәктәбенең күренекле вәкилләре булган И. Бодуэн де Куртенэ (1845–1929), Н. Крушевский (1851–1887), В. Богородицкий (1857–1941) белән бер үк вакытларда, җанлы сөйләмә телнең язма тел белән тәңгәл күренеш булмавын, ягъни әдәби тел табигатенең үзенчәлеген һәм гамәли, һәм нәзари яктан билгели. Кызганычка каршы, галимнең

бу фикере алга таба үстерелә алмый, безнең көннәргә кадәр дә җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелгән дип әйтеп булмый.

XIX гасырның соңгы елында төрки телне төзәтүгә багышланган беренче «Гыйльми мәҗлес»тә (Уфа, 1899) «Русия төркиләре» дигән атама рәсмиләштерелә, **Казан шивәсендәге төрки үз телемез** дип таныла. Җыелышның сәркатибе Ф. Кәрими беркетмәне яза, унөч пункттан гыйбарәт әлеге карарның беренчесендә мондый юллар бар: «...Русия төркиләре өчен Казан шивәсе лисанын гомуми ителеп кабул итәргә. Төрки тел өчен сарыф вә нәхү хаҗәт, үз телемез төрки вә Казан шивәсе илә язылыр...». «Гыйльми мәҗлес» күрсәтмәләренә нигезләнеп, бер-бер артлы «Сарфы төрки» дигән дәреслек-кулланмалар төзелә.

1905 елда, татар телендә газета чыгарырга мөмкинлек тугач, «Нур» газетасы мөхәрриренең «Нә делдә язармыз?» дигән соравына, «Әлбәттә, Казан делендә» дигән җавап алына. Әмма Гатаулла Баязитов (1846–1911) Казан теле дигән язма телнең бер генә төрле булмавын, К. Насыйри, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими кебек әдипләрнең «...һәр кайусының сүз вә гыйбарә йөреше берберенә башкаракдыр. Бәгъзесе госманлы деленә мәйел идеб, бәгъзесе гарәп вә фарсы күб катнашдырыб язалар. Димәк ки, бер төсле йиңел, асат аңлаешлы бер куелган дел йукдыр... Имде кайсына тотыныйк? Шушы соңгы төрек-госманлы теленәме яки иске татар телемезнеме алайык», – дип, газетага дигән мәкаләне нинди тел белән ничек итеп язарга кирәклекне тәгаенләргә өнди («Нур», 1905, № 4). Аңлашылганча, язма әдәби телнең бер төрле булмавы искә төшерелә, газетага дигән мәкаләнең шуларның кайсысы белән язылырга тиешлеген билгеләргә кирәклек көн тәртибенә куела. Әмма алга таба фикер алышу, әдәби телнең аерым бер стиленең үзенчәлеге турында гына түгел, тулаем әдәби телнең табигатен һәм вазыйфасын билгеләүгә таба юнәлеш ала. «Нур»дан соң айдан артыграк вакыт үткәч чыга башлаган «Казан мөхбире» (1905, 29.10) газетасында тарихчы Г. Әхмәров Г. Исхакыйның «...Әдәби телне үз телемез димен. Үземез сөйли торган телдә язарга тиеш, димен һәм язамын. Минем мәсләгемдә язылган китаплар халык арасында күп таралып, күп укылачак вә халыкка күп файда китерәчәктер» («Нур», 1905, № 8) дигән фикерен хуплап, «...Телемезне сакламасак, гыйлеме дә, телемез дә бетәр, динемезгә дә зарар килер, Польша татарлары мисалында калырмыз... Унбиш-егерме ел гыйлем тәхсил иткән шәкерт вә имамларымыз үзләрен гыйлем вә мәгърифәтле күрсәтер өчен, хатларын күп гарәп, фарсы һәм төрек (госманлы) гыйбарәләре белән тутыралар... Телемезне сакларга вә төзәтергә һәм бу көннән балаларыбызга үз телемезнең нәхү вә сарыфын укыта башларга!», – дип ассызыклый («Казан мөхбире», 1905, № 5).

Әмма аерым укучылар: «Хөрмәте мөхәррир! Зинһар, мөмкин кадәр гарәп, фарсы,

госманлы төрек сүзләрене катыштырмый яза күреңез, гәзитә мәдрәсә түгел, без ничек аңлыйбыз, шул телдә языңыз. Казан телендә яңа гәзитә чыгуына куанып торган идек, сездән үтенәмез, безләрне мәхрүм кылмаңыз», – дип, турыдан-туры газета теленә караган үтенечләрен дә белдерә. Г. Баязитов мондый аңлатма бирә: «...голяма әдибләремездән башка, укый-яза белгән, “ак өстендә кара таныган” халкымыз күбдер. Шулар өчен нә эшләймез? Менә бәхәс шунда иде. Иске аркадашымыз “Тәрҗеман” шивәсендә язуны мәгъкуль күрәдер. Без исә үземезнең “Нур” яза торган тел, татар-төрек шивәсендә язмакны хуш күрәмез. “Казан мөхбире”дәһа ачыграк-кулайрак дип, Казан халкы сөйләшә торган телдә булуны артыграк күрүе аңланадыр» («Нур», 1915, № 15). Авторның татар-төрек дигәндә, традицион төрки-татар телен истә тотуы аңлашыла. «Казан мөхбире»ннән соң бер ай үтүгә басыла башлаган «Фикер» (1905, 26.11) газетасының мөхәррире К. Мотыйгиның: «...гәзитә урам вә гавам телендә язылачакдыр», – дип белдерүен Г. Баязитов, «...нә гүзәл бер фикердер» дип куанып каршы ала («Нур», 1906, № 21). Күпчелек укучыларның таләбе белән, «үзебез сөйләшә торган гавам теле» белән язарга кирәк дигән нәтиҗә ясала. «Фикер» газетасында Г. Тукайның: «Минем уемча, “Тәрҗеман”ның, без татарларга, галәкәсе бөтенләй юкдыр, чөнки, әхвәлән, аның теле безнең телебезгә кире бер Кырым теледер...», – дип башлана торган мәкаләсендә әлеге фикер тасвирый рәвештә тагын да тәгаенләнә: «...“Тәрҗеман” газетасы, ялгыз чапканда, үз койрыгыннан алда килә торган ат шикелле, безнең күзебезгә һаман алда төсле күренә иде. Имде хәмедләр улсын, хәзер мәйданга “Таң йолдызы”, “Вакыт”, “Фикер” шикелле тагы да йөгерек атлар төште. Без “Тәрҗеман”ны шулар скачкасына куеп карадык. Шунда кем алда, кем артта икәнен күрдек» («Фикер», 1906). Г. Тукайның әлеге юлларын язган 1905–1906 елларда безнең телебезгә тәрҗемә итеп бирелгәч кенә аңлашыла торган шигырьләрен иҗат итүе мәгълүм. Димәк, шагыйрь газета теле белән шигырьнең бер үк телдә язылмаска тиешлеген белеп эш иткән. Ләкин Г. Тукайның беренче тәнкыйтьчеләре бу мәсьәләне үзләренчә күзаллый.

Әлеге күпкырлы катлаулы эшчәнлек «Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык» (2015) дигән коллектив монографиянең I томындагы «Фән буларак татар язма әдәби теле тарихы: теоретик мәсьәләләр» дигән гомуми керешендә яктыртылды. Төрлечә исемләнә торган дәүләтләрендә эзлекле рәвештә кулланылышта-хәрәкәттә булып, хәзерге вакытта да яшәвен дәвам итә торган төрки-татар язма әдәби теленең табигате, вазыйфасы, үзенә хас булган төшенчә-терминнары, бай фактик материал нигезендә ныклы системада тикшерелде [Татар әдәби теле тарихы, б. 8–232]. Иҗтимагый-сәяси, әдәби-мәдәни үсеш-үзгәрешләр, «Татар әдәбияты

тарихы»ның томнарына нигезләнеп өйрәнелде. Гомумән, әлеге ике хезмәтнең басылып чыгуы, татар филологиясендә күп кенә мәсьәләләрне яңача яктыртырга ярдәм итәчәк. Бу очракта Фатих Әмирханның үз чоры язма әдәби теленә карата булган мөнәсәбәтен шушы тикшеренүләр яктылыгында куеп карарга тиеш булабыз. «Фатих абый гомере буе татар әдәби теленең үсеше белән кызыксынып яшәде», – дип яза укытучы Сафия Локманова үзенең «Якын күршем» дигән истәлегендә.

Ф. Әмирханның үз чоры язма әдәби теленә карата булган мөнәсәбәтен һәм эшчәнлеген өч нигездә бәяләү урынлы булыр. **Беренчесе** – үз янындагы талантлы шагыйрь һәм язучыларга әдәби телдә иҗат ителгән әсәрләрен дөньяга чыгарырга мөмкинлек бирә торган «Әлислах» газетасын гамәлгә куюы, ягъни журналист-матбугатчы булуы. **Икенчесе** – әлеге басмаларда чагылыш таба торган язма әдәби тел халыкның сөйләмә теленә тәңгәл күренеш булырга тиешлегенә инануы. **Өченчесе** – сәнгатьле чәчмә әсәрне хикәяләүдә яңа теоретик нигезне аңлавы, ягъни куллана торган сүзләрнең шул әсәр эчтәлеге өчен кирәк булган мәгънә белән баетылырга тиешлеген күтәреп чыгуы. Әлеге мәсьәләләргә аерым-аерым тукталып үтик.

**1. Ф. Әмирханның** үз даирәсендәге талантлы шагыйрь һәм язучыларга әдәби телдә иҗат ителгән әсәрләрен дөньяга чыгарырга мөмкинлек бирә торган матбугатчы булуы әдәбиятчылар һәм журналистлар тарафыннан өйрәнелә. Дүрт томлык «Әсәрләр»енең өченче томында филология фәннәре докторы Зөфәр Рәмиев тарафыннан әдипнең публицистикасы тупланып бирелә, бу юнәлештәге эшчәнлеге җентекләп барлана һәм төгәл комментарияләре белән анализлана. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә шәкертләр хәрәкәтендә актив катнашучы, тырышып рус телен өйрәнүче Ф. Әмирхан, Казан шәкертләре тарафыннан оештырылган «Әлислах» комитетында, шул исемдәге атналык газетаның редакторы булып эшен башлый. 1905 елда яшерен рәвештә басыла башлаган «Әлислах» газетасы, «гыйльми, әдәби һәфтәлек гәзитә» буларак, 1907 елның 3 октябрендә рәсмиләштерелә, «Татарның мәгыйшәтен асылыннан сүтеп төзәтергә кирәк», – дигән шигаре белән 1 нче саны басыла. Рәсми мөхәррире һәм нашире Вафа Бәхтияров (1881–1960) булса да, газетаның бөтен җаны, аңа идея юнәлеше бирүче кеше газетаның сәркатибе Фатих Әмирхан була. Күпчелек баш мәкаләләр, фельетон, рецензия һәм мәкаләләр языла. 1909 елның 22 июленә кадәр яшәештә булган газета: «...милли әдәбият һәм эстетик фикерне үстерүгә җитди өлеш кертә, ...шул чорның күренекле шагыйрь һәм әдипләреннән Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Камал, С. Рәмиев, Г. Сәгъдиләр даими чыгыш ясап киләләр», – дип бәяләнә [Хәсәнов, 1984, б. 461]. «Әлислах» газетасына кадәр Ф. Әмирхан үзе тәрҗемә итеп, «Әлгасрелҗәдид» журналында «Париж коммунасы

тарихы» дигән мәкалә-очеркын бастыра (1906, №6, № 8). Мәскәүдә «Тәрбият әл-әтфаль» журналында сәркатип булып эшләгәндә «сабак балаларына махсус әдәби, фәнни вә рәсемле» журналның темасына туры килә торган мәкаләләрен яза (1907, 1.01–1.03). Әдипнең бу эшчәнлеге алга таба да уңышлы рәвештә дәвам ителә һәм бүгенге көннәрдә дә әһәмиятен югалтмаганга күрә, җентекләп өйрәнелә.

2. Ф. Әмирханның **Язма әдәби тел халыкның сөйләмә теленә тәңгәл күренеш булырга тиеш** дигән ышануы, асылда, әдипнең Г. Тукай иҗатына карата язылган беренче тәнкыйть мәкаләләрендә, «Тел мәсьәләсенә бер караш» дигән язмасында (1908) һәм аерым әдәби әсәрләрендә телгә карата әйтелгән фикерләрендә чагылыш таба. Ф. Әмирханның бу юнәлештәге эшчәнлеге, татар язма әдәби теле тарихының бер буыны итеп каралып өйрәнелмәгәнгә, объектив фикер әйтелеп бәяләнә алган дип әйтеп булмый. Әлеге мәсьәләгә җентекләбрәк тукталу сорала.

Академик М. Хәсәнов билдергәнчә, Ф. Әмирханның «...татар тормышындагы иске, консерватив тәртип һәм гадәтләрне фаш итеп, тәнкыйть утына тотарга» дигән [Хәсәнов, 1984, б. 465] теләк-омтылышы, яңа гына чыга башлаган газета журналларда басыла торган ялкынлы публицистикасында һәм әдәби әсәрләрендәге кебек үк, әдәбитәнкыйть мәкаләләрендә дә, әдәби язма телгә карата әйтелә торган фикерләрендә дә дәвам ителә.

Бу хәл Г. Тукайның басылып килә торган җыентыкларына карата язылган мәкаләләрендә ачык күренә. Ф. Әмирхан, «Габдулла Тукаев шигырьләре», 3 нче дәфтәре басылып чыгу уңае белән язылган мәкаләсендә: «...Бу мәҗмугада Габдулла әфәндене халис татарча – һәр татар рәхәтләнеп укырлык язылган бик гүзәл шигырьләре вә халис татар мәгыйшәтеннән алынган тасвирлары янында, **иске төрек теле белән язылып,** гарәпчә, фарсыча, азәрбайҗанча, тагы әллә нәрсәчә телләреннән корылган шигырьләре дә күптер... Габдулла әфәнде кеби табигате шигърияtle кешеләрнең иске вә яңа төрек әдәбияты тәхте тәэсиренә төшеп тә, татар шагыйре урынына-үзләрендән мөтәкәллиф (*кирәксез*) төрекләшкән шагыйрьләр ясаб чыгарулары татар теле вә әдәбияты ноктаи нәзарындан гөнаһдыр. ...гарәп сүзләреннән татарча төзелеп ясалган бәетләрнең татар шигырь мәҗмугасында торулары – бөтенләй урынсыздыр», – дип белдерә. Дөрес, бу төрдәге шигырьләрнең дә «гүзәл чыгуы» искәртелеп үтелә: «Болардан башка төрек әдәбияты тәхте тәэсирендә язылган шигырьләрендә дә Габдулла әфәнде мөстәкыйль вә гүзәл тасвирлар дәреҗ итәдер», – дип, «Хур кызына»дан һәм тагы берничә шигырьдән өзекләр китерелә, кайбер тәрҗемәләренең дә «телләрен истисна белән», ягъни телен искә алмаганда, бәхак (чыннан да) гүзәл чыкканнар, – дип бәяли (Әлислах, 1907, № 9). Ф. Әмирханның икенче мәкаләсендә дә әлеге язмада

чагылыш тапкан фикерләр дәвам итәлә: «Моннан соң Габдулла әфәндедән халис татар телендә язылган озын-озын поэмалар көтәмез. Татар теленең (дикъкать итеңез – төрек түгел!) аз булса да алга атлавы өчен, мотлак куәи шигърияле затларымызның тәсанныгсыз (табигый) татар булып калулары ляземдер» (Әлислах, 1907, 2 февраль). Шулай итеп, Г. Тукайның шигырьләре татар халкының **халис-саф сөйләмә телендә** һәм **иске төрек телендә язылган** дигән фикер мәйданга куела. «Иске төрек теле» дигән төшенчә, гарәп, фарсы, азәрбайҗан телләре белән бергә әйтелгәнгә, әлеге тәгъбирне гомум төрки дигән мәгънәдә аңларга да була. Г. Тукай үзе дә җыентыкларының «...Ул мәнзумат вак-вак диваннарга тәдвин ителеп, төрек-татар галәменең һәр ягына таралган...», – дип язганда, төрек сүзенең тулаем гаилә исеме булган төрки мәгънәсендә кулланылуы аңлашыла. Әмма ничек кенә булса да, иске төрек теле дип язганда Ф. Әмирханның иске төрекне (төркине) татар тормышындагы иске тәртипләрнең берсе дип санап, аңа каршы чыгуы аңлашыла. Академик М. Хәсәнов Ф. Әмирханның бу юнәлештәге эшчәнлеген XX йөз башы татар әдәби тәнкыйтендә халыкчанлык принцибын көн тәртибенә куючыларның берсе дип саный: «...Ул елларда халыкчанлык проблемасы турындагы принципиаль фикер алышулар, кагыйдә буларак, Г. Тукай иҗаты, аның чын мәгънәсендә халыкчан поэзиясенә мөнәсәбәтле рәвештә кузгала. ...Вакытлы матбугатта бер-бер артлы чыгып килгән тәнкыйть мәкаләләрендә, Ф. Әмирхан шагыйрьнең поэзиясендәге халыкчан рухына, аның алдынгы иҗтимагый омтылышларына гаять дәрәҗәдә сизгер һәм игътибарлы булуын күрсәтте», – дип белдерә [Хәсәнов, 1984, б. 472]. Ф. Әмирхан мәкаләләренең максаты – Г. Тукайның поэзиясендә халыкчан рухка сизгер булуы белән беррәттән, шигырьләренең теле сөйләмә телгә тәңгәл булырга, аларны һәр татар рәхәтләнеп укырлык халис-чын татар телендә язылырга тиешлеген искәртүдә.

Ф. Әмирханның чын күңеленнән инанып, изге ният белән әйтелгән һәм үз вакыты әдәбияты-мәдәнияте, язма теле өчен актуаль булган бу фикерләрендә, төрки-татар язма әдәби теле тарихының объектив-дөрес рәвештә чагыла алмавы күтәрелә. **Беренчедән,** Йосыф Хас-Хаҗиб Баласагунлы («Котадгу белек». XI г.), Әхмәд Ясәви (XII г.) дәверләреннән башлап иҗат итүче авторлар әсәрләрен гарәп яисә фарсыда түгел, ә төркидә язам дип искәртә баралар. Мөхәммәдъярның «Нуры содур» поэмасында бу фикер ун мәртәбә кабатлана. Әмма иске төрки телне инкарь итү белән, халык яратып укыган «Кыйссаи Йосыф» (XIII г.), «Кыйсасыл әнбия» (XIV г.) һ.б. әсәрләрне, ягъни татар язма әдәби теленең ун гасырлык дәверен юкка чыгарабыз була. **Икенчедән,** тикшеренүләрдән билгеле булганча, Г. Тукайның Җаек чорындагы шигырьләренең берсе дә төрек телендә язылмаганлыгы мәгълүм. Аларның кайберләре,

иске татар теленең, гарәп-фарсы алынмалары күп кулланыла һәм угыз-төркидән килә торган язма традиция файдаланыла торган абруйлы-аристрократ төркидә, кайберләре сөйләмә-диалекталь сүз һәм сүзформа, сүзтезмәләре әдәбиләштерелеп язылган халыкчан төркидә иҗат ителә [Бәширова И., б. 74–82]. Әлеге үзенчәлекне аңларга тырышмау аркасында, **беренчедән,** алга таба Г. Тукай иҗатын тикшерүчеләр, иске төрек теле дигән төшенчә-атаманы, аерым бер дәүләтнең теле мәгънәсендә кулланалар, нәтиҗәдә, зуррак ялгышларга юл ачыла. Җ. Вәлиди «Мөхәммәдгариф углы Тукаев» дигән хезмәтендә: «...Фатих әфәнде Тукаевның госманлыча язылган шигырьләренең тел җәһәтен яратмый һәм “Шүрәле”, “Алтынга каршы” кеби татарча шигырьләренә бик зур кыйммәт бирә иде», – дип белдерә. Ягъни Ф. Әмирхан мәкаләсендә «иске төрек теле» дигән тәгъбирнең бу мәкаләдә госманлы дәүләтендәге халыкның теле дигән мәгънәсендә тәгаенләнеп кулланылуы аңлашыла. Г. Ибраһимов та шушы ук фикерне кабатлый: «...Тукай кебек шагыйрьләр (башлангыч «Мөхәммәдия» дәвере) байтак вакытлар ярым “Тәрҗеман”, ярым госманлы тәэсирендә бардылар. Ләкин тормышның төбендән табигый рәвештә күтәрелеп килгән халык хәрәкәте әдәбиятны, матбугатны үзенә корал иттерергә тели иде. Боның өчен җанлы халык теле лязем иде». Шулай итеп, Г. Тукайның беренче тәнкыйтьчеләре тарафыннан шагыйрьнең башлангыч чор иҗатына үзенчәлекле рәвештә мөнәсәбәт белдерелә, татар сөйләмә теленә якын итеп, халыкчан телдә язылган шигырьләре санап күрсәтелеп мактала да, **гарәп-фарсы алынмалары мул файдаланылган шигырьләре төрек телендә язылган** дип ассызыклана. Бу төрдәге әсәрләренең кыйммәте, **халыкның сөйләмә теле яктылыгына куеп тискәре бәяләнә** һәм Г. Тукайның беренче шигырьләре госманлы-төрек телендә язылган дигән фикер ныгытыла. Шагыйрьнең иҗаты иске татар әдәби теленең тарихы булуына бәйләп аңлатылмый. Шуның белән бергә, татар әдәби теле тарихын өйрәнеп, беренче мәкаләләрен яза башлаган Л. Җәләй «Тукай телендә фигыльләр» дигән күләмле мәкаләсендә: «...Тукай телен өйрәнү – татар әдәби теле тарихының мәгълүм бер баскычын өйрәнү дигән сүз. Кешелек дөньясы барлыкка китергән культура байлыгын тәнкыйть үтәзеннән сөзеп алмый торып, яңаны төзеп булмый», – дип, шигъри әсәрләрнең телен яңача тикшерергә кирәк булуны күтәрә («Совет әдәбияты», 1938, № 3, б. 59–60). Әмма бу вакытларда әлеге фикер үстерелә алмый. Татар әдәби теленең эзлекле тарихы булырга тиешлек мәсьәләсен тикшерү юнәлеше көн тәртибенә куелмый, чөнки ул татар халкының тарихы бар, аның әдәбиятының, әдәби теленең тарихы бар, дип әйтүчеләр кулга алынып, юкка чыгарыла торган дәвер була. Г. Тукайның башлангыч чор иҗатын госманлы-төрек теле һәм әдәбиятына

бәйләп карау дәвам итә. Ш. Рамазановның «Тукай һәм хәзерге татар әдәби теле» дигән мәкаләсендә: «...Тукай иҗатына кадәр татар поэзиясе һәм татарча художестволы сүз культурасы турында шартлы рәвештә генә сөйләргә мөмкин», «Лексик һәм грамматик нормалар карарлашмады, чуарлыклар артканнан арта барды. Бер яктан, әле «төрки тел» дип аталган борынгы феодализм чорының корама «китап теле» дәвам итсә, икенче яктан, пантюркистлар Волга буе татарларына да, әдәби тел итеп, төрек телен көчләп тагарга маташтылар», – дип, үз чорының әдәби тел өлкәсендәге теориясе аңлатыла. Г. Тукай шигырьләренең теле дә әлеге нигезгә куеп анализлана: «...Тукайның ул чакта әле татар әдәби теле мәсьәләсендә аерым концепциясе дә, нык позициясе дә булмаганлыкны күрсәтә...», – дип, чынбарлыкка туры килми торган нәтиҗә ясала [Рамазанов, б. 58–63].

«Татар әдәби теле тарихын» язу барышында эшнең нәкъ киресенчә булуы күренә. Мөселман дине идеологиясе белән ныгытылып, гыйлемгә-белемгә омтылу фикеренең бөеклеге «Котадгу Белек»тән башлап, «Кыйссаи Йосыф»тан соң гасырлар буена тасвир ителә килеп, XVIII гасыр ахыры – XIX йөзнең беренче яртысында Утыз Имәни, Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки һ.б.ның тезмә әсәрләрендә дәвам ителә. Әлеге авторлар үзләренең әсәрләрен төрки телдә язам дип ассызыклый, укымышлы кешеләргә багышлап, традицион нигезне саклаган хәлдә, гарәп-фарсы алынмаларын мул кулланып иҗат итәләр. Яшь Тукай да Аллаһы Тәгалә, Коръәни-Кәрим сүзләре белән куәтләнеп, гыйлем-мәгърифәтле, затлызыялы булып халыкка хезмәт итүнең зарурлыгы тасвирлана торган шигырьләрен нәкъ шулай яза. Димәк, бу юнәлештә ул яңалык ача дип әйтеп булмый, гасырлар буена гамәлдә булган язма ысулны дәвам итә. Әмма ул аның әчтәлеген киңәйтә: Аллаһыга инану белән башланган фикер милләтне гыйлемле итүнең башка чаралары булуын белдерә торган тасвир белән киңәйтелә [Бәширова И., б. 78]. «Мужик йокысы», «Шүрәле», «Су анасы», «Пар ат» кебек шигырьләре халыкчан сөйләмә һәм авыз иҗаты әсәрләрендә кулланыла торган сүз, сүзформа, сүзтезмәләр әдәбиләштерелеп языла. Төрки-татар әдәби телендә бу юнәлешнең дә Әхмәд Ясәви иҗатларыннан башланып, абруйлы төрки белән гасырлар буена дәвам итеп килүе мәгълүм. Г. Тукайның иҗатыннан күренгәнчә, аның әдәби телгә карата ныклы позициясе дә, концепциясе булуы яхшы аңлашыла. Димәк, Ф. Әмирханның бу өлкәдәге фикерләре, тарих күзлегеннән карaганда, кызганычка каршы, объектив-дөрес юнәлешле булган дип әйтә алмыйбыз.

**3. Ф. Әмирханның әдәби телгә карата булган мөнәсәбәтенең өченчесе** – авторның үзе күргән-белгән хәлләрне турыдан-туры сөйләп бирү генә әдәби әсәр була алмый дигән фикерне күтәрүе; әсәрдә автор сөйләменең «мөхәррирнең үзендән тәгъбир

дип уйлау хата булачакдыр» дип, кулланыла торган сүзләрнең шул әсәр эчтәлеге өчен кирәк булган мәгънә белән баетылырга тиешлеген күтәреп чыгуы. Әдипнең әсәрләрендә әлеге юнәлешнең гамәлгә куелуына башлап игътибар итүче кеше Г. Ибраһимов була: «...Җиңел вә җитез кулдан, җиңел вә оста каләм белән матур, җанлы рәвештә язылган бу җиңел хикәяне мин әдәбият мәйданына чыккан яңа бер хадисә итеп карыйм. ...Безнең бик күп мөхәррирләремез авыр вә үлтереп язалар. ...Анларда буяу аз, анларда действие булмый. Анлар чын мәгънәсендә үлек кыйсса ясап чыгаралар иде. Ә «Хәят»та алай түгел. Монда мөхәррир үзе фәлән вакыйга булганын сөйләп кенә килми, бәлки каһарманнары үзләре сөйлиләр, кунакка йөриләр, театрга баралар, кешеләр илә танышалар, уйныйлар, көләләр, төннәр була, сандугачлар сайрый. Хасил, монда әллә кемнәр хакында кыйсса сөйләнми, бәлки каһарманнар үзләре яшиләр...» [Ибраһимов, б. 57–58]. Г. Ибраһимовның әлеге бер абзацында татар сәнгатьле прозасының 600 еллык үзенчәлекле үсеше күзаллана. Билгеле булганча, чәчмә әсәр укучыга автор тарафыннан хикәяләнеп бирелә. Тарихи планда караганда хикәяләүнең үзгәреш кичерүе күренә. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар прозасында, берсе икенчесенең дәвамы булып барлыкка килә торган өч төрле хикәяләү ысулының хәрәкәттә булуы мәгълүм. **Беренче төр** хикәяләү белән «...әллә кемнәр хакында кыйсса сөйләнә», ягъни «...тәмле-тәмле хикәятләрне риваят кыйлгучылар шу илә риваять кыйлурлар...» дип, автор тарафыннан укучыга шул риваять кабат җиткерелә. Бу юнәлештә К. Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы» (1868), «Кырык бакча» (1880), «Әбүгалисина кыйссасы» (1881), «Фәвакиһелҗөләса фил әдәбият» (1884) әсәрләре, Ә. Уразаев Кормашиның «Кыйссаи Бүз йекет» (1874), «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (1894), Г. Фәизхановның «Тутыйнамә» (1887) әсәрләре һ.б. иҗат ителә. Татар прозасында «кеше сүзен» сөйләп хикәяләү гамәлгә куела. **Икенче төр** хикәяләү – вакыйга турында автор үзе сөйли, ягъни әсәрнең авторы алгы планга чыга, хикәяләүне үз исеменнән, хөрмәтле укучым дип, турыдантуры аңа эндәшеп сүзен башлый, вакыйганың тәртибен (сюжет барышын) билгели, үзенең аңлатмасын бирә бара, төрле чаралар белән уңай һәм кире персонажлар тасвир ителә. Кыйсса сөйләүчеләрдән аермалы буларак, укучыга җиткерелергә тиеш сәнгатьле фикер тарихи-гомумилегеннән котыла, авторның шәхси үз фикере буларак бирелә. Татар прозасында «авторның үз сүзен» сөйләп хикәяләве гамәлгә куела. Әлеге төр хикәяләү Муса Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» романы белән башлана (1886). Бу романның иҗтимагый тормыш шартлары яктылыгына куеп карала һәм прогрессив дип санала торган яңалыклары турында Г. Ибраһимов, М. Гайнуллин, Х. Миңнегулов, Ф. Мусин, А. Хәлим, Р. Мостафин кебек галимнәр һәм язучыларның фикер

әйтүе мәгълүм. Әсәрдә тасвирлана торган вакыйга-хәлләрне укучыга җиткерүдә М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романы белән башланган әлеге яңарыш, билгеле бер үзенчәлекләр белән З. Бигиев, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, Ш. Мөхәммәдов, З. Һади, М. Гафури кебек мәгърифәтче әдипләребезнең иҗатында дәвам иттерелә [Бәширова, б. 7–41). Шуның белән бергә, XX гасырның беренче елларында, татар халкының классик әдипләре күтәрелеп чыга башлый. Г. Исхакый үзенең 1900 елда басылган «Кәләпүшче кыз» хикәясенең «Хөрмәтле укучым» дип башланган керешендә: «...әдәбият нәдән гыйбарәт идекене» аңлату максатыннан болай ди: «...Һәр язылган сүз үз вакыйгаларын тасвир, үз хәлләрен бәян улмаз! Хосусән, мөхәррирләр, шагыйрьләр ни язсалар, кемне тасвир кылмакчы булсалар, шул кеше булып күп сүзләр сөйләрләр һәм сөйләтерләр...». Димәк, укучыга җиткерелә торган фикер, әлегә кадәр языла торган әсәрләрдәге кебек, сөйләүче авторның шәхсән үзенеке итеп кенә түгел, төрле кеше (персонажларның) фикере буларак җиткерелергә дә мөмкин. «Бай угылы» (1903) әсәрендә ул тагын да ачыклана: «Яздыгым романында бай угылларыбызның тәрбияләре нинди идекене вә бу тәрбияләрнең ни дәрәҗәдә зарарлы идекене укучыларымның күз алларына куймак эстәдем. ...Милләтемездә шул мәсьәләне ислях фикере уянмасмы дип, мин шул эшләремезне булдыра алдыгым кадәр күрсәтмәк эстәдем...». Димәк, төп максат булган хәлләрне сөйләп бару гына түгел, аларны гомумиләштереп күз алдына кую, укучыга күрсәтеп бирү (Бәширова И., Фәнни Татарстан, 2016, № 1, б. 9–14). Менә шушы фикер Ф. Әмирханның «Танымаганлыктан таныштык» дигән хикәясенең (1909) «Бер-ике сүз» дип бирелгән керешендә тагын да тәгаенләнә: «Монда очрый торган «мин» кәлимәсен, мөхәррирнең үзендән тәгъбир дип уйлау хата булачакдыр. Хикәя язганда бу тәгъбир, гомум тарафыннан кабул ителгән бер тәгъбир булып, мөхәррирнең үз фикерен күбрәк кертер өчен истигъмал ителәдер» [Хәсәнов М., 1984, б. 57]. Шулай итеп, XX гасырның беренче унъеллыгында, алга таба татар прозасы ничек итеп язылырга тиешлегенең теоретик нигезе эшләнә. Г. Исхакый туган илгә кайтканчы әлеге фикерне Ф. Әмирхан исеме белән башлап китә идек. Хикәяләүнең максаты үзгәртелә: К. Насыйри кыйссаларындагы кебек, билгеле бер хакыйкатьне кабатлап сөйләү дә, «Хисаметдин менла»дагы кебек булган хәлләрне турыдан-туры сөйләп бару да түгел, бәлки, сөйләүдән бигрәк, күбрәк фикер күтәрү. Гамәли яктан исә, шул ук Г. Исхакыйның, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камалның беренче хикәяләрендә, билгеле бер хәлне сөйләү дәвам ителгәне хәлдә, «мөхәррирнең үз фикерен» тирәнәйтү ысулы да яшәеш ала. Сүзләр аерым бер әсәр эчтәлеге өчен генә кирәк булган дәрәҗәдә мәгънәсен катлауландырып кулланыла: Г. Исхакыйның «Остазбикә»се – мулла хатыны һәм буыннарның дәвам

итүен кайгыртучы Ана. Ф. Әмирханның «Хәят»е – чибәр, гүзәл бер кызның исеме һәм аның мәгънәсез тормышы. Ш. Камалның «Уяну»ы, «Буранда» әсәрләренең атамалары да һәм туры, һәм әсәр эчтәлеге өчен киңәйтелгән мәгънәсе белән аңлашыла. Г. Ибраһимовның «Яз башы», «Кызыл чәчәкләр»е, «Тирән тамырлар»ы һ.б. әсәрләре шул ысул белән иҗат ителә. Сүзләр белән **сурәт-образ барлыкка китерелә.** Чәчмә әсәрдәге аерым сүзне тезмә әсәрләрдәге кебек тикшерү зарурлыгы барлыкка килә. Әлеге мәсьәләгә үз вакытында Җ. Вәлиди игътибар итә. Бүгенге көндә дә актуаль булган, әледән-әле бәхәсләр уята торган бу мәсьәләнең теоретик нигезен күзаллауда әдип, тәнкыйтьче Ф. Әмирханның да өлеше зур булган дип әйтә алабыз.

Ф. Әмирханның иҗатын, татар әдәби теле тарихының бер үсеш баскычы итеп карaганда, түбәндәге нәтиҗәгә килергә мөмкин: Ф. Әмирханның журналистлык һәм публицистлык эшчәнлеге, сәнгатьле әдәби әсәрләрнең хикәяләү поэтикасын камилләштерүе үз вакыты өчен дә, аннан соң да табигый-зарури күренеш булып кабул ителә. Яшь шагыйрьләргә һәм әдипләргә әсәрләрен дөньяга чыгару мөмкинлеге киңәя. Татар прозасының киләчәктә ничек итеп хикәяләнергә тиешлегенә теоретик нигез салыну да зарури мөһим эш булып тора.

Ә инде халыкны милләт итеп тота торган язмаларның гасырлар буена дәвам итеп ныгыган традициясен, нигезен, исеме-атамасын инкарь итү, аларны субъектив бәяләргә омтылу һичкайчан уңай нәтиҗә бирмәде, киресенчә, фаҗигагә генә китерде. Әлеге мәсьәләне хәзерге вазгыятьтә бара торган күренешләргә бәйләп карарга да мөмкин. Халыкны милләт итеп тота торган тел, язма тел, дин, гореф-гадәт, җыр-моң кебек күренешләрнең асылын, традициясен саклау зарурлыгы бервакытта да үзенең әһәмиятен югалтмый.

**Әдәбият**

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: дүрт томда. I т.: Хикәяләр (1907–1922). Казан, 1984. Б. 458–474.

*Бәширова И.* Сәнгатьле чәчмә әсәрләр теле: Татар прозасында хикәяләү стильләренең үсеше. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 96 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. V т. Казан, 1978.

*Насыйри К.* Логать китабы: русча-татарча сүзлек. Казан, 1892.

*Рамазанов Ш.* Татар теле буенча очерклар. Казан, 1954. 200 б.

Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма, вариантлылык. ТӘҺСИ, 2015. 1 т. 696 б.

*Фасеев Ф.* Краткий грамматический справочник татарского языка // Татарско-русский словарь. М., 1966. С. 807–863.

*Хисамова Ф.М.* Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – начало XIX вв.). Казань: Мастер-Лайн, 1999. – 407 с.

***Бәширова Илида Басыйр кызы,***
*филология фәннәре докторы,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми тел белеме бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***Б.К. Миңнуллин***

# ХХ ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ГАЗЕТАСЫНДА АНАЛИТИК ЖАНРЛАР

В статье предпринимается попытка систематизации и анализа аналитических жанров татарских газетных текстов начала ХХ в. на примере материалов, опубликованных на страницах газет «Вакыт» и «Борхане таракки». В рассматриваемых газетах чаще всего встречаются такие аналитические жанры, как статья, обозрение, обзор периодической печати и письмо.

**Ключевые слова:** литературный язык, язык газеты, жанры газетного текста, аналитические жанры.

XIX гасыр ахыры – ХХ гасыр башында иске татар язма әдәби теле яңа социаль шартларда кулланыла башлый. Нигездә шигърият, дини-дидактик һәм тарихи әдәбият теле буларак яшәп килгән иске татар язма әдәби теле бу чорда әдәби проза һәм газета мәкаләләрендә кулланыла башлый [Мирхаев, Миннуллин, с. 118; Мирхаев, Гумеров, с. 49].

Билгеле булганча, теге яки бу газета текстының жанрына бәйле рәвештә аның стилистикасы да үзгәрергә мөмкин, бу исә үз чиратында, морфологик һәм лексик үзгәрешләргә китерә торган факт булып санала. Мәсәлән, мәгълүмати жанрларга караган хәбәр (заметка) мөмкин булганча гади тел белән кыска формада языла. Шулай ук мәгълүмати жанрлардан булган репортаж кысаларында исә автор эпитетлар, чагыштырулар кебек стилистик чараларны актив куллана, андагы фикер агышы гадәттә динамик һәм эмоциональ характерда була. Аналитик жанрларга караган мәкаләгә гадәттә эшлеклелек хас, аның авторы реаль фактларга таянып яза. Фикерен җиткергәндә, укучыны ышандыру максаты белән, ул текстның башыннан ахырына кадәр үзенең нәтиҗәләрен раслый торган дәлилләр китерергә тырыша. Газета текстының әдәби-публицистик төренә караган очерк жанрында иҗат ителгән текст исә тел һәм стиль ягыннан әдәби әсәргә якыная [Гуревич, с. 5]. Әлеге үзгәрешләр газета текстында лексик-стилистик һәм грамматик яктан күпкырлылыкның барлыкка килүенә сәбәп булып тора. Шул ук вакытта, галимнәр фикеренчә, иң консерватив стиль булып рәсми стиль, ә иң ачык стиль булып публицистик стиль санала [Бондалетов һ.б., с. 185].

Газета телендә, текстның жанрына бәйле рәвештә, публицистик стиль өчен хас булган характерлы үзенчәлекләрдән тыш, әдәби телнең башка функциональ стильләренең үзенчәлекләре дә чагылыш таба. Мәсәлән, публицистик стильгә хас үзенчәлекләр мәгълүмати (хәбәр, хисап, һ.б.) һәм аналитик жанрларда (аңлатма (комментарий), корреспонденция,

мәкалә, күзәтү (обозрение) һ.б.), сөйләмә стильгә караган үзенчәлекләр мәгълүмати (интервью, репортаж һ.б.), әдәби стиль үзенчәлекләре әдәби-публицистик жанрларда (фельетон, очерк һ.б.), аерым төркем галимнәр тарафыннан мөстәкыйль функциональ стиль буларак карала торган эпистоляр стиль исә аналитик жанрлар төркеменә карый торган хат жанрында очрый.

Әлеге мәкаләдә «Вакыт» (Оренбург, 1906–1918) һәм «Борхане тәрәкъкый» (Әстерхан, 1906–1911) газеталарында басылган материаллар нигезендә XX гасыр башы татар газетасының аналитик жанрларына анализ бирү максат итеп куела. Тикшерелә торган газета текстларында очраган аналитик жанрлар арасында нәкъ менә мәкалә жанрында автор тирән анализга бирелергә мөмкин. Гадәттә мәкаләдә җәмгыять тормышында урын алган теге яки бу иҗтимагый-сәяси, икътисади яисә мәдәни проблема анализлана. Күтәрелә торган проблема чыннан да киң масштабка ия булырга, киң җәмәгатьчелекне кызыксындырырга тиеш. Мәкаләнең төп үзенчәлекләре – текстның ахырыннан башына кадәр бер фикерне чагылдыру, логик дәвамчанлык, максатчан фикер һәм дәлилләр, нәтиҗә һәм тәкъдимнәрнең ачык булуы. Башта текстның авторы тезислар ярдәмендә укучыны төп проблема белән таныштыра, соңыннан, уйланылган ныклы дәлилләр ярдәмендә үз фикеренең һичшиксез иң дөресе булуына ышандырырга тырыша [Бобков, с. 21].

Гадәттә галимнәр берничә төр мәкаләне аерып чыгара: баш мәкалә, теоретик-пропагандистик мәкалә һәм проблемалы мәкалә. Баш мәкалә газетаның конкрет бер санын ачып җибәрә һәм редакциянең сәяси позициясен ачыклап килә. Теоретик-пропагандистик мәкалә ярдәмендә редакция теге яки бу сәяси агымны пропагандалый һәм башка идеология вәкилләренә каршы көрәш алып бара.

Тикшерелә торган газеталарда басылган мәкаләләрнең стиле төгәл билгеләмәләр һәм эзлеклелек белән аерылып тора. Гомумән алганда, мәкалә – тулысынча автор тексты, аның композициясендә, стилистикасында, фактларны аңлатуда, проблеманы куюю алымнарында һәрвакыт автор шәхесенең үзенчәлеге, аның анализлау мөмкинлеге, үз фикерен укучыга җиткерә белүе чагылыш таба. Билгеле булганча, татар газеталары чыга башлаган дәвердә, редакциягә килгән текстлар газета мөхәррире тарафыннан эшкәртелгән, яисә, гомумән редакциягә бәйле булган авторлар төркеме тарафыннан язылган, ягъни текстлар тел ягыннан да, идеологик яктан да конкрет бер калып кысаларына кертелгән. Шунлыктан, бу очракта автор шәхесенең үзенчәлекләре турында түгел, ә бәлки редакция, газета стиле яисә үзенчәлекләре турында сүз алып бару дөресрәк булыр.

«Борхане тәрәкъкый» газетасында басылган проблемалы мәкаләләр арасында илдәге иҗтимагый, сәяси мәсьәләләрне алгы планга чыгаручы, шул

исәптән татар халкына кагылышлы милли һәм дини проблемаларга кагылучы, тирән анализга ия булган иң кызыклы мәкаләләр арасыннан «Гадәләтме? Золымлыкмы?» (1906, № 56), «Мәгыйшәт яхуд инсанларың яшәмәсе» (1907, № 116), «Шәкерд галәме» (1907, № 116), «Ислах хакында» (1906, № 31), «Дәрел әдәбдә сөйләнгән нотык» (1906, № 33) һ.б. мисал итеп китерергә мөмкин. Кызганычка каршы элеге мәкаләләрнең барысының да диярлек авторлары күрсәтелмәгән. Авторлар күрсәтелгән очракта да, еш кына инициаллар яки тәхәллүс кенә куела. Мәсәлән, «Борхане тәрәккый» газетасында басылган «Кавказ вакыйгалары» дип исемләнгән мәкаләдән бер өзекне карыйк: «kafkaz telegramlaryna qarağanda ärmän berlän tatarlar arasyndağy qan tügelüläre haman betmi. äle anda äle monda ärmänlär tatarlarğa tatarlar ärmänlärgä höcüm itep ällä ni qadär qanlar tügälär ällä ni qadär balalarny jätim qaldyryp ällä ni qadär analarny balasyz qaldyralar... üzeŋezneŋ waq töjäk došmanlyqlaryŋyz öčen ällä ni qadär kešelärne qanly jäšlär elatmaŋyz tuqtaŋyz! tuktarğa waqyt» (№ 30, 1906). Әлеге шактый зур күләмдәге мәкаләнең ахырында «Таң» («طاڭ») дигән тәхәллүс куелган.

«Вакыт» газетасына килгәндә, биредә дә җәмгыять тормышының теге яки бу тармагына карый торган мәсьәләләргә багышланган проблемалы мәкаләләр зур урын алып тора. Мәсәлән, «Азеф мәсьәләсе» дип исемләнгән мәкаләне карыйк: «ufa gubernatory bogdanovič, daxiliyä nazyjre pleve wä biek knäz sergej häm bašqa zur kešelär jäšeren politsijagä mäğlüm itelep ütelgänlär» (№ 433, 1909). Әлеге проблемалы мәкаләдә рус революционеры, эсерлар партиясе җитәкчеләренең берсе, Полиция департаментының яшерен хезмәткәре Евно Фишелевич Азеф турында сүз бара. Бу мәкаләнең авторы шулай ук күрсәтелмәгән, ләкин текст ахырында киләсе санда элеге мәсьәләгә карата премьер-министр П.А. Столыпинның фикере басылачагы хакындагы искәрмә бар.

«Борхане тәрәккый» газетасында шулай ук еш очрый торган аналитик жанрларның берсе – күзәтү (обозрение). Күзәтүнең төп максаты – теге яки бу вакыйга турында гомуми караш булдыру. Күзәтү текстын әзерләгәндә автор иҗтимагый тормышның төрле тармакларына хас булган вакыйгалар, фактлар, күренешләр җыелмасы белән эш итә. Күзәтү текстында факт, күренеш яки вакыйга мөстәкыйль рәвештә түгел, ә бәлки бербөтеннең өлешләре буларак карала [Бобков, с. 24].

Бүген галимнәр күзәтү жанрының берничә төрен аерып карый. Гомуми күзәтүләрдә, вакытлы басманың дәрәҗәсенә бәйле рәвештә, конкрет бер вакыт кысалары эчендә дөньяда, теге яки бу дәүләт яки регионда булып узган мөһим вакыйга турында сүз бара. Тематик күзәтүләрдә исә, исеменнән аңлашылганча, җәмгыять тормышының теге яки бу тармагы (мәдәният, икътисад, сәясәт һ.б.) белән бәйле булган вакыйгалар аңлатыла. Халыкара күзәтүләр үз эчендә ике төркемчәгә бүленә: халыкара тематик күзәтүләрдә

дөньяның теге яки бу ноктасында җәмгыять тормышының конкрет бер тармагы белән бәйле проблемалар турында сүз бара, ә халыкара гомуми күзәтүләр исә дөньяның ниндидер бер ноктасында урын алган мөһим бер вакыйга яки күренеш турында булган информацияне чагылдыра.

«Борхане тәрәккъкый» газетасында басылган текстлар арасында, еш кына, халыкара гомуми күзәтүләр очрый. Алар арасында аеруча әһәмияткә ия булганнары «Төркия хәвадисе», «Госманлы хәвадисе», «Иран хәвадисе» дип аталган рубрикаларда тупланган. Рубрика исемнәреннән аңлашылганча, әлеге күзәтүләрдә теге яки бу илдә булып узган мөһим вакыйгалар турында сүз бара. Информацион жанрларга караган хәбәр текстлары да, шулай ук, халыкара вакыйгаларны яктыртырга мөмкин, ләкин халыкара гомуми күзәтүләр, хәбәр текстлары белән чагыштырганда, көчле аналитик төсмергә ия.

Газетада очрый торган күзәтүләргә берничә мисал китерик: «bolğar mäsäläsene müzakärä wä xäl itmäk öčen ljapčevyŋ istanbula göndärelmäsene ğosmanly xökümäte bolğariaja xäbär virmešter» («Госманлы хәвадисе», № 72, 1909); «iranyŋ ämer malijäsene islax öčen ameriqadan maxsus mämur kitereläčäge äwäldä jazylmyš ide» («Иран хәвадисе», № 145, 1911).

Халыкара күзәтүләр еш кына «Вакыт» газетасында да очрый. Шул ук вакытта, «Борхане тәрәккъкый» газетасы белән чагыштырганда, «Вакыт»та халыкара мәсьәләләрне яктыртучы текстларның саны күбрәк, ләкин аналитик характерда булмау сәбәпле, алар барысы да күзәтү жанрына карамый. «Вакыт» газетасында басылган халыкара гомуми күзәтүләргә берничә мисал китерик: «bu hafta avstrija ilä serbija arasynda suğyš başlanuny kötep uzdy... xodağa šöker soŋ kilgän telegramlar beraz tynyčlyq birälär» (№ 433, 1909). Әлеге өзек «Балкан эшләре» дип аталучы күзәтүләр сериясенә карый торган «Сугыш ихтималы» дип исемләнгән текстка карый.

«14 nče ijüldäge suğyšta ispanjullardan giniral pintus ilä ber ničä afitser üterelmešder. aurupalylar bik qurquda. hämmä irlär qorally. jämsez nyq esseleklär xalyqnyŋ ğajräten basa] (№ 495, 1909).

Тикшерелә торган газеталарда, шулай ук, массакүләм мәгълүмат чараларына күзәтү жанрына караган текстлар да очрый. Галимнәр фикеренчә, әлеге жанр рецензия жанры белән охшаш, ләкин, рецензиядән аермалы буларак, таррак өйрәнү объектына ия. Массакүләм мәгълүмат чараларына күзәтү жанрының бүген берничә төрен аерып чыгаралар. Гомуми күзәтү конкрет бер вакытлы басманың аерым бер вакыт кысаларындагы эшчәнлеген чагылдыра. Мондый төр күзәтүләрдә текстларның төп темалары, сәяси-идеологик эчтәлеге һәм басманың әдәби яктан ни дәрәҗәдә формалашкан булуы хакында языла. Нәтиҗә буларак редакция эшчәнлегенә гомуми бәя бирелә.

Тематик күзәтү исә басмада җәмгыять тормышының теге яки бу тармагының ни кадәр

яктыртылуын өйрәнү максатыннан чыгып языла. Әлеге төр күзәтүнең максаты бер яки берничә вакытлы басманың аерым бер вакыт кысаларындагы эшчәнлеген ачыклау, булган җитешсезлекләрне барлау һәм аларны төзәтү юлларын күрсәтүдән гыйбарәт.

Мәгълүмати күзәтү исә бер яки берничә вакытлы басманың иң мөһим дип табылган материаллары турында хәбәр итүне максат итеп куя. Мондый төр күзәтүләрдә укучыга яки башка басмаларга конкрет бер редакциянең теге яки бу мәсьәләне ни рәвешле яктыртуы җиткерелә.

Безнең очракта исә, карала торган жанрны, төгәлрәк итеп әйткәндә, газеталарга күзәтү яисә вакытлы матбугатка күзәтү жанры дип атау дөресрәк булыр. Чөнки мондый төр жанрга караган текстларда бары тик газета-журнал текстлары турында гына сүз бара. Шунысы мөһим, XX гасыр башы татар матбугатына караган газеталардагы күзәтү жанрын, әлеге жанрның бүгенге көн өчен хас булган төре – вакытлы матбугатка күзәтү жанрының кече формалары белән чагыштырырга була. Ике очракта да, редакция укучыга журналистика нигезләре белән бәйле мәгълүматны биреп тормыйча, башка басмалардагы иң кызыклы дип табылган публикацияләр белән таныштыра.

Алга таба «Борхане тәрәккъый» газетасыннан алынган мисалга күз салыйк: «bögelmä öjäze maqtama baš adly awyldan xäbär bireldegenä kürä šul awylnyŋ sadiq isemle ber möselman üzeneŋ möselman kijäüdän ajrylğan qyzyny batrak adly čuaš awylyndağy ber čuašqa alty sum aqča alyp kijäügä birmešter» («Газеталардан. Чуашка кыз бирү», № 28, 1906).

Әлеге текст «Газеталардан» дип исемләнгән рубрика кысаларында басылган. Бу рубрикада күзәтү формасында төрле газеталардан алынган мәгълүмат бирелә. «Борхане тәрәккъый» газетасының 28 нче санындагы әлеге рубрикага кертелгән текстларның икесе генә индивидуаль исем астында бара, бер текст ахырында инициаллар куелган, калган текстларның авторлары күрсәтелмәгән. Әлеге рубрика ахырында китерелгән мәгълүматның «Вакыт» газетасыннан алынганлыгы күрсәтелә.

«Борхане тәрәккъый» газетасының 139 нчы санында «Газеталардан» дип аталучы рубрикада, моңарчы «Тәрҗеман» газетасында Оренбург губернасы мөфтиенең юбилее уңаеннан басылган текст дөнья күрә. Бу хакта текст башындагы кыска аңлатмада әйтелә. Әлеге тексттан бер өзек китерик: «möftineŋ 25 el itkän xezmätläre nidän ğibarätter sualenä bireläčäk cawap mömkin bulğan ešlärder... ärmäni patriklarynyŋ wä jäki rus mitropolitlarynyŋ itä ala torğan xezmätlären kötü mömkin tügelder. bunyŋ waqyty etkäne juq äle. läkin ütkäne dä juq» (№ 139, 1911).

«Вакыт» газетасында вакытлы матбугатка күзәтү жанры шулай ук киң таралыш алган. Әлеге жанрга караган текстлар, шулай ук, «Газеталардан» дип аталган рубрика кысаларында басыла: «bakuda čyğa torğan törki räfiqymyznyŋ feleton qysmynda jazymyz dilemez ikenče ilemez

ğyjnwany astynda bik ciddi mäqalälär näšer iteläder...» («Лисан мәсьәләсе», № 460, 1909).

«Борхане тәрәкъкый» һәм «Вакыт» газеталарында басылган вакытлы матбугатка күзәтү жанрына караган текстлар эчтәлекләре ягынннан шактый аерылып тора. Гомумән, «Борхане тәрәкъкый»да әлеге жанр кысаларында редакциядән кыскача аңлатма белән башка газета текстларыннан күчерелмә бирелсә, «Вакыт» газетасында басылган матбугатка күзәтү жанрындагы текстларның күпчелеге – мөстәкыйль текстлар. Мәсәлән, югарыда мисал буларак китерелгән «Лисан мәсьәләсе» дип аталган текстта теге яки бу вакытлы матбугатта басылган текстның эчтәлеге аңлатыла.

Югарыдагы фикерне дәлилләр өчен «Вакыт» газетасында басылган вакытлы матбугатка күзәтү жанрына карый торган тагын бер текстка күз салыйк: «bakuda ittixad isemle iran mäktäbendä 1 nče wä 2 nče syjnyf šäkertlärendän sajlanğan 23 šäkerttän ber muzyka arkestry täškil ulynačaq... bu xäbärne bakuda čyqmaqta ulan ittifaq gazetasy jazyp näšer ittektän soŋ ittifaqnyŋ ike nomerynda ike keše monyŋ öčen šadlyq ibraz itälär...» (№ 488, 1909). Әлеге өзек «Мөселман мәктәбендә музыка дәресләре» дип аталган мөстәкыйль текстка карый. Бу текстта Бакуда чыккан «Иттифак» газетасындагы мәкалә турында мәгълүмат бирелә, ул мәкаләгә карата «Вакыт» газетасының фикере белдерелә.

«Борхане тәрәкъкый» һәм «Вакыт» газетасында басылган аналитик жанрлар арасында, шулай ук, хатлар жанрын да аерып чыгарырга була. Галимнәр фикеренчә, хатлар жанры XVIII гасырда ук барлыкка килә, Россиядә ул XIX гасырда киң таралыш ала [Бобков, с. 29]. Тикшерелә торган газеталарның материаллары күрсәткәнчә, хатлар жанры татар газеталарында татар вакытлы матбугатының башлангыч чорында ук урын ала.

Танылган рус галиме Е.П. Прохоров фикеренчә, хатлар жанрының төп үзенчәлекләреннән берсе – теге яки бу вакыйга, чара һ.б. турында сөйләү формасы, ягъни авторның адресатка булган мөрәҗәгате. Автор һәм адресат ролендә аерым шәхес, социаль төркем яисә хезмәт коллективы була ала. Хат авторының адресатка юнәлткән аермачык мөрәҗәгате жанрның формасы һәм эчтәлеген билгеләүдә төп роль уйный [Гуревич, с. 258].

Теге яки бу вакытлы басмада дөнья күргән хатның эчтәлеге җәмәгатьчелеккә ачыла, димәк әлеге жанрның кысалары тарая. Хәзер инде бу текст адресант һәм адресат өчен генә әһәмиятле булудан тыш, киң җәмәгатьчелекне дә кызыксындырырга мәҗбүр. Бу – хатлар жанрының мөстәкыйль жанр буларак формалашуында төп шарт булып тора.

«Борхане тәрәкъкый» газетасында, башка аналитик жанрлар белән чагыштырганда, хатлар жанрына карый торган текстлар сирәгрәк очрый, ләкин безнең тикшерүебезне уздыру өчен аларның саны җитәрлек. Мисал өчен, «Тайный циркуляр. Идарәгә мәктүб» дип исемләнгән тексттан

өзек китерик: «möxtäräm möxärir äfände! minem ošbu mäktübemne gazetaŋyzğa jazmyjča qaldyrmaŋyz! 17 nče sintäberdä jäkšänbe kön kič säğat 9 jarymda iptäšem berlän tatarski most berlän zemlanoj most arasyndan uzyp bara idek bez šunda ber jortnyŋ qaršynda tuqtadyq. šul zaman kinättän bezgä qarawylčy berlän gorodovoj kilep... rivalveryn čyğardy da... bu erdän kiteŋez!.. kitmäsäŋez atarmyn dide...» (№ 28, 1906).

«Вакыт» газетасында, «Борхане тәрәкъкый» белән чагыштырганда, хатлар жанрына карый торган текстлар ешрак очрый. Гадәттә алар «Идарәгә мәктүб» рубрикасында басыла. Мәсәлән, «Вакыт» газетасының № 470 санында басылган текстка күз салыйк: «möxtäräm möxärir äfände. gazetaŋyzda tübändäge satyrlarğa uryn birüeŋezne ütenämen. bän orenburg öjäzendä ufa gubernasynda säjäxätemdä bik küp karjalarny wä mäktäplären küzdän kičerdem. orenburg öjäze dürt volostynyŋ cämğyjäte xäjrijä cyjylyšlarynda buldym...» (№ 470, 1909).

Аңлашылганча, «Борхане тәрәкъкый» һәм «Вакыт» газеталарында чагылыш тапкан аналитик жанрлар арасында иң еш очраганнары – мәкалә, күзәтү һәм вакытлы матбугатка күзәтү жанрлары. Хатлар жанры «Вакыт»та актив кулланыла, ә «Борхане тәрәкъкый» газетасында сирәк очрый.

**Әдәбият**

*Бобков А.К.* Газетные жанры: учебное пособие. Иркутск: Иркут. ун-т, 2005. 64 с.

*Бондалетов В.Д., Вартапетова С.С., Кушлина Э.Н., Леонова Н.А.* Стилистика русского языка. Л.: Просвещение, 1982. 286 с.

*Гуревич С.М.* Газета: вчера, сегодня, завтра. М.: Аспект Пресс, 2004. 288 с.

*Мирхаев Р.Ф., Миннуллин Б.К.* Старотатарский литературный язык в конце XIX – начале XX века: функционально-стилистические особенности употребления деепричастия на -ып (-ур) // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота. 2016. № 11, ч. 2. С. 118–121.

*Мирхаев, Р.Ф., Гумеров И.Г.* Система форм существования татарского языка в конце XIX – начале XX вв. // Филология и культура. 2015. № 1 (39). С. 49–54.

Теория и практика советской периодической печати: учеб. пособие для вузов / под ред. В.Д. Пельта. М., 1980. 376 с.

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә.*

***Миңнуллин Бәхтияр Ким улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге мөдире*

УДК 811.512.145'366

***Р.Ф. Мирхәев***

# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ПРОЗАСЫ ӘСӘРЛӘРЕ ТЕЛЕНДӘ ХӘЛ ФИГЫЛЬ ФОРМАЛАРЫ

В конце XIX – начале XX веков в татарской литературе под влиянием европейской культуры формируется новое направление – просветительский реализм, представители которого в своих произведениях обратились к наиболее актуальным проблемам своего времени. Язык данных произведений представляет собой сплав традиционных особенностей, которыми классический старотатарский письменно-литературный язык характеризуются в целом и элементов разговорного языка. Данная особенность наблюдается и в области морфологии, доказательством чего является употребление в языке татарской просветительской прозы деепричастных форм общетюркского, огузско-турецкого и собственно татарского происхождения.

**Ключевые слова:** история татарского литературного языка, старотатарский письменно-литературный язык, язык татарской просветительской прозы конца XIX – начала XX веков, неличные формы глагола, формы деепричастия.

Хәл фигыль, башка затланышсыз фигыль формаларыннан аермалы буларак, сөйләмдә төп эш-хәрәкәтне ачыклап килгән икенче бер өстәмә эш-хәрәкәтне белдерә. Татар теле диалектларында аның унөч формасы кулланыла [Юсупов, с. 122–186]. Хәзерге татар әдәби телендә хәл фигыльнең биш формасы норма буларак аерып чыгарыла: *-п, -а, -гач, -ганчы, -ышлый* кушымчаларына тәмамланган хәл фигыльләр [Татар грамматикасы, б. 290–298; Тумашева, б. 147–158; Хисамова, б. 256–263].

Хәл фигыльнең хәзерге татар әдәби телендә норма буларак кабул ителгән формаларының кайберләренең XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар язма әдәби телендә дә актив хәрәкәттә булуы күзәтелә. Шуның белән бергә, бу чорга караган иске татар язма текстларының тел тукымасын гомумтөрки һәм угыз, аерым алганда госманлы төрек телләре өчен хас булган формалар да тәшкил итә. Татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән күренгәнчә, XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар язма әдәби телендә хәл фигыльнең парадигматик һәм синтагматик мәгънәләре гомумтөрки *-ып (-уб)*, хәзерге татар теленә хас *-а, -гач* һәм төрек теле үзенчәлекләре саналган *-арак, -ынча, -дыкча, -маздан, -кән* формалары белән белдерелә.

***-ып/-еп (-уб/үб кушымчалы) хәл фигыльләр.*** Классик иске татар язма әдәби теленең традицион үзенчәлекләреннән саналган *-ып (-уб)* кушымчалы хәл фигыльләр – XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләре текстларында иң еш кулланылган формаларның берсе.

Сөйләмдә *-ып (-уб)* формасындагы хәл фигыльләр төп эш-хәрәкәт белән вакыт мөнәсәбәтенә кереп, аның белән бер үк вакытта яисә аннан алда башкарылган эш-хәрәкәтне белдерәләр. Татар тел белемендә бу аларның төп мәгънәсе буларак билгеләнә. Моннан тыш, әлеге хәл фигыльләр төп эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен, сәбәбен, максатын, ә аерым очракларда кире шарт мәгънәсен дә белдереп киләләр [Татар грамматикасы, б. 293–295; Тумашева, б. 151–152; Хисамова, б. 258–260].

Төп фигыль белән бер үк вакыттагы эшне белдергән *-ып (-уб)* формасындагы хәл фигыльләр күбрәк аны үтәлү рәвеше ягыннан ачыклыйлар: *Кәндесене* ***забт идүб****, укымайа гәнә чалышыр* [Акъегет, б. 6]. *Мәукыйфнең эчендә вә тышында анда-бунда исламлар* ***сөйләшүб*** *гәзәләр* [шунда ук, б. 42]. *Хикәямездә, зийадә гъад кыйлмаенча, табылган мәктүбне дә* ***тәрҗемә кылуб*** *язамыз* [Бигиев, 1887, б. 7]. *Муса әфәнде бер нәрсә дә җаваб вирмәенчә тәфәккердә* ***тәгаҗҗебләнүб*** *ултырадыр* [шунда ук, б. 10]. *Галиевләрнең бәднамы чыкмасын дийү, Ибраһим Галиев, карчык-акушеркайы* ***алдалаб****, баланың къәтеленә* ***гайрәт кылуб****, баланы «тәмам» кылдырды* [Бигиев, 1890, б. 33]. *Маһруйның әнкәсе, бу сөалә җаваб вирмәенчә, кечек балалардан зиядәрәк тавышла* ***кычкыруб*** *җыгламайа башлады* [шунда ук, б. 38].

Язма текстларда *-ып (-уб)* формасындагы хәл фигыльләр төп эш-хәрәкәтнең үтәлү сәбәбен (а) һәм максатын (ә) белдерү өчен дә кулланылалар:

а) *Кягыды* ***алуб*** *егет зиядәсе илә мәсрур улды* [Акъегет, б. 4]. *Бөйлә аҗы агламагы* ***ишедүб*** *анасы керер* [шунда ук, б. 6]. *Бу сөале* ***ишедүб****, җәмгыятьнең чугысы вә хосусән Бикбулат менла вә Гали бай вә углы бу шәкерд Хисаметдине хараб идәр дийү батинән мәмнун улдылар* [шунда ук, б. 15]. *Муса әфәнденең егладыгыны* ***күрүб****, Нигъмәтулла әфәнде дә битәкать булуб еглыйдыр* [Бигиев, 1887, б. 14]. *Хәдичә туташ да, бу кеби гүзәл мәслихәтне* ***ишедүб****, тәхте къәләмдә тәмам улмаячак кадәр шадланды* [шунда ук, б. 29].

ә) *Гайниҗамал абыстайда сәне күрүб, чыкмакыңы* ***көтүб*** *андан качдым* [Акъегет, б. 67]. *Габденнәсыр әфәнде Казандан – Габдуллиндан туй мәсарифе ичүн акча* ***сораб*** *мәктүб язмыш* [Бигиев, 1887, б. 65]. *Бән дә шул дакика илә үз-үземне забт идә алмадым, вә нә ичүн көлдегемне соравыны көтмәй, берәр төрле шөбһәгә төшмәсүн диб, сәбәбене* ***бәян итмәк улуб*** *Сәлимә туташга дидем ...* [Фәхретдинов, 1899, б. 70].

XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә *-ып (-уб)* формасындагы хәл фигыльләрне авторлар еш кына бер-бер артлы башкарылган эш-хәрәкәтләрне бирү өчен кулланалар һәм әлеге алым күпмедер дәрәҗәдә сөйләмне җанландыра торган стилистик чара булып тора: *Яшь кыз йомшак дүшәгендән* ***торуб****, әтрафа* ***бакуб****, җөмләсе уйкуда улдыкларыны белдекдән соңра*

*лампасыны* ***яндыруб****, каләм-кәгазь* ***табуб,*** *бөйлә мәктүб язды* [Акъегет, б. 37]. *Муса әфәнде илә Нигъмәтулла әфәнде мәҗлесдән ивләренә* ***кайтуб*** *кәлгәч,* ***тәһарәтләнүб****, салаваты гасырла салаваты мәгърибне* ***әда кылуб****, ахшам йиде сәгатьда чәй эчдекләре вакытда политсә* ***кәлүб****, Муса әфәндене* ***арестовайть идүб****, хәбесханәйә* ***алуб*** *китделәр* [Бигиев, 1887, б. 33]. *Җиһангир Агиев, хикайәмезнең героинясе Маһруй кызның гыйрфанына хәйран вә хөсненә* ***гашыйк улуб****, кызы* ***никях идүб*** *алмак* ***фикренә кәлүб****, аталар вә кыз тарафындан разыйлык* ***булынуб****, Җиһангирнең морадына наил вә бәхтийар улдыгы көн – бу кичәдер* [Бигиев, 1890, б. 8].

Аерым очракларда бу чара авторлар тарафыннан әдәби әсәрдәге геройларның хис-кичерешләрен сурәтләгәндә кулланыла: *Маһруй, атәш күзләре илә бүлмәнең стенасы (дивары)ны карарқән, кечек тәрәзәдә улан тимер рәшәткәйе* ***күрүб****, гвоздь зарур улмадыгыны* ***белүб****, котырган кеше кеби* ***гъәҗәлә кылуб****, җебне кулына* ***алуб*** *вә бүлмәдә улан кечек өстәлне тәрәзәнең янына* ***кәлтерүб****, өстенә менүб, җебнең бер тарафыны рәшәткәйә* ***бағлаб****, питләле тарафыны муенына* ***кийүб****, аягы илә өстәлне* ***орып агдаруб****, әҗәлнең кулына* ***дөшүб****, гаять агыр мәшәкатьләрлә җан тәслим кылмайа башлады* [Бигиев, 1890, б. 41].

Моннан тыш, XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә *-ып (-уб)* формасындагы хәл фигыльләрнең кабатланып кулланылу очраклары да теркәлде. Әлеге күренеш мәгънәләре ягыннан бер-берсенә якын торган, ләкин төрле тамырдан булган фигыльләрдә дә күзәтелә. Бу очракта алар *-а/-ә* формасындагы хәл фигыльләрне алыштырып киләләр һәм аларның мәгънәсе интенсивлык, дәвамлылык кебек төсмерләр белән баетыла: *Бәс өч дуст* ***кызышуб-кызышуб*** *сөйләшмәкдә иделәр* [Акъегет, б. 31]. *Ишекләр ачылгач, җәмагать бер-берсене* ***басуб-кысуб,*** *су кеби агылуб, мәхкәмә эченә керә башладылар* [Бигиев, 1887, б. 37]. *Безнең Казан байларының хатынлары, ирләре үлгәндә* ***үкерүб-үкерүб*** *егълаб, иртәге көнендә көлә-көлә яшь кияүгә кидәләр иде...* [Фәхретдинов, 1899, б. 34].

Югарыда күрсәтелгән мәгънәләрдә *-ып (-уб)* хәл фигыле XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләренең тел тукымасын тәшкил иткән барлык функциональ-стиль катламнарында да (әдәби-тасвирлама, публицистик, фәнни) очрый. Биредә ул автор сөйләменең төп үзенчәлекләренең берсе булып тора.

***-а/-, -и/-ый*** **кушымчалы хәл фигыльләр.** Хәзерге татар әдәби телендә *-а* формасындагы хәл фигыльләр, төп фигыль белән белдерелгән эш-хәрәкәтне аның бер үк вакытта яки аннан алда башкарылуы мәгънәсе фонында, башка эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен яисә сәбәбен белдерә һәм, гадәттә, кабатланган хәлдә кулланылалар. Кайбер очракларда алар аны үтәлү вакыты яки максаты ягыннан да

ачыклап киләләр [Татар грамматикасы, б. 295–296; Тумашева, б. 152–154; Хисамова, б. 260–261]. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләре текстларында *-а* формасындагы хәл фигыльләр сирәк очрый. Биредә алар, нигездә, автор сөйләмендә генә кулланылып, башка эш-хәрәкәтне үтәлү рәвеше ягыннан ачыклап киләләләр: *Хисаметдин менла кемсәйә белдермәйүб, гүя гәзмәк нияте илә багчайа чыкды вә мәркум казыкның янына килүб* ***детри-детри*** *вә* ***курка-курка*** *ташны күтәрүб, астда мәктүб табды* [Акъегет, б. 25]. *Хәнифә туташ* ***көлә-көлә*** *кияр* [шунда ук, б. 28]. ***Сөйләшә-сөйләшә*** *яшьләр бер ханә янына йитешүб гарәбәдән төшделәр* [шунда ук, б. 45]. *Анчак берничә кеше урам буенча солы көлтәләр илә* ***шыгырдый-шыгырдый*** *үтәләр* [шунда ук, б. 51]. *Пароход хезмәтчеләренең ашыгуб нәрсә ташулары, ягъмур күрелгәндә ашлык уручыларның* ***йөгерә-йөгерә*** *көлтә җыймакларыны искә төшерә иде* [Фәхретдинов, 1899, б. 14].

Күп кенә очракларда кабатлаулардан котылу өчен *-а* формасындагы хәл фигыльләрнең бер үк җөмләдә *-ып (-уб)* формасындагы хәл фигыльләр белән бергә кулланылуы күзәтелә: *Безнең Казан байларының хатынлары, ирләре үлгәндә* ***үкерүб-үкерүб егълаб****, иртәге көнендә* ***көлә-көлә*** *яшь кияүгә кидәләр иде...* [шунда ук, б. 34]. *Картчыгы исә яшь вакытында абыстайга ир балалар илә берлекдә сабакга* ***йөрүб****, абыстайның чыра* ***күтәрүб*** *дә: «Укыңыз! Үтерермен!..» дигән сүзенә каршы шаян малайларың артдан* ***торуб****,* ***көлә-көлә****: «Һич үтермәз, бу хөкемсез йир дәгел, курыкмаңыз!..» – дигән сүзләрендән* ***гыйбрәт алуб****, һичнәрсә укымамыш иде* [шунда ук, б. 47]. *Уфа, Пермь, Оренбург, Самара губерналарындан жыелмыш улан бу матрослар, хәлләре кадәр садакаларыны Габбас мелланың алдына* ***куйуб****, пароходларына* ***йөгерә-йөгерә*** *кәтделәр* [шунда ук, б. 126].

***-гач-гәч (-кач/-кәч)*** **кушымчалы хәл фигыльләр.** Әлеге хәл фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә еш очрый торган сөйләм теле үзенчәлекләренең берсе булып торалар. Хәзерге татар әдәби телендә мондый формадагы хәл фигыльләр җөмләдә төп фигыльдән алда башкарылган эш-хәрәкәтне белдереп, аны үтәлү вакыты ягыннан ачыклап киләләр [Татар грамматикасы, б. 296–297; Тумашева, б. 154; Хисамова, б. 261–262]. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә дә алар әлеге функцияне башкаралар һәм, нигездә, автор сөйләмендә кулланылалар: *Һәр насыл исә дә, икенче көн бай мәҗлесендә Хисаметдин менла да булынды вә бай анасының үлдегендән соңра кырык кичә кичдеге үзәрә Бикбулат менла Коръәне кәримдән бераз* ***укыгач****, софрайа чәй китерелде* [Акъегет, б. 14–15]. *Икенче мәктүб ирешдекдән өч көн соңра көн урталары* ***кичкәч****, Хәнифә туташ кечек бүлмәдә тирәзә төбендә тегеш тегүб утырыр иде* [Акъегет, б. 27]. *Кичәнең ярылары*

***булгач**, Мохтар мөсафирханәйә кичәләмәгә китде* [шунда ук, б. 33]. *Тәфтишчеләр, швейцардан бу сүзләрне **ишеткәч**, мөсафирә Зөләйханың мәкътүлә булуы сәкез сәгать илә унике сәгать мабәйнендә вакыйгь улдыгыны аңладылар* [Бигиев, 1887, б. 6–7]. *Кофе **тәмам улгач**, Муса әфәнде господин Андреевдән китде* [шунда ук, б. 24]. *Хак катыйль **табылгач**, Муса Салихов хәлас улачак* [шунда ук, б. 52]. *Сәүдә хезмәтләрем **тәмам улгач** вә үзем бөтен-бөтенә **сәламәтләнүб йиткәч**, Казанга кайтырмын* [Бигиев, 1890, б. 17]. *Хатлар да язуб җибәрмә, чөнки мән ике йә өч көн **кәчкәч**, үзем дә хезмәтләр илә Мәскәүгә кидәмен* [шунда ук, б. 18]. ***Таң аткач**, сәгать сәкездә, Маһруйның бүлмәсе ишеге ачылды* [шунда ук, б. 18].

Аерым очракларда *-гач/-гәч* кушымчалы хәл фигыльләр төп фигыльдән аңлашылган эш-хәрәкәтнең үтәлү сәбәбен белдереп киләләр: *Габденнәсыр әфәнде прокурорга бу җавабны **виргәч**, господин Андреев бик шадланды* [Бигиев, 1887, б. 41]. *Бу сүзләрне Муса әфәндедән **ишеткәч**, һәб җәмагать мөтәхәйир улдылар* [шунда ук, б. 45]. *Сатылачак нәрсәләр вә акча **тәмам улгач**, Габделгафур әфәнде ... Мәмәт әфәнде янына тормайа күчде* [Бигиев, 1890, б. 51].

Еш кына *-гач* формасындагы хәл фигыльләр бер җөмләдә *-ып (-уб)* формасындагы хәл фигыльләр белән бергә кулланылалар. Бу очракта алар бер-бер артлы башкарылган эш-хәрәкәтләрне белдереп киләләр. Алда әйтеп үткәнчә, хәл фигыльләрнең бу рәвешле кулланылышы сөйләмдә кабатлаулардан коткара: *Гайниҗамал абыстай кәндесене гаебләмәсенләр ичүн шөйлә игълан итде ки, Хәнифә туташ дүнке көн **килүб**, бераз **торуб**, Хисаметдин менла **чыккач** гаиб улды имеш* [Акъегет, б. 68]. *Господин Шубин күстәрелмеш йиргә **ултыруб** сәламәтлек **сорашкач,** Муса әфәнде кунакны хөрмәтләмәк өчен хадимгә чәй кәлтерергә кушды* [Бигиев, 1887, б. 11]. *Габденнәсыр әфәнделәр **керүб ултыргач**, дүрт-биш дәкыйка кәчдекдән соңра, бер исерек рус чәйханәйә **керүб**, Габденнәсыр әфәнделәрнең өстәлендән бер-ике өстәл аша бер өстәл янына **ултыруб**, чәйханә хадимендән мөскир гаракы таләп идийур* [шунда ук, б. 47]. *Бөйләҗә Мостафа сабакны белүб вә укуб **тәмам иткәч** вә гади улан мәдехне **ишеткәч**, сабах китапларыны махсус йиренә **куйуб**, софра янына **ултыруб**, чәй эчмәйә башлады* [Бигиев, 1890, б. 14–15]. *Кулында улан дүрт-биш сум көмеш акчасыны **хәреҗ иткәч**, ул-бу нәрсәләрне, ата вә бабасы язмыш китаплары сатмайа **башлаб**, көн кәчермәйә дәвам итде* [шунда ук, б. 51]. *Габделгафур нумерәйә **кергәч**, Ибраһим әфәнде, биш данә йөзлек акчалары **чыкаруб**, Мәмәт вә Габделгафурның алдына өстәлгә куйды* [шунда ук, б. 53].

***-кән (икән)* кушымчалы хәл фигыль.** Төрек теле үзенчәлеге саналган *-кән (икән)* хәл фигыле сыйфат фигыль нигезләренә *икән* ярдәмче фигыленең кыскаруы нәтиҗәсендә барлыкка килгән *-кән* кушымчасы ялганып ясала. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы

татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә аның нигездә *-р* кушымчалы сыйфат фигыленнән ясалган формалары кулланыла. Шул ук вакытта биредә әлеге хәл фигыльнең *-мыш* сыйфат фигыле нигезендә ясалган формасы да теркәлде.

*-ркән* кушымчалы хәл фигыль функциясе һәм мәгънәсе ягыннан хәзерге татар әдәби телендәге *-ганда* формасының грамматик синонимы булып тора. Ул җөмләдәге төп фигыльдән аңлашылган эш-хәрәкәтне үтәлү вакыты ягыннан ачыклап килә һәм аның белән бер үк вакытта башкарыла торган процессны белдерә: *Бөйлә **кидәркән** яшь кыз бер дөккяна керде* [Акъегет, б. 20]. *Юлда **кидәрләркән** Әбүзәр бәк Мохтардан сурды ...* [шунда ук, б. 44]. *Хәтта ки бер эт юл аша узмак **истәркән** өлгермәйүб, колясканың көпчәкләре астында калуб уртага йарылуб, эчәкләре һаваны бераз исләтделәр* [шунда ук, б. 52]. *Бу тарика господин Шубин бакышы илә мәзкүр өстәлне дикъкатьлә **тәфтиш идәркән**, өстәл өстендә алтын илә мөзәййән бер револьвер күрде* [Бигиев, 1887, б. 58]. *Господин Шубин илә Иванов номер эченә кергәч, Иванов, кулындан чемодан, мендәрләрне номер идәненә **куяркән**: «Менә бән сезнең кәлүеңезгә кадәр номерне дә арутмадым, җыймадум», – диде* [шунда ук, б. 60]. *Ибраһим әфәнде картчыгы куркытмайа **дәвам идәркән**, өйнең капысыны какмайа башладылар* [Бигиев, 1890, б. 30]. *Бу хәбәрләр һәркайусы хата булырлар дийү, Җиһангир, үз-үзенә тәсалла вирүб, өй эченә **кереркән**, Маһруйның әнкәсе Җиһангирә раст кәлде* [шунда ук, б. 37]. *Мәмәтлә Габделгафур сөйләшүб **утырырларкән**, нумерә ишеге ачылуб, мәгьлүмеңез Ибраһим Галиев керде* [шунда ук, б. 52].

*-мышкән* формасы исә төп эш-хәрәкәт алдыннан башкарылган процессны белдерә, ягъни *-гач* хәл фигылен алыштырып килә: *Гали бай гаиләсе илә чәй эчмәгә **утырмышкән**, Бикбулат менла әфәнде керде* [Акъегет, б. 12].

***-арак/-әрәк* кушымчалы хәл фигыльләр.** Төрек теле өчен хас булган *-арак* хәл фигыле З. Бигиев һәм Ф. Кәрими сәяхәтнамәләренең төп тел үзенчәлеген тәшкил итә. Башка әсәрләрдә ул сирәк кулланыла.

Функциясе һәм мәгънәсе ягыннан *-арак* хәл фигыле билгеле бер дәрәҗәдә *-ып (-уб)* һәм *-а* формаларының грамматик синонимы булып тора. Әлеге хәл фигыльләр җөмләдәге төп эш-хәрәкәт белән бер үк вакытта яисә аннан алда башкарылган процессны белдереп, төп эш-хәрәкәтне үтәлү рәвеше ягыннан ачыклап киләләр: *Бу инчә биле **тамаша идәрәк** менламыз хәйратда калды, мәгыйшәтнең зәхмәтләрене оныдуб үз-үзене онытды* [Акъегет, б. 9]. *Соңра бөйлә хаинләр Русийәдә тәкрар гъәүдәт идүб, диләнҗелек, бәдәлҗелек сәнгате илә әтрафы **гизәрәк**, ... гаять чук әһле исламы йирләрендән, суларындан җөда идүб, хәраб идәрләр* [Бигиев, 1908, б. 12]. *Бән дә тәмам мәмнүниятлә рисаләйе кабул идүб, Волгин җәнабләренең йәд

*галийәләрене **мөсафәхә идәрәк**, соң дәрәҗә сөрүреме, тәшәккератымы бәян итдем* [шунда ук, б. 17]. *Бундан соңра Нева җаддәсендә буйдан-буйа бер **гәзәрәк** Петербургын гәҗә вакытындагы манзарасыны сәер вә тамаша итдек* [Кәрими, 1902, б. 34]. *Агачларыны, юлларыны вә чаерларыны фән вә сәнгать ярдәме илә **тәрбия идәрәк**, өйлә бер хәлә кәтермешләрдер ки, гаҗәиб табигатә вә гарибе халикатә даир нә кадәр ләтафәт күрмәк истәрсәң бурада вардыр* [шунда ук, б. 124–125]. *Иләредәге ир илә хатын, вә артдагы ике кыз һәб үз араларында **сөйләшәрәк**, гаять кибаранә вә әдибанә бер сурәтдә гәзмәкдәләр иде* [Кәрими, 1908, б. 55].

Еш кына *-арак* кушымчалы хәл фигыльнең бер үк җөмләдә *-ып (-уб)* формасы белән бергә кулланылуы күзәтелә. Бу очракта алар бер-бер артлы башкарылган эш-хәрәкәтләрне белдереп киләләр. Әлеге чара җөмләдә бер үк форманың кабатлануыннан коткара: *Мәетәнең тиресенә канәгать кыйлмай, симезлегене **күрүб**, кәндүм бугазладым **диярәк**, Субаш мөселманларына шу мәетәйе **сатуб** йидермеш* [шунда ук, б. 21]. *Билет **алуб,** багажлары **тәслим идәрәк** әшьямызы вагона йирләшдердекдән соңра чук тормады икенҗе ишарәт вирелде* [Кәрими, 1902, б. 4]. *Кәндесе илә **күрешүб,** бәрабәр җамигә **керәрәк** намаз кылдык* [шунда ук, б. 16]. *Сызраньда ике сәгать кадәр **торуб**, башка вагонлара **бинәрәк**, сәгать 7 дә хәрәкәт итдек* [Кәрими, 1908, б. 14]. *Кырымдан дышары **чыкуб**, Русия мәмләкәтләренә **кәләрәк**, рус вә яһүди дилбәрләрене күрдекдә, бунларың әксәре ... әхлаксызлык вә сәфаһәтә, вә дәһа зиядәсенә дучар улыйурлар* [шунда ук, б. 38–39]. *Бән дә һәрбере илә **күрешәрәк**, илтифатларына тәшәккер итдектән соңра, рәфикым Хәмитҗан әфәндейе анлара **тәкъдим идүб** таныштырдым* [шунда ук, б. 56].

***-ынча/-енчә* кушымчалы хәл фигыльләр.** XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә төрек теле үзенчәлеге саналган *-ынча* хәл фигыленең, нигездә, юклык формасы кулланыла. Барлык формасында ул сирәк очрый һәм, төп эш-хәрәкәттән алда башкарылган процессны белдереп, аны үтәлү вакыты ягыннан ачыклап килә: *Маһруй мәктүбне язуб **тәмам иденчә**, хатны Ягъкуб Галиевкә тапшырмак нияте илә карчык да, әлбисә-киемләрене кийүб, тәмам вә мәктүблә өйүдән хоруж әйләде* [Бигиев, 1890, б. 22].

Чыганакларда барлык формасындагы *-ынча* кушымчалы хәл фигыльләр өчен, нигездә, *дәк* һәм *кадәр* бәйлекләре белән кулланылу хас. Бу очракта алар юнәлеш килеше кушымчасын алалар. Әлеге төзелмә төп эшхәлнең вакыт ягыннан үтәлү чиген белдерә һәм хәзерге татар әдәби телендәге *-ганчы* кушымчалы хәл фигылен алыштырып килә: *Абыстай, риҗа идәрмен, менла Хисаметдин шәһәрә **йитешенчәйә дәк** бәне гизлә, кәл, алла разый улсын* [Акъегет, б. 88]. *Шимди исә, хәмелең **тәмам уланчайа кадәр**, күрешергә*

*вакыт булмас, бу кәчәмез ахыргы кәчәдер* [Бигиев, 1890, б. 18].

XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә юклык формасындагы *-ынча* хәл фигыле *-ып (-уб)* хәл фигыленең юклык формасын алыштырып килә. Ул җөмләдәге төп эш-хәрәкәт белән бер вакыт яссылыгында башкарыла торган процессны белдерә һәм аның үтәлү рәвешен күрсәтү өчен кулланыла: *Муса әфәнде бер нәрсә дә **җаваб вирмәенчә** тәфәккердә тәгаҗҗебләнүб ултырадыр* [Бигиев, 1887, б. 10]. *Өчесе дә **сөйләшмәенчә** чәй эчәләр* [шунда ук, б. 15]. *Бән, ..., сүземне **озын кылмаенча**, әхуалемне сөйләдем* [шунда ук, б. 15]. *... сән, абыстай, зинһар, бүген кемгә дә **белдермәенчә** белүб кәлсәнә, ирем кайтмадымы икән?* [Бигиев, 1890, б. 19]. *Әгәр дә мәнем өемдә бала тугдырмыш улса идең, мән ул эшне бер дә **сәтер кыйлмаенча** хөкем хозурында әйтер идем* [шунда ук, б. 35].

Күп кенә җөмләләрдә хәл фигыльнең әлеге ике формасы, сөйләмгә җанлылык кертү максатыннан, бергә кулланылалар: *Бер дәкыйка кәчкәч, старшина, **ашыкмаенча**, борнысындагы күз көзгесене **төзәтүб**, присяжный заседательләрнең иттифакы нә идегене укымайа башлады* [Бигиев, 1887, б. 46]. *Господин Шубин револьверны тоткалаб бакдыгы вакытда кесәсендән бер кисәк балавыз **чыкаруб**, зәкявәт илә, номер эчендә улан әшхаска **белдермәенчә**, мәзкүр балавызга револьверның дуласының очыны **басуб**, револьверның зурлыгыны, биеклегене үлчәб алды* [Бигиев, 1887, б. 58]. *Кич улгач да, күзенә **йокы кәлмәенчә**, ярым кичәйә кадәр хили **фикерләр кылуб**, йокламады* [Бигиев, 1890, б. 40]. *«Йалан буйакчылара» раст кәлмеш арестантның әйтдеге сүзләрне ишедмәмеш кеби улуб, шөбһәдә калсын дийү **тәфәккер идүб**, **туктамаенча**, капыйа тәвәҗҗеһ кылуб бармайа дәвам итделәр* [шунда ук, б. 68].

Аерым очракларда юклык формасындагы *-ынча* хәл фигыльләре киләчәктә башкарылырга тиеш булган, әмма билгеле бер сәбәпләр нәтиҗәсендә тормышка ашмаган эш-хәрәкәтнең киресен белдерү өчен кулланылалар: *Энем, әгәр дә мәхкәмәдә күстәрән язуыгызны кичә бәңа язуб вирмәгән булса идең, Муса Салихов къәтелдә **мәгъйүб улмаенча**, хәлас улыр иде* [Бигиев, 1887, б. 61]. *Мөшфика әнкәем, әгәр сез шимди бу номердә бәнем янымда улсаңыз иде, бәлкем бән үз-үземне **къәтел идмәенчә**, әүвәлге кеби, дөньяда торыр идем* [шунда ук, б. 69].

***-дыкча/-декчә*** **кушымчалы хәл фигыльләр.** XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә төрек теле үзенчәлеге саналучы *-дыкча* хәл фигыле сирәк кулланыла. Ул, нигездә, Р. Фәхретдиннең романнарында һәм Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә очрый.

Чыганакларда *-дыкча* формасындагы хәл фигыльләр өзлексез башкарыла торган яисә кабатланып килә торган эш-хәрәкәтне белдереп, җөмләдәге төп процессны үтәлү вакыты ягыннан ачыклап киләләр: *Заман **кәчдекчә**, мәдәният вә мәгариф*

***тәрәкъкый итдекчә*** *һәр шәй алмашындыгы кеби, сәяхәт мәсьәләсе дәхи пәк чок тәбдил итмешдер* [Кәрими, 1902, б. 2]. *Заман* ***дәгешдекчә*** *зирагать вә тиҗарәт вә сәнәгатьләрең дә ысулы дәгешмешдер* [шунда ук, б. 87]. *Татарларың руслар илә мөнәсәбәтләренә кәленҗә, татарлар,* ***форсат дөшдекчә****, Русияйә һөҗүм илә ягьма вә гарт идәрләр иде* [Кәрими, 1908, б. 42]. ... *тәхсилең* ***артдыкча*** *кечелегең, белегең* ***артдыкча*** *сабырың артсын!* [Фәхретдинов, 1899, б. 5].

Моннан тыш *ул-* ярдәмче фигыленнән ясалган *-дыкча* кушымчалы хәл фигыль авторлар тарафыннан җөмләдәге төп эш-хәрәкәтнең яисә персонажга хас сыйфат-билгеләрнең дәрәҗәсен күрсәтү өчен кулланыла: *Касыйм татарлары буфет, вокзал, гостиница тотмак хосусында* ***улдыкча*** *тәрәккый итмешләрдер* [Кәрими, 1908, б. 26]. *Назыр вә мотагаләсе* ***улдыкча*** *тугрыдыр* [шунда ук, б. 29–30]. *Бунлар чуҗыкларыны укытмак җәһәтенә* ***улдыкча*** *һиммәт вә гайрәт идийурлар* [шунда ук, б. 35].

Еш кына *-дыкча* кушымчалы хәл фигыльләр тартым кушымчалары алган хәлдә иярчен кереш җөмләләр составында кулланыла. Бу – автор тарафыннан әйтеләсе фикергә, эчтәлеккә өстәмә рәвештә ачыклык кертү максатыннан эшләнә: *Ләкин юкарыда* ***дидегемезчә****, халыкның бунлардан хәбәре юк, бәлки һәркем үзе эше илә мәшгуль иде* [Фәхретдинов, 1899, б. 17]. *Карга юлбашчы улса, үләксәгә алуб варыр* ***дидекләренчә****, бу кеби хатыннлар үзләренең тәрбиясендә улган мәгъсум балаларны үз эзләренә бастырырлар вә гадәтләренә һәм ияртерләр* [Фәхретдинов, 1899, б. 66]. *Ләкин юкарыда* ***сөйләдегемезчә****, малы-фәләне улмадыгындан Йосыф бабай химаясенә дөшмәге лязим кәлде* [шунда ук, б. 46].

Шуның белән бергә тартым кушымчасы алган *-дыкча/-декчә* хәл фигыленең *-ганчы/-гәнче* формасында кулланылу очрагы да теркәлде: *Менлалар да: «Буны* ***вирдегенчә****, бер түгәрәк бөтен акны виргән булса, яхшы улачак иде», – дия сукрануб кәтделәр* [шунда ук, б. 31].

Юклык формасындагы *-дыкча* кушымчалы хәл фигыль җөмләдәге төп эш-хәрәкәтнең башкарыла алмау сәбәбен белдерә: *Бинаән галәйһи бер-беремезнең табигатьләре вә әхлаклары* ***анлашылмадыкча*** *җавабы катгый вирмәгә мөктәдирә дәгелмен* [Акъегет, б. 26].

***-маздан/-мәздән* кучымчалы хәл фигыльләр.** XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә төрек теле үзенчәлеге саналучы мондый хәл фигыльләр сирәк кулланыла. Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләреннән кала башка язма чыганакларда аның бары тик аерым кулланылыш очраклары гына теркәлде.

Мисаллардан күренгәнчә, *-маздан* формасындагы хәл фигыльләр *әүвәл, мөкатдәм* сүзләре белән бергә кулланылып, төп эш-хәрәкәтне үтәлү вакыты ягыннан ачыклап, аннан соң башкарылачак процессны белдереп киләләр: *Бундан бөйлә*

*машина **кәлмәздән** бер сәгать әүвәл тулы мәүкыйф татар иде* [Акъегет, б. 71]. *Муса Салихов Зөләйхане къәтелдә нахак мәгъйүб улдыгы кеби, бәнем ичүн дә кем булса мәгъйүб улмасын дийү үз-үземне **къәтел кылмасдан** мөкатдәм, ишекне йозак илә биклимен* [Бигиев, 1887, б. 76]. *Сәфәрә **чыкмаздан** әүвәл юл ичүн бәгъзы хәзерлек күрмәк ләзим улдыгы һәркәсә мәгълүмдер* [Кәрими, 1902, б. 2]. *Йаурупада сәрбәстҗә вә һәр шәйе аңлайуб гәзә билмәк вә кәндеңе алдатмамак ичүн франсызҗа, алманҗа, яхуд инглизҗә лисанлардан берене белмәк вә һәр йирә **вармаздан** әүвәл ул йирен харитасына бакуб, рәһнамәсене моталәгә итмәле* [шунда ук, б. 159]. *Мәгълүм заманы **йитешмәздән** мөкатдәм йөк тартдырылмыш ат имгәнүб, эшдән чыкдыгы кеби, **вакыты йитмәздән** мөкатдәм сабак укытдырылмыш бала һәм имгәнүб калмакдадыр* [Фәхретдинов, 1899, б. 12].

Аерым очракларда *-маздан* хәл фигыле аерым сәбәпләр нәтиҗәсендә башкарылмыйча калган эш-хәрәкәтне белдерү өчен дә кулланылырга мөмкин: *Ана деле улган фарсычаны Тыйһранда укуб, соңра Әл-Каһирәгә вармыш, анда исә кызлар дарелфөнүнендә биш ел укымыш; ... ләкин дарелфөнүн тәхсилене **тәмам итмәздән** мөкатдәм Тыйһранга кайтырга мәҗбүр улмыш имеш* [Фәхретдинов, 1899, б. 34].

***-мадан/-мәдән* кушымчалы хәл фигыльләр.** Ф. Кәриминең сәяхәтнамәләрендә, башка мәгърифәтче язучыларның әсәрләреннән аермалы буларак, төрек теле өчен хас булган *-мадан* хәл фигыленең дә кулланылуы күзәтелә. Мәгънәсе ягыннан *-мадан* хәл фигыле *-ып (-уб)* хәл фигыленең юклык формасына туры килә һәм ул җөмләдәге төп-эш хәрәкәтне үтәлү рәвеше ягыннан ачыклап килә: *Без халә вокзал әтрафында нимсә хаммалы илә бер-беремезең сүзене **аңламайадан** вакыт кәчерийуруз* [Кәрими, 1902, б. 61]. *Биш-ун danә алманы вә яхуд тарелкалары (табаклары) һавада сикердүб, һич бересене **дөшермәдән** мәһарәт күстәрийурлар* [шунда ук, б. 79]. *Бер мөддәт бунлар илә **конушмадан** вә **танышмадан** кәлдек исә дә, озын бер тоннель кәчдекдән соңра анасы безә бакуб бер шәй сурды* [шунда ук, б. 143].

Аерым очракларда *-мадан* формасы җөмләдәге төп эш-хәрәкәтнең үтәлү шартын күрсәтү өчен кулланыла: *Бу музәдәге китапларың кәсрәт вә тәнәүвыгы хакында бер фикер әҗмале вирә билмәк ичүн бәгъзыларының исемләрене бурая **язмадан** кәчәмияҗәгем* [шунда ук, б. 45]. *Бу кәрамәтле шәехе **күрмәдән** китмәк асла мөмкин дәгел* [шунда ук, б. 114].

Югарыда әйтеп үтелгәннәрдән һәм китерелгән мисаллардан аңлашылганча, угыз-төрек чыгышлы хәл фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләре теле тукымасының төп үзенчәлеген тәшкил итәләр һәм биредә алар очраклы рәвештә түгел, ә билгеле бер стилистик максатларда кулланылалар.

**Әдәбият**

*Акъегет М.* Хисаметдин менла. Милли роман яки хикәя. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1886. 70 б.

*Бигиев З.* Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә. Роман. Казан: типогр. Г.М. Вечеслава, 1887. 77 б.

*Бигиев З.* Гөнаһе кәбаир. Роман. Казан: типогр. Г.М. Вечеслава, 1890. 72 б.

*Бигиев З.* Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр). Казан: типолитогр. И.В. Ермолаевой, 1908. 108 б.

*Кәрими Ф.* Йаурупа сәяхәтнамәсе. Оренбург: типогр. «Вакыт», 1902. 191 б.

*Кәрими Ф.* Кырым сәяхәте. Оренбург: типогр. М.-Ф. Каримова, 1908. 116 б.

*Тумашева Д.Г.* Хәзерге татар әдәби теле. Морфология. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1978. 221 б.

Татар грамматикасы. Т. 2. М.: ИНСАН, Казан: Фикер, 2002. 448

*Фәхретдинов Р.* Сәлимә яки гыйффәт. Гафил бән Габдулла әсәре уларак бер хикәятдер. Казан: типогр. Б.Л. Домбровского, 1899. 80 б.

*Фәхретдинов Р.* Әсма, яки гамәл вә җәза. Оренбург: типогр. М.-Ф.Г. Каримова, 1903. 130 б.

*Хисамова Ф.М.* Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Татар. кит нәшр., 2015. 335 б.

*Юсупов Ф.Ю.* Морфология татарского диалектного языка: категории глагола. Казань: Фэн, 2004. 592 с.

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145'373

***Э.Н. Денмөхәммәтова***

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ СИНОНИМНАР

Умение пользоваться лексическим фондом языка в своем творчестве является одним из основных показателей мастерства писателей и поэтов. В лексико-семантической системе каждого языка и художественном процессе особое место занимают синонимы. В статье анализируются роль и место данных слов в творчестве современных татарских поэтов.

**Ключевые слова:** синонимы, синонимический ряд, язык поэзии, образные средства, татарский язык.

Элек-электән теге яки бу телне камил белү күрсәткечләренең берсе булып, мәгънәдәш сүзләрдән дөрес файдалану саналган. Шунлыктан синонимнарга күп тел белгечләре, язучылар һәм әдәби тәнкыйтьчеләр зур игътибар биргәннәр, әлеге төр сүзләрнең телне баету, фикерне төгәл һәм анык бирүдәге рольләрен күрсәтеп килгәннәр, аларны үз мәгънәсендә, әйтәсе фикерне гади, җыйнак итеп бирерлек формада кулланырга чакырганнар.

Тел белемендә бер яки якын мәгънә белдергән сүзләр синонимик рәтләргә туплап өйрәнелә. Галимнәр фикеренчә, татар телендә синонимик оялар 15 меңнән артып китә. Бу өлкәдә тикшеренүләр күптәннән алып барылса да, өйрәнеләсе, ачыклык кертәсе мәсьәләләр дә кала бирә. Мәсәлән, мәгънәдәш сүзләрнең шагыйрьләр иҗатында тел-сурәтләү чарасы буларак кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү аларның табигатен тулырак күзаллау ягыннан зур әһәмияткә ия.

Т. Галиуллин татар шигъриятен түбәндәгечә тасвирлый: «Хәзерге поэзиянең киң тармаклы һәм күп юнәлешле эчтәлеген иңләве кыен. Тарихи үткән, иҗтимагый мөнәсәбәтләр, туган җиргә, телгә мәхәббәт, кешенең үз-үзен аңлавы, кичерешләр хәрәкәтен ачарга ярдәм иткән табигать күренешләре, тормышны киная белән, үзгәртеп сурәтләү, фәлсәфи гомумиләштерү, акыл һәм физик хезмәтләр белән рухлану, балачакны сагыну, мәхәббәт сагышлары – барысы газиз илһам чыганаклары. Шигърият, берише чорлардагы кебек, Җир шары мәшәкатьләре, атом-төш коралы, галәмне яулау белән масаю, бөек төзелешләр, кара алтынны күбрәк чыгару өчен көрәш кебек татар халкына файдасы нисби гамәлләргә дан җырлау, халыклар дуслыгы турында сафсата сатудан арына бара» [Галиуллин, б. 8]. Г. Афзал, Ш. Галиев, Ә. Баянов, М. Шабаев, И. Юзиев кебек һаман иҗади эзләнүләр рухы белән яшәгән өлкән буынның дөньяда яшәү мәгънәсе турында уйлануларын алтмышынчы елларда поэзиягә язгы ташкындай дәррәү килеп

кереп, сүз-образ өлкәсендә кыю ачышлар ясаган Р. Әхмәтҗанов, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Гаташ, Г. Рәхим дәвам итә, аларга соңрак килеп кушылган Р. Миңнуллин, Р. Вәлиевлар традициясен Г. Морат, Р. Зәйдулла, Р. Сүлти кебек яшьрәк буын авторлар һәм хатын-кыз шагыйрәләр дәвам иттерә, үстерә дип, фикерен дәвам итә галим. Әлеге авторлар укучыга үзләренең хисләрен шигырь аша җиткергәндә синонимнарга еш мөрәҗәгать итәләр. Сөйләмгә, контекстка синонимнар рәте күпчелек очракта тулысынча диярлек килеп керә. Алар я тезеп китү, я каршы кую формасында, яисә төрле тезмәдә яки җөмләдә әле берсен, әле икенчесен файдалану рәвешендә кулланылалар.

Ш. Ханбикова үзенең «Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр» хезмәтендә, синонимнарны тезеп китү төрле максатларда файдаланырга мөмкин, дип яза. Ул аларны якынча унга бүлеп күрсәтә [Ханбикова, б. 48]. Тикшеренүләр үткәргәннән соң, мәгънәдәш сүзләрнең поэзия телендә түбәндәге максатларда ешрак файдаланылулары ачыкланды:

1. Күпмәгънәле сүзнең кайсы мәгънәсендә кулланылуын ачыклау өчен. Бу төр синонимнар шигъри текстларда аеруча еш очрый. Мәсәлән, татар телендә *изү* сүзенең берничә мәгънәсе бар, алар «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә теркәлгәннәр:

изү – I. 1) Каты яки порошок сыман нәрсәне су кушып болгатып, йомшак, сыек яки боламык хәленә китерү; 2) Әйберне зур авырлык астында калдырып басу, яньчү, сыту, таптату, шәкелен бозу; 3) *күч. сөйл.* Бик каты, хәлдән тайдырганчы кыйнау; 4) *күч.* Йөрәккә авыр булып, борчып, җәфалап, газаплап тору; 5) *күч.* Төрле авырлыклар, дөнья мәшәкатьләре басу, газап чиктерү, хәлдән тайдыру, эштән чыгару; 6) *күч.* Иктисади, сәяси һәм рухи яктан кысу, җәберләү; 7) *күч.сөйл.* Бер үк сүзне кат-кат сөйләү, кабатлау; 8) *күч. сөйл.* Кирәксез, зарарлы эш эшләү, җайланган эшне бозу; 9) *күч. сөйл.* Танымаслык, аңлашылмаслык хәлгә китереп бозу.

II. (Икътисади, сәяси һәм рухи) кысынкылык, җәбер, эксплуатация.

III. 1) Киемдә муен турысында күкрәк авызына таба уелган ерык һәм шул ерыкның һәр ике ягы; 2) *этн.* Татар хатын-кызларының төрле төстәге тасмаларны изү тирәли тегеп, укалар белән чигеп эшләгән, күлмәк якасыннан алып билгә кадәр бөтен күкрәкне каплый һәм бизәнү өчен күлмәк өстеннән киелә торган күкрәкчәсе [Татар теленең..., б. 174].

М. Әгъләмов әлеге сүзне түбәндәгечә файдалана:

*Күпереп торган илне **изү, басу**,*
*Камыр азык ясау дәвам итте…*
*…һәм, ниһаять,*
*Өркетелгән милләт*
*Кимсетелгән милләт…*
*тәпи китте.*
(«Хәтер көне»)

Шагыйрь аның төрле авырлыклар, дөнья мәшәкатьләре басу, газап чиктерү, хәлдән тайдыру, эштән чыгару мәгънәсендә

кулланылганлыгын *басу* фигыле ярдәмендә ачыклап китә.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *кичерү* сүзенең 4 мәгънәсе бирелгән [б. 260]. Түбәндәге мисалда ул *гафу итү* мәгънәсендә кулланылган. Зөлфәт шул рәвешле кичерү фигылен «аныклап» үтә:

*Мин **кичермим**!*
*Мәңге **гафу итмим**!» –*
*Әткәң-әнкәң җыры шул булыр.*
*Татар! Татар! Моны аңлаганчы*
*Вакыт узган булыр, соң булыр!*
(«Соңгы язмыш яры»)

2. Гомумән сүзнең мәгънәсен ачыклау, тулыландыру өчен кулланылган синонимнар. Әлеге очракка да мисаллар еш очрый. Мәсәлән:

*Күрәсезме, әнә шул көрәштә*
*Күзгә карап ил **алышына**.*
***Үзгәрә** бит Татарстан йөзе –*
*Кешеләрнең йөзе үзгәрә.*
(М. Әгъләмов «Татар көрәше»)

*«Әллә нинди дәшмәс йолдыз!» –*
*димсез*
*Янәсе, без шуңа гел ялгыз.*
*Ул нигәдер усал караганда,*
***Пәйда булганбыз** без, **туганбыз**...*
(Зөлфәт «Казык йолдыз»)

*Шул тузанда мин үзем дә*
*торам әле чак-чак басып.*
*Юк, **тайпылмыйм**, **китмим***
***читкә**,*
*тузаным да миңа тансык.*
(Зөлфәт
«Мин үтәсе бу юллардан...»)

Югарыда китерелгән шигырь юлларында синонимнар мәгънә төсмере белән бер-берсеннән аерылсалар да, тулы картинаны күз алдына китерү өчен, автор тарафыннан уңышлы файдаланылганнар.

3. Чит телдән кергән сүзләргә, терминнарга аңлатма бирү өчен аныклагыч рәвешендә кулланылган синонимнар. Авторлар алынмаларны кулласалар да, аларның шигырьләрдә синонимлашуы юк дәрәҗәсендә. Ә терминнар исә, жанр таләбенә туры китерелеп, бөтенләй кулланылмый.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә француз теленнән кергән *мираж* сүзе түбәндәгечә аңлатыла: мираж – *фран.* 1) Горизонтта күкнең ялган сурәтләреннән яки ялган җир предметларыннан гыйбарәт оптик күренеш; 2) *күч.* Аңда, хыялда тудырылган нәрсә, хыял [б. 367]. Бу лексик берәмлек татар телендә *рәшә* сүзе белән мәгънәдәшлектә тора. Алар икесе дә телдә актив кулланылышта йөриләр һәм шигъри текстларда да урын алалар:

*Мөстәкыйльлек шулай килер дисәк,*
*Бу алдавыч **мираж**, бу – **рәшә**...*
(М. Әгъләмов «Татар көрәше»)

4. Күчерелмә мәгънәдәге образлы сүзнең мәгънәсен ачыклау, ачу өчен тәкъдим ителгән синонимнар. Бу төргә шагыйрьләр иҗатыннан түбәндәге мисалларны күрсәтергә мөмкин:

***Кайный** Казан, **гөрли** Казан,*
*Без нәкъ шуның уртасында.*
*Без – бар! Димәк, сөю яши,*
*Димәк, яшәр бездән соң да.*
(М. Әгъләмов «Без – бар!»)

Автор *кайнау, гөрләү* кебек контекстуаль синонимнарны шулкадәр уңышлы файдаланган

ки, күз алдына пар бөркеп кайнаучы казан килә. Ә чынлыкта исә әдип башкалада барган эшхәлләрнең, вакыйгаларның һәм анда катнашучыларның күңел кичерешләрен бирергә тели. Шул рәвешле образ тудыруда синонимнар зур вазифа башкаралар.

Моңа дәлил буларак түбәндәге шигъри юлларны да китерергә мөмкин:

*Мин **янам**,*
*    **шатланам**,*
*        **газапланам**,*
*гаҗәп түгел – дөнья бу!*
*Карап тора миңа күзләр –*
*йөзләрендә тук елмаю.*
(Р. Зәйдулла «Мин янам...»)

Биредә автор лирик геройның күңел кичерешләрен тасвирлау максатыннан төрле мәгънәдәге сүзләргә мөрәҗәгать итә, ләкин контекстта алар арасында мәгънә бәйләнешләре барлыкка килә.

5. Сүзнең билгеле бер мәгънәсенә яки мәгънә төсмеренә басым ясау өчен кулланылган синонимнар. Бу төр – шагыйрьләр тарафыннан шулай ук яратып кулланыла, чөнки хиснең югары ноктасын тасвирлуда уңышлы алым булып санала:

***Рәнҗүләргә**, **әрнү**, **үпкәләргә**,*
***Кимсенүгә** хәтле*
*Тел тидереп сүз әйтүме әллә?*
*Сүз дә мәрхәмәтле.*
(М. Әгъләмов «Сөю булып җиргә алма ява»)

Әлеге синонимнар кеше күңелендә генә була ала һәм саклана торган авыр хис-кичерешләрне тирәнрәк бирү өчен кулланылалар.

6. Нинди дә булса күренешкә тулырак, күләмлерәк характеристика бирү өчен. Бу төргә карый торган синонимнар еш кына парлы сүз буларак та кулланылалар. Алар, нигездә, контекстуаль синонимнардан торалар, ләкин тасвирлау объектын тулаем күз алдына китергән вакытта мөһим роль уйныйлар:

*Син ипләгән, син сипләгән*
*        сүзләр, –*
***Аңлап**, **сизеп**, **тоеп** карасаң, –*
*Якты гомер, утлы күмер икән*
*        ләбаса!*
(Зөлфәт «Шигырьдәш»)

7. Нинди дә булса бер билгене тулырак итеп, төрле яктан ачу өчен. Мәсәлән, Р. Зәйдулла халык күңелендәге рәнҗү хисен түбәндәгечә тасвирлый:

*Кайда соң ул Тукай күргән*
*Без бергә теркәлгән җеп?*
*Гәрәйләрнең сөякләре*
***Хурланып** ята, **рәнҗеп**.*
(«Җеп»)

Алдагы шигырь юлларында исә *ялгыш* төшенчәсе *ачы*, *зур* сыйфатлары ярдәмендә ачыла. Әлеге синонимнар кылынган ялгышның күләмен, көчен тагын да арттыра төшәләр:

*Йокы аралаш төшләренә кереп,*
*И йөдәтә икән бер тавыш:*
*– Йоклау татлы булды синең*
*        өчен –*
*Бу гамәлең **ачы**, **зур** ялгыш.*
(В. Фатыйхов «Рәиснең йокы сәгате»)

8. Сөйләмгә киеренке, тәэсирле, гомумән патетик тон бирү өчен. Бу төркемгә керә алырдай мисалларның да күп булуы

ачыкланды. Мәсәлән, *җанга якын*, *кадерле булган* төшенчәләрне бирү өчен:

***Изге*** *өем минем,* ***газиз***
*Татарстан!*
*Ничә буын инде синдә тапмый*
*җылы,*
*Яки уңга китә,*
*Яки сулга китә –*
*Уңга – сулга китә улларыңның*
*юлы.*
(М. Әгъләмов «Бүген»)

Алдагы мисалда диңгезгә хас сыйфатлар кешегә күчерелеп, аның күңелендә бара торган киеренке хисләрне белдерәләр:

*Сөю тотты да тынлыкны*
*Урлап китте тәмам.*
*Хуш, тыныч яр!*
*Саумы, диңгез!*
***Дөрлим, дулкынланам****.*
(Р. Зәйдулла «Битараф идем...»)

9. Эш, күренеш, процессның дәвамлылыгын, интенсивлыгын күрсәтү өчен. Бу алымнан аеруча М. Әгъләмов оста файдалана:

*Яшәргә килгән буласың*
*Матурлык белән генә,*
*Мәгънәсез Вакыт*
*...****Сындыра****...*
*...****Җимерә****...*
*...****Вата****...*
*...****Бөгә****...*
(«Матурлык безнең белән»)

Бу синонимнар «Синонимнар сүзлеге»ндә түбәндәге тәртиптә бирелә: *вату – туздыру; җимерү; бозу; зыян китерү; сындыру* [Ханбикова, Сафиуллина, б. 30]. Әдип исә, синонимик рәтне кире тәртиптә кулланып, көчле тәэсир тудыруга ирешә.

Түбәндәге өзектә дә бу рәвешле кулланылган мәгънәдәш сүзләр укучыга процессның көчәюен анык күзалларга ярдәм итә:

***Сызланадыр****...*
***Әрнидер****.*
***Авыртадыр*** *ла тәне*
*Кыйныйлар шул*
*Көтү белән*
*Йөрисе килмәгәнне.*
(Р. Зәйдулла «Качкын»)

«Синонимнар сүзлеге»ндә бу берәмлекләр түбәндәге тәртиптә бирелә: *авырту – сызлау; әрнү; сыкрау; чәнчү; чәнчешү; сулкылдау; сулыгу; сыкрану* [Ханбикова, Сафиуллина, б. 10]. Автор исә аларны киресенчә куллана.

10. Иң югары яки иң түбән дәрәҗәне бирү өчен. Мәсәлән:

*Ә бит* ***туңам****...*
*Суык...*
***Калтыранам****.*
*...Күкрәгемнән алып үпкәне*
*Суган, борыч салып табалыкта*
*Кыздырмакчы идем.*
(М. Әгъләмов «Кан туганым бит син…»)

Салкын, суыкның тәнгә тәэсире нәтиҗәсендә кеше туңа, ә калтырану исә шул туңу халәтенең бер билгесе генә, әмма шигъри юлларда ул процессның югары дәрәҗәсе буларак бирелә.

Киләсе өзектә билгеләнгән сүзләр үзара тигез хокуклы синонимнар булсалар да, иң түбән дәрәҗәне белдерү чарасы буларак, бер-берсен тулыландырып киләләр:

*Анда Сәйдәш моңсу көлемсери,*
*Сибелә көй* ***әкрен****,* ***тын*** *гына.*
*Сибелә язмыш...*

*Җирдә яшәүләре*
*Читенрәк икән моңлыга.*
(Р. Зәйдулла «Күз яше»)

Мисаллардан күренгәнчә, шагыйрьләр синонимнарны төрле максатларда кулланалар. Биредә шуны да искәртеп үтү кирәк: кайбер синонимнарны бер үк вакытта берничә төргә кертеп карарга мөмкин. Мәсәлән, фикерне төгәлләү, аныклау яисә басым ясау, ассызыклап күрсәтү өчен кулланылган төрләргә. Монда авторның һәм укучының субъектив фикерләре мөһим роль уйнавын да ассызыкларга кирәк.

Мәгънәдәш сүзләр күбрәк олы һәм урта буын шагыйрьләрдә очрый. Яшьләр исә, нигездә, телдә еш кулланыла торган синонимнар белән чикләнәләр, алар иҗатында мондый чараларны төрлеләндерүгә омтылыш бик сизелми.

**Әдәбият**

*Галиуллин Т.Н.* Шигърият офыклары // Татар шигърияте: 1980–2000 еллар. Казан: Мәгариф, 2003. 352 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

*Ханбикова Ш.* С. Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 280 б.

*Ханбикова Ш.Х., Сафиуллина Ф.С.* Синонимнар сүзлеге. Казан: Хәтер, 1999. 255 б.

***Денмөхәммәтова Эльвира Николай кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан федераль университетының гомуми тел белеме*
*һәм тюркология кафедрасы доценты*

УДК 811.512.145'375

***И.Ф. Миргалимов***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ *ПРОСТРАНСТВО* КОНЦЕПТЫНЫҢ ВЕРБАЛЬЛӘШҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Каждый народ имеет свой метод познания Пространства и комплекса представлений о его устройстве и космогонии. Многие народы приходят к пониманию данной категории в связи с первобытными представлениями о природных явлениях. В статье рассматриваются средства вербализации концепта *пространство* в татарском языке.

**Ключевые слова:** татарская языковая картина мира, концепт, *пространство, место, ориентация, центр, вселенная.*

Тел һәм әдәбият белеме өлкәсендә урын-ара мәгънәсен яки «пространство» концептын белдерә торган репрезентлар күп түгел. Иң элек, «пространство» терминының сүзлекләрдә теркәлгән мәгънәләре белән танышып үтик.

*Пространство* лексик берәмлеге үзенең этимологиясе белән рус теленә барып тоташа. Русча-татарча тәрҗемә сүзлегендә аның түбәндәге мәгънәләре теркәлгән:

1) киңлек; воздушное пространство – һава киңлекләре; 2) *филос*. пространство; пространство и время – пространство һәм вакыт. 3) (*место; промежуток*) бушлык; аралык, буш урын; безвоздушное пространство – бушлык, вакуум; занимать две трети пространства – урынның өчтән ике өлешен алып тору; свободное пространство между окном и дверью – тәрәзә белән ишек арасындагы буш урын; 4) (*земельная площадь*) мәйдан [Русско-татарский словарь, с. 497].

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *пространство* лексемасы фәлсәфә фәне кысаларында аңлатыла: Пространство *филос*. Материя яшәешенең озынлык һәм күләм белән характерлана торган гомуми төп объектив формаларының берсе [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, б. 430].

М.И. Мәхмүтов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллиннар төзегән «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә пространство *фәза* (фәзаэ) алынма сүзе белән атала. Ул *күктәге* (һавадагы) *бушлык; ачык урын, ачыклык* дип тәрҗемә ителә [Мәхмүтов, Хәмзин, Сәйфуллин, б. 632].

Урын-ара мөнәсәбәтләре борынгылар тарафыннан дөнья шәкеленең иң әһәмиятле атрибутларыннан саналган. Борынгы төркиләрдә пространство – «бар җир» төшенчәсе «кояшның беренче нурларыннан алып, көнбатыш чикләренә кадәр булган» киңлекне аңлата. Алар фикеренчә, *пространство* дүртпочмаклык формасында. Татарларның бабалары аңында ул реаль яки мифологик юллар белән үзләштерелгән һәм хаоска каршы куел-

ган тәртипкә салынган дөньяны аңлаткан.

Борынгы төркиләр һәм шул исәптән болгарлар карашынча, хаос, ягъни буталчык, тәртипсез башлангычны чагылдыручы иксез-чиксез су өермәсеннән дөнья, галәм барлыкка килә, хаос тәртипкә керә, *пространство* – Җир, Кояш, Ай ярала.

Халык дөньяны ничек күрсә, аның аңында шундый дөнья төзелеше чагылыш таба. Ул яшәешне шул рәвешле күреп аңлый һәм бу дөньяның милли образын тәшкил итә.

Соңгы вакытта тюркологиядә дөньяны тел чаралары ярдәмендә сурәтләү мәсьәләләрен өйрәнүгә игътибар арта башлады. 2006 елда Ә.Р. Тенишев редакциясендә төрки халыкларның дөнья картинасы модельләренә багышланган «Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика» исемле китап басылып чыкты. Әлеге хезмәттә төрки халыкларның дөнья моделе 3 катлы пространствога бүлеп тасвирлана: өске катны күк (небо), урта катны җир (земля), аскы катны җир асты (подземелье) тәшкил итә [Сравнительно-историческая грамматика..., с. 326].

Татар лингвокультурасында дөнья картинасын өйрәнү башланып кына килә дисәк тә, ялгыш булмас. Татарларда дөнья моделе, төрки халыклардагы кебек, 3 катлы булып күзаллана: күк (небо) – өске дөнья, җир (земля) – урта дөнья, җир асты (подземелье) – аскы дөнья. Башкорт тел белгече З.М. Раемгужинаның «Языковая картина мира в башкирской фразеологии» дигән фәнни хезмәтендә ул тагын да конкретлаштырыла төшә [Раемгужина, с. 11]. Өске дөнья – күк, һава. Анда кояш, ай, йолдызлар, Алла (Ходай, Тәңре). Урта дөнья – җир, җир-су, кешеләрнең һ.б. җан ияләренең тереклек урыны. Аскы дөнья серле кала. Ул кешеләрне, хайваннарны күмү, җирләү, кара көчләрнең яши торган җирләре булып санала.

Ф. Урманченың «Татар мифологиясе» энциклопедик сүзлегендә дөньяның космогоник мифларда чагылышы аңлатыла. Борынгы заманда кешеләр *Җирне*, хәзерге шикелле шар рәвешендә түгел, ә бәлки тигез, яссы урын буларак кабул иткәннәр. Җиһанның (Галәм), шул исәптән Җирнең дә, гомуми төзелешен безнең ерак бабаларыбыз түбәндәгечә күз алдына китергәннәр: тигез, яссы җир үгез мөгезендә тора. Бу үгез үзе зур балыкның мыегына беркетелгән. Балык чиксез-кырыйсыз суда йөзеп йөри. Җирне төрле яктан чорнап алган су мәңгелек караңгылыкка күмелгән. Ягъни, борынгы чор дөнья мифологиясендә тасвирланган җиһандагы *тәүге тәртипсезлек* («первобытный хаос») төшенчәсе билгеле бер дәрәҗәдә татарларның милли мифологиясендә дә чагылыш таба. Җир Җиһанның (Галәм) үзәге буларак карала. Димәк, Күк патшалыгындагы Ай, Кояш, йолдызлар, табигатьнең җанлы көчләре буларак, Җир мәнфәгатьләре белән генә яшиләр.

Иң борынгы карашлар буенча Җирнең барлыкка килүе бик җиңел хәл ителә. Безнең

көннәргә кадәр саклаган легендада бу хакта түбәндәгеләр сөйләнә: «Элекке заманнарда дөнья тоташ судан гына торган. Кешеләр әле булмаган. Суда балыклар һәм су кошлары гына яшәгәннәр. Шунда бер үрдәк, су төбенә чумып, борыны белән бер кисәк балчык алып чыккан. Ул зурайган һәм шуннан җир хасил булган, ди». Бу легендага карата Х. Гыйләҗетдинов шундый искәрмә бирә: «Болгар чорына караган археологик материаллар арасында авызына шар капкан үрдәк сурәтле бизәнү әйберләре очравы бу мотивның борынгы болгарлардан таралган булуы турында сөйли». Борынгы болгар мифологиясе буенча, Җир, Кояш, Ай бер үрдәк салган күкәйдән яралган дип тә уйланылган [Урманче, б. 11–12].

Галәм өч каттан тора: Күк дөньясы, без яшәгән Җир һәм Җир яки Су асты дөньясы. Күк дөньясы Ай, Кояш, Кошлар патшалыгы белән бәйләнгән булса, Җир өсте – кешеләр яши торган гадәти дөнья. Ә инде Җир асты яки Су асты патшалыклары Үлеләр дөньясы санала. Анда бу фани дөньядан киткән кешеләр, аларның рухлары, Аждаһа, Дию, Елан, гыйфритлар гомер итә. Соңгылары кешелек дөньясына зыян салып торалар.

Борынгы төркиләр фикеренчә, *вертикаль дөнья* өч өлештән тора:

1) Югары дөнья, Күк, Тәңре дөньясы;

2) Урта дөнья, җир өсте, «Удук Йир-Суб» – «изге Җир-Су». Ул «Удук Йир-Суб» алласы белән идарә ителә. Борынгы төркиләр аңында Йир-Суб бербөтенлекне, туган ил мәгънәсен белдергән;

3) Җир асты, үлеләр дөньясы. Аның белән Эрклиг исемле алла идарә итә.

Бу дөньялар арасында күченеп йөрергә мөмкин. Моның өчен изге биек таулар, биек ялгыз агачлар, кошлар, канатлы атлар хезмәт итә. Алар Юл тәңресе карамагында.

Болгарлар, борынгы төркиләр кебек үк, *вертикаль дөнья* өч өлештән: Җир, Күк, Җир асты дөньяларыннан тора дип уйлаганнар [Дәүләтшин, б. 200].

Димәк, Җиһан без яшәгән Җир өсте дөньясы белән генә чикләнми: анда башка – икенче, хәтта өченче дөньялар да бар икән. Шулай булгач, аларда гомер итүче затлар да төрле булырга тиеш. Җирдә булмаган һәм һич тә була алмаган күренешләрнең, затларның барысы да Җир асты яки Су асты патшалыкларында урын ала. Гомумән алганда, бу патшалыклар, бу дөньялар билгеле бер дәрәҗәдә Җир өсте патшалыгының киресен гәүдәләндерәләр [Урманче, б. 20–21].

Нәтиҗә ясап әйтсәк, пространство яки урын-ара ул, иң беренче чиратта, безне чолгап алган дөнья, галәм, яшәеш, барлык, тереклек. Әлбәттә, Күк, Җир асты дөньяларын да кире кагып булмый. Тик аларның икесе дә кешеләрнең ышануларына бәйле. Шулай ук бу мәсьәләдә дин һәм дин кануннары да зур әһәмияткә ия. Кайберәүләр Җир астын «түбән мифологик затлар» яши торган урын дип түгел, бары тик байлык, файдалы казылма-

лар тупланган, яшеренгән хәзинә дип кенә уйлыйлар. Күк дөньясын да аерым илаһи затлар яши торган урын дип санаучылар бар. Ә кешеләр яши торган Җир өсте дөньясы һәркем өчен дә билгеле, бар дип санала һәм кабул ителә.

Ягъни, *пространство* яки *урын-ара* ул – киңлек; җир, урын; аралык, бушлык; мәйдан; материя яшәешенең төп объектив формаларының берсе; ачык урын, ачыклык; фәлсәфи төшенчә; Җир; Күк; Җир асты һ.б.

**Әдәбият**

*Дәүләтшин Г.М.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 429 б.

*Мәхмүтов М.И., Хәмзин К.З., Сәйфуллин Г.Ш.* Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. II том. Казан: Иман, 1993. – 853 б.

*Раемгужина З.М.* Языковая картина мира в башкирской фразеологии.: дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 2000. 137 с.

Русско-татарский словарь. М.: Русский язык, 1984. 730 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика / под ред. Э.Р. Тенишева. М.: Наука, 2001. 986 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты. 2005. 849 б.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. Өч томда. II т. Казан: Мәгариф, 2009. 343 б.

***Миргалимов Илдар Флүс улы,***
*Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары*
*E-mail: ildarfm.kazan@gmail.com*

УДК 821.162.1-6(=512.1)

*Марцин Байко*

# ТАДЕУШ МИЦИНСКИЙ ХАТЛАРЫНДА ИСЛАМ, ТӨРЕКЛӘР ҺӘМ ТАТАРЛАР

Автор статьи предпринимает попытку представления некоторых ранее не известных эпизодов биографии Тадеуша Мицинского (1873–1918) – писателя младопольского периода. Во время Первой мировой войны он находился в Москве, где встречался с татарами, проживавшими в Российской Империи. Принимал участие в I Всероссийском мусульманском съезде (1–11 мая 1917 года), с энтузиазмом высказывался о перспективах культурного и религиозного освобождения мусульман, что стало возможно благодаря Февральской революции. В своем творчестве, преимущественно публицистике, он высказывался о турках и склоняющейся к упадку Османской империи. Это были достаточно амбивалентные высказывания, распятые между восхищением и признательностью, обидой и осуждением.

**Ключевые слова:** татары, турки, Первая мировая война, Февральская революция.

XIX–XX гасырлар чигендә иҗат иткән башка поляк язучылары кебек үк, Тадеуш Мицинский (1873–1918) өчен дә Госманлы империясе шул чордагы исламның төп репрезентанты булып санала. Ул таркалу алдында тора (шуңа да карамастан, аның котылгысыз һәлакәтен беркем дә көтмәгәндер). Әлеге мәкалә герое бу хәлне бөтен тулылыгы белән аңлый, һәм бу аның Балкан корреспонденцияләренең 1913 ел датасы куелган «Ярымайның шәфәгы» (Zmierzch półksiężyca) дигән мәкаләсендә исеменнән үк тулы чагылыш таба.

Мөхәммәд пәйгамбәр динен, аеруча аның мистик йолаларын, суфичылыкны шагыйрь үз иҗатында аллюзияләр һәм типның күпсанлы фигуралары («Мөхәммәднең фантастик киемнәрдәге сугышчылары Иблис ягына хәрәкәт итүче шәүләләрне хәтерләтәләр» [Miciński, 2008, s. 125]) сыйфатында куллана. Яки болай дип бирә: «Матур телле гарәп шагыйрьләре кебек Муаллактан[1] сокландыргыч газәлләр җыры яңгырый. Суфиларның мөселманлыгын ул розенкрейцерлар («Роза һәм тәре» ордены тарафдарлары. – *Ред*.) мистикасы белән тәңгәлләштерә» [Miciński, 1930, s. 143]. Мәкаләмдә алга таба аллюзияләргә һәм әлеге тип гыйбарәләренә тукталмыйча, аеруча мөһим мәсьәләләргә генә урын бирәчәкмен.

Мөгаен, Мицинский хезмәтләрендә мөселман «элементлары»ннан аеруча танылганы һәм киңрәк тасвирланганы фарсы шагыйре һәм унөченче йөзьеллыкның мистик шәхесе Җәләлетдин Мөхәммәд Руми[2] булгандыр. «Нетота» («Nietota») авторы Руми поэзиясен тәрҗемә итә, һәм үз әсәрләрендә берничә мәртәбә аның иҗатыннан сылтамалар китерә. Яшь Польша чоры язучысы-

ның татар темасын, шул исәптән борынгы Речь Посполитаяның көнчыгыш чикләрендә яшәгән татарлар тормышын бик теләп күтәргән хезмәтләре турында мәгълүматлар бөтенләй аз. Мицинскийның Польша – Литва һәм Казан татарлары белән шактый мавыктыргыч очрашуы Мәскәүдә Февраль инкыйлабыннан соң, Октябрь инкыйлабы алдыннан була, һәм бу аның язмышында да эзсез калмый [Кара: Wieczorkiewicz, 2010, s. 383–387].

Нәкъ менә татарларга Мицинский «кардәшләр» сүзе белән мөрәҗәгать итә, һәм шуның белән үзенең төп идеясен – халыклар туганлыгы идеясен чагылдыра. Үзенең башлангыч иҗатында, барыннан да бигрәк, славян халыклары туганлыгы идеясен пропагандалаганга күрә, бу очракта ул әлеге сүзнең нигезен билгеле бер дәрәҗәдә үзгәртеп куллана.

Мицинский иҗатының «исламга кагылышлы» юнәлешләренең өченчесен төрекләр турындагы уйланулары тәшкил итә һәм монда аның Коръәнгә һәм исламның кайбер аспектларына карата тискәре мөнәсәбәте мөһим урын тота. Аның бу өлкәгә карашлары еш үзгәреп тора: ул я сокланулы мактаудан, я хәлиткеч хөкем чыгарудан гыйбарәт була.

## Төрекләр, ислам – «катнаш» хисләр

«Вита» («Wita») авторы 1912 елда София, Белград шәһәрләрендә була һәм Балкан сугышларына багышланган махсус белдерүләрендә беренче тапкыр төрекләр турындагы фикерләрен әйтә. Бу хактагы язмасын Варшаваның атналык басмасы «Мир» («Świat»)га җибәрә. Танылган славянофил[3] Мицинский төрекләрне беркайчан да гафу итә алмый, чөнки көньяк славяннарының (бигрәк тә болгарлар һәм сербларның) язмышлары «аларның намусында була». Төрекләргә карата күралмаучылыкның тагын бер сәбәбе ул – XX гасырда төрекләрнең сәяси союздаш итеп немецларны сайлавы[4].

Госманлы басып алучыларының кылган гамәлләре аркасында «биш гасыр буе дәвам иткән коллык изүе славяннарның рухын җимерде». Мицинский «Витоша янындагы шәһәр» («Miasto pod Witosa») дип аталган корреспонденцияләренең шактый зур өлешен шушы темага багышлый. Ул шулай ук түбәндәге фактларны раслый: «Төрек аларга, коллар икәнен онытмасыннар дип, бөтенесенә дә кара киемнәрдән яки ирләр өчен дип өйдә тукылган көрән күлмәкләрдән йөрергә кушты. [...] Үзенә ачык төстәге киемнәрне калдырды; чибәр йөзен куе челтәр астына яшерергә өлгермәгән матур кызларның барысын да үзе белән алып китте. Бүгенге болгар милләтенең борынгы бабалары төрекләр булган, шул борынгы бабаларның оныклары хәзер пычаклар белән турыйлар һәм штыкка утырталар...» [Miciński, Miasto pod Witoszą, s. 4].

«Нетота» авторы коллыкка төшерелгән болгар һәм аларны коллыкка төшерүче төрекләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тасвирлый. Шул ук вакытта ул урталыктагы этнодини төркемнәрне –

помакларны, ягъни мәҗбүри рәвештә яки үзләре теләп (нигездә икътисади сәбәпләр аркасында) исламны кабул иткән, төрекләшкән болгарларны да онытмый. Болгарларның төрекләрне дә, үзләре сатлык җаннар дип атаган помакларны да бердәй дәрәҗәдә күралмавы турында яза[5]. Төрекләрнең дә, болгар солдатларының да ерткычлыклары һәм мәсхәрәләүләре турындагы мәсьәләләрне күтәрә, аларның берсен дә яклап чыкмый.

Шул ук вакытта төрекләргә дөрес бәясен бирә: «Бу әле зур үсеш алган сәнгати мәдәнияткә ия һәм һәрчак үз иленең кешеләренә югары әхлаклы мөнәсәбәттә булган халыкны биш гасыр буена сузылган коточкыч юкка чыгару детальләре турында сөйләшү урыны түгел», – ди.

«Төрекләр, мәсәлән, барщинаның нәрсә икәнен беркайчан да белмәгәннәр, ә Морат III фәрманнарында, Собеский вакытларында һәрвакыт, безнең һәркайсыбыз райны изү-җәберләүгә сак карарга тиешбез (рай – салым түләүче халык) дия торган булганнар».

Автор шушы сүзләрдән соң ук болай дип өсти: «Шулай да Коръән кяферләр (гяурлар) өчен фәкать кылычны гына белә, ә колакларны һәм телне кисү – тәмугта шушы әгъзалары белән гөнаһка кергән бәндәләрнең колакларын һәм телләрен кисәчәкләр дигән дини карашка нигезләнгән. Гөнаһлылар алар, һичсүзсез, сугыш кырындагы кяферләр» [Miciński, Miasto pod Witoszą, s. 7].

«Ярымайның шәфәгы» тексты нигездә төрекләргә багышланган. Анда түбәндәге юллар бар: «Коръән мөселман халыкларның (малайялылармы алар, әллә Босния яки Албания славяннарымы) рухына-канына сеңдерелә: тәкъдиргә буйсындырылган аңсызлыкка җиткерә» [Miciński, Zmierzch półksiężyca [część I], s. 5].

Без төрекләрнең үзләренә буйсындырылган славяннарга карата кулланган рәхимсезлекләре, камилләшкән җәза формалары турында беләбез. Моннан чыгып, Мицинский түбәндәге нәтиҗәгә килә: «Шулай да без дөрес аңларга тиешбез, төрекләр, кагыйдә буларак, намуслы һәм рәхмәтле халык. Аларны дингә сукырларча ышану харап итә. Коръән – сокландыргыч поэзия китабы, әмма тормышта ул үзенең колларына гына түгел, ә гарем (хәрәм) азгынлыгына, чамасыз ялкаулыкка кереп баткан хөкемдарларына да үлем китерә [Miciński, Zmierzch półksiężyca [część I], s. 5].

Әйтеп үтелгәннәрдән чыгып, мондый нәтиҗә ясарга мөмкин: авторның мөселманнарга карашы ике төрле. Ул мөселманнарның гореф-гадәтләрен хөрмәт итә, аларның техник һәм сәнгати казанышларын дөрес бәяли, төрек командирларының патриотизмына һәм талантына соклана. Шул ук вакытта бу диннең изге китабына карата югары фикердә булмый. Сүз дә юк, ул үзен ялгыш фикерлелектә гаепләүләрен теләми, шуңа күрә сугыш турындагы хезмәтләрендә «болгарларның, сербларның һәм грекларның» төрекләргә карата «агрессив гамәлләре» турында да искә алырга онытмый

[Miciński, Zmierzch półksiężyca [część II], s. 5].

Аның үзенең берничә мәртәбәләр искәртүенчә, Госман империясенең дошманнары – славяннар һәм греклар тарафыннан кертелгән цензура сәбәпле, алар хакында прессага язу тыелган була.. Цивилизация таләпләреннән караганда, сүз дә юк, төрекләр көнбатыштагы күршеләреннән күпкә өстен булалар, хәрби операцияләр вакытында инфраструктураны (күперләрне, телеграф линияләрен, тимер юлларны), серблар, болгарлар һәм греклардан аермалы буларак, җимермиләр, юкка чыгармыйлар. Мицинский әйтүенчә, моны ярымай илендә яшәүчеләргә адресланган иң югары комплиментларның берсе дип санарга кирәк. Ул моны түбәндәге юллары белән раслый: «Төрекләр – алар үзенчәлекле кешеләр. Элек алар метафизикага омтылса, ә бүген – цивилизациягә [...] Төрекләр христиан чиркәүләрен, һич югында, мәчеткә әйләндерсә, христианнар исә мәчетләрне ат абзарына әверелдерә [Miciński, Zmierzch półksiężyca [część II], s. 6].

Аның Балкан текстларында төрекләр белән греклар көньяк славян халыкларыннан күпкә түбәнрәк бәяләнә, гәрчә автор анда болгарлар белән сербларга карата тәнкыйди фикердә булса да. Ул корреспонденцияләрендә грекларны уңай яктан искә алмый, ә менә төрекләр тарафыннан төзелгән учреждениеләр, барыннан да элек, ислам мәдәниятенең матди аспектлары турында ул уңай фикерләрне бик еш әйтә.

Берничә еллар узгач, язучы, ислам темасына бәйле рәвештә, төрекләр мәсьәләсенә яңадан әйләнеп кайта. Беренче Бөтендөнья сугышы башланган елларда Мицинский Мәскәүдә нәшер ителә торган «Польское эхо» басмасы белән хезмәттәшлек итә. 1916 елда аның бер санында Госман империясе кул астында яшәүче әрмәннәрне күпләп үтерү турында язма басыла. Ул авторның төрекләр темасына кабат әйләнеп кайтуына этәргеч була. Әйтелгән темадан читкә китеп, ул үзенең соңгы поэмасын – «Анахита мәхәббәте»н (Miłość Anahity) яза[6]. Төрекләр әрмәннәргә карата кулланылган геноцид фактын дөнья җәмәгатьчелегеннән яшерергә тырышалар [Кара: Wituch, s. 238–244]. Монда шунысы икеләндерә, Мицинский әрмәннәрне юкка чыгару хакындагы барлык мәгълүматларга да ия була алды микән, чөнки алар аны «мөмкин кадәр яшерен эшлиләр» [Wituch, s. 238–244]. Шуңа да карамастан, поэмада әрмән халкы фаҗигасе киң итеп, бөтен дөнья сугышының беренче планына чыгарыла, ул исламның христианнарны юкка чыгару максаты белән алып барган дини сугышы итеп тасвирлана.

Станислав Назарян (хәзерге варианты – Назаревич) – чыгышы белән әрмән саналган поляк. Ул патша армиясендә хезмәт итә, төрек-немец гаскәрләре урнашкан Эрзерум ныгытмасын штурмлауда катнаша. Шул ук вакытта ул үзенең сөйгәне – Анахитаны да коткарырга тели. Аның өчен Анахита бөтен

Әрмәнстанның символик образы рәвешендә гәүдәләнә. «Анахита белән бергә без Тәңре Тәресенең бишенче кадагын тәшкил иткән бөтен Әрмәнстанны коткарачакбыз», – ди ул [Miciński, 1916, s. 12].

Бу тарих уңышлы (хеппи-энд) тәгәлләнми, чөнки төп героиня, Назарянның өметен өзеп, явыз төрек Сиди Морнанг бәй аркасында ялкын эчендә һәлак була. Аерым детальләргә тукталмыйча гына, авторның төрекләрне характерлаган берничә эпитетына тукталып узыйк. Алар турында Назарян һәм әрмән вартабеты (теологы; православие чиркәве архимандриты дәрәҗәсенә тиңләшә торган дин әһеле) болай диләр: «Ярымай шәһәре (сүз Эрзерум турында) – Мәкерле Кайзер белән рухланган кара фикерле фанатлар ятаганы таркалып бара» (Мәкерле Кайзер – Германия императоры Вильгельм II).

Мицинский «Анахита мәхәббәте» поэмасында әрмән поэзиясенең XIX гасыр (Рафаэль Патканян, Петрос Дурян) һәм XX гасыр (Ованес Туманян) әсәрләреннән фрагментлар китерә, аларда азатлыкка омтылыш элементлары, шулай ук Европаның гамьсезлегеннән һәм сүзсез ризалашуыннан зарлану авазы чагылыш алган була. Нәкъ менә шушы сыйфатлар Германия тарафыннан яклау тапкан төрек дипломатиясе барлыкка килүгә юл ача. «Анахита мәхәббәте» поэмасының бер өлешен тәшкил иткән «Әрмән каны» («Armencka krew») шигырьләрендә бу хакта бик ачык тасвирлана:

Ha, dopókiż, Armeńczycy, jarzmo
będziem znosić,
pokorniutko Europę, jak Jehowę
prosić?!
Wszyscy radzi, by pewno nie słyszeć
nas więcej!
gładko idzie, wyrżniętych tysiąc
kroć tysięcy!..
dzielne Turki! ta kwestia już będzie
milczała…
W czarnych kłębach dyplomacji
Kainowi chwała!

[Miciński, s. 12.]

Эх, до каких пор, Армяне, мы
будем тянуть ярмо,
покорненько Европу, как Егову
просить ?!
Все рады, чтобы не слышать нас
больше,
гладко идет, тысячи вырезанных
армян! …
смелые турки! эта проблема будет
молчать …
В черных клубах дипломатии
Каину хвала!

*(Русчага мәкалә авторы тәрҗемәсе)*

## Татарлар – «кайнар» хислеләр. Полякның Россиядә татарлар белән очрашуы

Сүз дә юк, поляклар өчен мөселманнардан иң якыны элек-тән үк татарлар булган. Мицинский бу хакта гомеренең соңгы айларында үз фикерен әйтеп калдырган. Ул берничә ел дәвамында Мәскәүдә яшәгән. 1917 елның май аенда Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаенда (ул 1–11 майда уздырыла) катнаша, ә Польша матбугаты аны «Татарлар корылтае» дип яза[7].

«Йолдызлар караңгылыгында» («W mroku gwiazd») авторы

бу корылтай вакытында чыгыш та ясый әле. Мицинский үзе әйткәнчә, «очраклы импровизация»сендә ул татарларның Польшага күрсәткән игелекле гамәлләрен билгеләп үтә.

Аның чыгышыннан аңлашылганча, монда алар тоткан дин поляклыкны чикләми. Речь Посполитая территориясендә яшәүче татарлар, үз диннәреннән баш тартмыйча да, һәрвакыт Польшаның патриотлары, Бөек Литва кенәзлегенә һәм Польша корольләренә хезмәттә кыю сугышчылар булдылар.

Докладчы «Польшаны бүлгәләү вакытында фәкать мөселманнарның намуслылыгы һәм тирән тугрылыгы гына протест белдерде. Моны Польша беркайчан да онытмаячак» [Цит. по: Miciński, 1917; Кара: Bałczewski, s. 363–282; Reychman, rozdz. 8 i 9], дип искә төшереп үтә. Без монда борынгы Госман империясендә XVIII гасырда яшәгән язучы Мицкевичның Речь Посполитаяны бүлгәләү белән беркайчан да килешмәве һәм Мицинскийның да аның фикеренә кушылуы кебек чираттагы реверансы белән очрашабыз. Мицинский төрекләргә «ярдәмгә ашыгучы поляк полклары» турында искә алганда, әлбәттә, Кырым-Польша сугышы һәм Польшаның бәйсезлегенә ирешү максатларында рус-төрек конфликтларыннан файдаланып калырга омтылуы вакыйгаларына мөрәҗәгать итә[8].

Илһамланып ясаган чыгышында Мицинский «мөселманнарның азат ителүе уңаеннан үзенең тирән шатлыгын» белдерә һәм, поляклар белән татарлар арасындагы бәйләнешләргә генә түгел, югары мәдәни үсеш алган поляк-мөселман мөнәсәбәтләренә дә басым ясый. Үзен тыңлап утыручы татарларга поляк язучыларының (Мицкевич монда Словацкий һәм Сенкевичны атый) бик теләп көнчыгыш мотивларга мөрәҗәгать итүләре, шулай ук «даһи мистик шагыйрь»не (әлбәттә, сүз Руми турында) тәрҗемә итүләре (тәрҗемәчеләр дигәндә, үзен күз алдында тота) хакында да әйтеп уза. Аның чыгышы озын булмый, шуңа күрә бу документның Польша газетасында («Gazeta Polska») басылып чыккан вариантын тулысынча тәкъдим итәргә булдым:

«Мөселман кардәшләр!

Польшада татарлар күп яши, алар барысы да дини һәм гражданлык хокукларыннан тигез файдаланалар. Мөхәммәд өммәте булып калсалар да, алар чын күңелләреннән Польшаның патриотлары һәм кыю сугышчылары булып хезмәт итәләр.

XVI гасырда ук инде Польшада “Гөлестан”[9], “Йосыф белән Зөләйха” поэмасы һәм тагын күп кенә әсәрләрнең тәрҗемәләре басылып чыкты. Польша көнчыгыш белән көнбатыш сәүдәсен һәм мәдәниятен бәйләүче буын булды. Без көнчыгыш сәнгатеннән күп үрнәкләр үзләштердек. Безнең өчен тагын шул факт мөһим, Польшаны бүлгәләү вакытында фәкать мөселманнарның намуслылыгы һәм тирән тугрылыгы гына протест белдерде. Моны Польша беркайчан да онытмаячак.

Ә инде ярымай азатлыгы өчен көрәш барганда, поляк полклары сезгә ярдәмгә ашыкты. Поляк әдәбияты көнчыгыш тормышына багышланган әсәрләргә бай. Мицкевич “Фариса”ны язса, Словацкийда кыю Мирза Хәмид Абдулевич тасвирлана, Сенкевич “Сәлимә”не иҗат итә һәм тагын башка күп әсәрләр языла. Җәләлетдин Руминың шигъри әсәрләре поляк теленә тәрҗемә ителә. Бу даһи мистик-шагыйрь XIII гасырда, сугыш вакытында Сәмәркәнд белән Бохара мәдәнияте тар-мар ителгән чорда яши, әмма, Кече Азиягә күчеп китеп, дини поэзиянең тирән чагылышын саклап калуга ирешә. Аның поэмаларының берсенә нигезләп поляк композиторы Шимановский гаҗәеп яңгырашлы музыкаль әсәр иҗат итә[10].

Сугыш туктауга ук без барыбыз да чистару-сафлану суына чумарга тиеш булабыз. Боларның барысын да безгә бай рухлы дөньясы исән калган Көнчыгыш бирәчәк.

Петроград өстендә мәчетнең сапфир төсендәге гаҗәеп матур гөмбәзе юкка гына балкып тормый[11]. Ул күк йөзен безнең сокландыргыч хисләребезгә күмәчәк. Цивилизациянең бишеген, хәтта иң югары ноктасын тәшкил иткән көнчыгышка, Һиндстанга юл сезнең аша уза.

Көнчыгышта таң атты, һәм без ышанабыз, ул безгә ярдәмгә киләчәк!»[12]

Әйтеп үтелгән чыгышыннан тыш, Мицинский әле корылтай турындагы тәэсирләрен «Татарлар Мәскәүдә» дигән мәкаләсендә дә дәвам итә. Ул анда поляклардан Мәскәүдәге Польша йортының мәдәният эшлеклесе (булачак күренекле геолог) Мечислав Лимановский белән икесе генә катнашуы хакында үкенебрәк яза. Текстында ул Россиядә 26 миллион мөселман (аныңча – «мөхәммәт өммәте») яшәвен искәртә. Әмма, мәгълүм булганча, 1917 елда аларның якынча исәбе 16 миллион чамасы тәшкил итә. Мицинский сүзләренә караганда, корылтайда 800 делегат катнаша, шулардан йөзләп хатын-кыз Мәскәүгә Казаннан турыдан-туры «Тигезлек» корылтаеннан килгән була [Кара: Chazbijewicz, s. 27].

Автор монда нәрсәгә аерым игътибар итә соң? Табигый ки, карашларга, нәкъ менә хатын-кыз күзләренә ул битараф кала алмый: «Алар арасында язучылар бар һәм чуар капланныкы кебек саргылт-бронза яки металлны хәтерләткән кара бәрхет төсендәге гаҗәеп матур күзле чибәркәйләр бар», – ди. Ул вакытларда кабул ителгәнчә, «типажлар»га аерып, мөселманнарның йөз төзелешенә кыскача тасвирлама бирә: «Индуслар тибындагы озын сакаллы, чал чәчле, бөркетнекедәй борынлы шәехләр дә бар. Нигездә алар – чаларган, энергияле, йөз төзелешләре үзенчәлекле, әмма азатлык хисе белән рухланган һәм, ниндидер, тәкъдиргә буйсындырылган дәртле типлар. Дала бөркетедәй чандыр, куркыныч типлар да бар. Күзләре кысык, җәлпәк борынлы калмыкны, Лев Толстой кыяфәтендәге картларны, славяннарны хәтерләткән типлар бар».

Мицинский корылтайның бәйрәм догасы белән башлануын

болай тасвирлый: «Мулла, күзләрен йомып, Коръән сүрәсен чыгара. Тамак төбе белән, меланхолик экстазга бирелеп, гадәттә тартык авазлардан торган көйне суза. Барысы да аяк өсте басып, кулларын күкрәкләренә куялар». Ул корылтайда нинди телләрдә чыгыш ясауларына да туктала. Өч телне – татарча, алтай-төрки һәм рус телләрен санап үтә. Ә инде Урта Азиянең төрки телләре турында сүз барганда, үзбәк, кыргыз һ.б. телләрне атый. Мицинскийга кемнәрнең чыгышлары ошаган яки ул кем турында әйтүне кирәк санаган? Беренче чиратта «Әхмәт» Цаликовны искә ала. Милләте белән осетин Әхмәт Цаликов (1882–1928) – Кавказда танылган сәясәтче, меньшевиклар партиясенең актив әгъзасы. Ул, чыннан да, бик җитди шәхес – Россия номенклатурасы өчен проектлар әзерләүче башкарма комитет әгъзасы була. Берничә айдан соң, 1917 елның ноябрендә ул Ленин хөкүмәте составына керүдән баш тарта, моның белән большевикларны күралмаган «Нетота» авторына аеруча ошарга тиеш була. Мицинский аның хезмәтләренең өземтәләреннән файдалана. Әмма аларны хәтерендә сакланган буенчамы, әллә корылтай барганда язылганнардан гына алганмы – анысы ачык мәгълүм түгел.

Мицинский мәгълүматларына караганда, корылтай утырышлары вакытында «Кырымнан, Алтай, Кавказ, Идел буе, Ташкент, Иркутскидан» килгән телеграммаларны укыйлар. Мицинский тарафыннан телгә алынган икенче делегат Вакытлы хөкүмәт вәкиле, профессор Сергей Котляревский була. Аны «рухи эшләр комиссары» диләр, ә чынлыкта ул Россиядәге Католиклар чиркәве эшләре буенча комиссия рәисе вазифаларын башкара. Котляревскийның чыгышы, Цаликовныкыннан аермалы буларак, куштырнакларга алынмый, берничә җөмләсе кыскартылып бирелә. Докладчы Топчибашев чыгышы да шулай бирелә. «Беренче Дума депутаты П. Топчибашев мөселманнарның лояльлегенә инандыра». Монда сүз, барыннан да бигрәк, азәрбайҗан вәкиле Алимәрдән Топчубашев турында бара булса кирәк. Ул корылтайда ясаган чыгышында «мөселманнар кичергән кыенлыклар турында елмаеп» сөйли һәм «мөселманнарның лояльлегенә инандыра». Ул, шулай ук, «мөселманнарга мәчет белән мулла гына кирәк» дигән күзаллауның ялган булуын, мөселманнарның «белемгә һәм иҗтимагый азатлыкка сусавын» исбатларга омтыла. Мәкаләнең калган өлеше Корылтайда икенче көн тәртибенең төп темасы – дәүләт эшендә «ачлыктан меңләп кырылган кыргызларның хәле» турында барган бәхәсләргә багышлана. Шулай ук анда Словацкийның «Беневский» поэмасының VII җырыннан шактый зур өземтә китерелә, бу өзектә «Ваки астындагы татар» – мулла (бу мулла турында Мицинскийның тантаналы чыгышында әйтелә) малае Абдулевич Әмәт әфәнде турында тасвирланган була [Słowacki, s. 187].

Корреспонденциясенең соңгы өлешендә Мицинский кабат

Цаликовка, төгәлрәге аның «Кавказ турында» («O Kaukazie») дигән әсәренә туктала.

Цаликов әфәнде үз әсәрендә «Прометей әле һаман шунда чылбырланган хәлдә һәм каргалар аның бавырын чукыйлар» дигән гыйбарәне раслап, администрация түрәләренең законсызлыклары турында сөйли: «таулардагы барлык черкас халкын Төркиягә кудылар, аларның күбесе хәерчелектән һәм авырулардан дөнья куйдылар. Черкасларга милли мәктәпләр ачарга рөхсәт итмәделәр, аларның җирләрен тартып алдылар. Бу фактлар турында миңа әрмән епископы Эчмиадзин җиткерде: Россия бюрократиясе аларның ел саен 150 миллион сум керем бирә торган (ул акча мәдәниятне үстерүгә тотыла, чиркәү ихтыяҗларына 15 миллионы калдырыла торган була) чиркәү милкен тартып ала».

Минемчә, Мицинскийның Россия империясе мөселманнары кичерешләрен тирәнтен аңлавын үз халкының да җәбер-золымга дучар ителүе, суверенлыкларын һәм элементар хокукларын югалткан кавказлыларныкына охшаш булуы белән бәйләргә кирәк. Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында шагыйрь, нинди диндә булуларына карамастан, бу халыкларны активлаштырырга омтыла. Шуңа күрә, поляк шагыйренең әрмән, кыргыз, черкас һәм татарларны тугандаш халык итеп санавы беркемне дә гаҗәпләндерергә тиеш түгел. Ә татарларны Мицинский стереотиплар аша кабул итә, бу аның тарихи повестында чагылыш таба. Анда ул татарларны «кысык күзле йөзләреннән танып була», дип яза [Miciński, Wita, s. 383]. Димәк, ул, татарларның Польша белән (Мәскәүдәге поляклар диаспорасы белән) бәйләнешләре хакында гомум энциклопедик күзаллауларга гына нигезләнсә дә, үз максатына ирешә.

**Искәрмәләр**

[1] *Mu’allaqāt*. Исламга кадәрге чор әсәрләренең иң яхшыларыннан саналган, гарәпләрнең зур күләмле җиде поэмасын эченә алган җыентык.

[2] Шуңа күрә бу теманы читләтеп үтәргә булдым. Кара: Dulęba, 1979; Nowakowska, 1979.

[3] Аеруча басым ясауны белдергән бу бүленеш мәкаләнең авторы тарафыннан билгеләнгән.

[4] Miciński, Zmierzch półksiężyca [część I], s. 5: «Төрекләрне Европадан куу өчен сәбәпләр күп. Беренчедән, аларга Германия ярдәм итә. Ул аларга славян йолаларын һәм бәйрәмнәрен юкка чыгару өчен 60 млн. марка бирде. Икенчедән, алар ил белән югары мәдәни дәрәҗәдә идарә итә белмиләр.

[5] Аннан соң ул Болгария территориясендә ачылган мөселман дини мәктәпләре – мәдрәсәләр, ислам дине әһелләре – хаҗилар турында искә ала. Боларны ул Җәләлетдин Руми белән бәйли. Чөнки Мицинский хатларында фарсы шагыйре ислам мәдәниятенең иң яхшы якларын туплаган символ, аның квинтэссенциясе булып санала.

[6] 1989 елда А. Выдрицка бу поэманы табып ала һәм аның кыскача эчтәлеген бирә. Кара: *Zapomniane...*, 1989, z. 4–5, s. 390.

[7] Корылтайны оештыруга Февраль инкыйлабыннан соң килеп туган яңа сәяси шартлар мөмкинлек тудыра. Бу – илдә чагыштырмача дин иреге алган, хәтта берничә ай дәвамында цензура булмаган чор санала. Октябрь борылышыннан соң алар юкка чыга. Кара: Татар энциклопедия сүзлеге, б. 122.

[8] Монда сүз, шулай ук, Мицкевичның Истанбулдагы эшчәнлеге һәм Михал Чайковскийның госманлы казаклары бүлекләре, генерал Владислав Замойскийның солтан казаклары дивизиясе турында бара.

[9] «Гөлестан» – фарсы шагыйре Сәгъдинең тезмә һәм чәчмә хикмәтләр, хикәятләр җыентыгы. Аның ике әсәре – фәлсәфи поэмасы «Бостан» (1256–1257, OgródDrzew) һәм «Гөлестан» (1258, OgródRóżany). Полякчага тәрҗемәләре Otwinowski (1610–1625; wyd. 1879), W. Kazimirski (1876).

[10] Сүз Король Шимановскийның «Төнге җыр» («Pieśń o nocy») дигән (1914–1916) III симфониясе турында бара.

[11] Санкт-Петербургта 1913 елда файдалануга тапшырылган мәчет ул чорда Европадагы иң зур мәчетләренең берсе була. Аның манараларының биеклеге – 49 метр, гөмбәзенеке – 39 метр. Мәчет Петербургның үзәгенә урнашкан. Бер үк вакытта 5 мең кешегә исәпләнгән.

[12] Тагын берничә сүз әйтү урынлы булыр. Беренчедән, аның үз чыгышында «Мөхәммәт өммәте» сүзен куллануы игътибарны җәлеп итә, дөресе – «мөселман». Беренче билгеләмә дөрес түгел, чөнки ислам тарафдарлары Мөхәммәткә түгел, ә Аллаһка табына. Кара: Banek, s. 469, przypis 1.

**Әдәбият**

*Bałczewski M.* Turcja a upadek Polski w XVIII wieku // Oświeceni wobec rozbiorów Polski / red. J. Grobis. Łódź, 1998. S. 363–282.

*Banek K.* Islam // Banek K. Historiareligii. Religie niechrześcijańskie. Kraków, 2007. S. 469, przypis 1.

*Chazbijewicz S.* Tatarstan. Pomiędzy autonomią a tęsknotą do suwerenności (4) // Przegląd Tatarski. 2014. Nr 2. S. 27.

*Dulęba W.* Gazele Dżalaluddina Rumiego w interpretacji Józefa von Hammera i Tadeusza Micińskiego (Porównanie tekstów // Studia o Tadeuszu Micińskim / pod red. M. Podrazy-Kwiatkowskiej. Kraków, 1979.

*Miciński T.* Miasto pod Witoszą // Świat. 1913. nr 3. S. 4.

*Miciński T.* Miłość Anahity // Echo Polskie. 1916. nr 5. S. 12.

*Miciński T.* Mowa Tadeusza Micińskiego na wiecu Tatarów // Ilustrowany Kurier Codzienny. 1917. Nr 159.

*Miciński T.* Wita. Warszawa, 1930. S. 143.

*Miciński T.* Xiądz Faust / oprac., przypisy i posłowie W. Gutowski. Kraków, 2008, s. 125.

*Miciński T.* Zmierzch półksiężyca [część I] // Świat. 1913. Nr 8.

*Miciński T.* Zmierzch półksiężyca [część II] // Świat. 1913. Nr 9.

*Nowakowska E.* Przekłady gazali Dżalaluddina Rumiego na tle twórczości Tadeusza Micińskiego // Studia o Tadeuszu Micińskim / pod red. M. Podrazy-Kwiatkowskiej. Kraków, 1979.

*Reychman J.* Historia Turcji. Wrocław; Warszawa; Kraków; Gdańsk, 1973. Rozdz. 8 i 9.

*Słowacki J.* Beniowski. Poema / oprac. A. Kowalczykowa. Wrocław 1996. S. 187.

*Wieczorkiewicz P.* Rząd Tymczasowy. Przewrót październikowy // Bazylow L. Historia Rosji, wydanie czwarte, poprawione i uzupełnione / Tekst obejmujący lata 1917–1991 napisał P. Wieczorkiewicz. Wrocław, 2010. S. 383–387.

Wituch T. Tureckie przemiany. Dzieje Turcji 1878–1923. Warszawa, 1980. S. 238–244.

Zapomniane teksty Micińskiego // Ruch Literacki, 1989. Z. 4–5. S. 390.

Татар энциклопедия сүзлеге. Казан. 2002.

*Мәкалә 2015 елда гуманитар фәннәр үсешенең милли программасы проектының бер өлешен тәшкил итә. «Naukowa edycja krytyczna pism rozproszonych Tadeusza Micińskiego w czterech tomach: eseje, liryka, publicystyka» (grant 1aH 15 0322 83, moduł Tradycja 1.a).*

***Марцин Байко,***
*Белосток университеты, Польша*

УДК 821.512.145-95

***А.Г. Хәлиуллина***

# ӘДӘБИЯТ ГАЛИМЕ СУФИЯН САФУАНОВНЫҢ ӘДӘБИ-ТӘНКЫЙДИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

В статье рассматривается литературно-критическая деятельность ученого, литературного критика и писателя С. Сафуанова. Выявлены основные направления и темы его исследовательской деятельности, оценен вклад ученого в изучение взаимосвязей национальных литератур, особенностей региональной татарской литературы Башкортостана в частности и татарской литературы в целом.

**Ключевые слова:** Суфиян Сафуанов, проблема взаимодействия национальных литератур, литературная критика, татарское литературное краеведение.

Танылган әдәбият белгече, галим, язучы Суфиян Сафуанов исеме татар һәм башкорт әдәбияты тарихында аерым урын били. Башлангычы уртак төрки тамырларга барып тоташкан ике халыкның әдәбиятын, аларның атаклы әдипләренең иҗади мирасын өйрәнүгә бар гомерен багышлаган олуг әдипне чын-чыннан «дуслык, туганлык җырчысы» дип атап була. Кешеләр белән аралашудагы зыялылыгы, үз принципларына тугры булып калуы, соклангыч хәтергә ия булуы, яңаданяңа ачышларга рухланып яшәве аны кабатланмас шәхес итте.

Суфиян Гаяз улы Сафуанов 1931 елның 2 октябрендә Башкортстан АССРның Туймазы районы Бикмәт авылында туа. Мәктәпне һәм Бөгелмә педагогия училищесын тәмамлаганнан соң, үткән гасырның 50 нче елларында Казан педагогия институтының тарих-филология факультетында белем ала. Илдар Юзиев, Хисам Камалов, Суфиян Поварисов, Ләбиб Айтуганов кебек киләчәктә татар мәдәнияте өлкәсендә зур казанышларга ирешәчәк шәхесләр белән бергә укый. Университетта уку дәверендә Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир, Салих Баттал, Нәкый Исәнбәт һ.б. атаклы әдипләрнең әдәбият, әдәби мирас турындагы чыгышларын тыңлап фикер туплый, әдәбиятка үз юлын яра. Студент елларында ук фәнгә ныклы тартылган С. Сафуанов 1954–1957 елларда аспирантурада укый.

1957 елдан С. Сафуанов язмышын Башкортстан белән бәйли. СССР Фәннәр академиясенең Уфа тарих, тел һәм әдәбият институтында фәнни хезмәткәр булып эшли башлый. 1960 елда яшь галимнең «Али Карнай. Тормыш һәм иҗат юлы» исемле беренче монографиясе басылып чыга һәм 1962 елда шушы тикшеренүләр нигезендә кандидатлык диссертациясе яклый.

Суфиян Сафуанов исеме әдәби тәнкыйть мәйданында XX гасырның II яртысында күренә башлый. Әдәбият тарихы, аерым әдәби күренешләр һәм язучы иҗаты хакындагы хезмәтләре башкорт һәм татар әдәби тәнкыйтенең алтын фондына кертелгән. 1967 елда – башкорт телендә, 1977 елда – рус телендә басылган

«Башкорт совет әдәбияты тарихы» дигән фундаменталь хезмәтне язуда төп авторларның берсе санала. 1990–1996 елларда дөнья күргән «Башкорт әдәбияты тарихы»ның 6 томлыгын әзерләүдә тынгысыз эзләнүләр алып бара, өченче томның җаваплы мөхәррире буларак катнаша. Басманың күпмилләтле совет әдәбияты тарихын яктырткан дүртенче томындагы 1972 елда (Мәскәүдә нәшер ителә) башкорт әдәбиятына караган бүлек тә С. Сафуанов тарафыннан язылган. Алты томлык «Татар әдәбияты тарихы»н әзерләүдә дә актив катнаша.

Бөек Ватан сугышында гомерләре өзелгән унөч яшь шагыйрьнең шигырьләрен вакытлы матбугат битләреннән җыеп, биографияләрен ачыклап, «Җыр сафта кала» (1960), кардәш халыклар әдәбияты үрнәкләреннән төзелгән «Сәлам сиңа, Башкортостан» (1984) җыентыкларын әзерләп бастыра. Суфиян Сафуанов, шулай ук, Башкортстан сүз осталарының Г. Тукайга багышланган истәлекләрен, мәкаләләр, әдәби әсәрләрен туплаган «Тукай Башкортстанда» (1966) җыентыгын төзи.

С. Сафуановның гыйльми эшчәнлегенең тагын бер юнәлеше – әдәби мирасны барлау, әдәби фактларга ачыклык кертү. Гайнан Хәйринең 1928 елда ук язылып, үз вакытында басылмый калган «Борылыш» әсәренең кульязмасын, соңрак язучының «Өчәүнең тарихы» повестын һәм берничә хикәясен гарәп язуыннан кириллицага күчерү эшен дә, Даут Юлтыйның «Кан» романының икенче кисәген табып, редакцияләп бастыру хезмәтен дә С. Сафуанов башкара. Әдәбият белеменең тарихи-теоретик фикер үсешенә сизелерлек өлеш керткән әлеге эзләнүләрне дәвам итеп, галим Әкрам Вәли, Суфиян Яхшыгулов, Шиһап Шәһәр, Хәсән Мохтарның югалган дип исәпләнгән әсәрләрен барлап бастыру эшен дә тормышка ашыра. Шуларга өстәп, ул М. Җәлилнең М. Галәү романнары турындагы мәкалә-рецензиясен, С. Рәмиевнең башкорт шагыйре Булат Ишемгулов шигырьләре җыентыгы кульязмасын анализлаган рецензиясен, М. Гафуриның югалган дип саналган «Адәм һәм Иблис» дигән поэмасын, архивлардан табып, фәнни әйләнешкә кертә. Әдәбият тарихында ачылмый калган фактларны торгызу, ак тапларны барлау галимнең игътибар үзәгеннән төшми.

Аерым язучы иҗатын җентекле өйрәнү – С. Сафуановның әдәби-тәнкыйди эшчәнлегенең мөһим тармагы. Язучы иҗатын бербөтен итеп күз алдына бастыра алу ягыннан «Али Карнай. Тормышы һәм иҗат юлы» (1960), «Ибраһим Гази. Язучы турында китап» (1968), «Әнвәр Бикчәнтәев иҗаты» (1971), «Гайнан Хәйри. Тормышы һәм иҗаты» (1983), «Җиһан буйлап караван кичте. Башкортстанның халык язучысы Әхияр Хәкимовның тормышы һәм иҗаты турында» (2009) китаплары әдәбиятның зур казанышы буларак бәяләнергә хаклы. Язучы иҗатын төрле аспектта өйрәнү, әсәрләрнең идея-эстетик асылын ачып бирү, һәр әсәрнең сәнгатьчә осталыгына анализ ясау – китапларның кыйммәтен тагын да күтәрә.

Милли әдәбиятларның үсеш закончалыкларын, үзгә сыйфатларын тирәнтен өйрәнү әдәбиятлар арасындагы бәйләнешләрне тулы күзалларга ярдәм итә. Татар, башкорт, рус әдәбиятларының үзара бәйләнешләрен өйрәнүгә зур өлеш керткән галим буларак С. Сафуановның күпсанлы хезмәтләре дөнья күрде. Мәсәлән, башкорт әдәбиятының көнчыгыш һәм көнбатыш әдәбиятлары белән дуслык, туганлык җепләрен яктырту уңаеннан «Вехи дружбы и братства» («Хаклык әдәбияты, дуслык әдәбияты», 1976), «Межнациональные связи башкирской литературы» (1979), «Хаклык әдәбияты, дуслык әдәбияты» (1981) китаплары, «Взаимосвязи башкирской литературы с литературами народов СССР» (1981) дип исемләнгән ике кисәктән торган библиографик күрсәткеч аның тарафыннан әзерләнеп нәшер ителә. Моннан тыш башкорт әдәбиятының татар, рус, украин, казакъ, үзбәк, кыргыз, литва, латыш, чуваш, мари, удмурт әдәбиятлары арасындагы иҗади йогынтысын ачыклауга багышланган күпсанлы мәкаләләре матбугат битләрендә дөнья күрә. Башкорт әдәбиятының башка тугандаш әдәбиятлар белән бәйләнешен тирәнтен өйрәнгән Суфиян Сафуанов башка галимнәр белән берлектә дә хезмәтләр бастыра. «Башкирия в русской литературе» басмасының 4, 5 һәм 6 томнарын әзерләүдә, Л.Н. Толстойның 175 еллыгына багышланган «Башкортлар мине беләләр һәм бик ихтирам итәләр…» (М. Рәхимкулов белән берлектә) мәкаләсен язуда һәм «А.С. Пушкин һәм Башкортостан» (Р.В. Паль белән берлектә) китабын төзеп бастыруда С. Сафуановның хезмәте бәяләп бетергесез.

С. Сафуановның башкорт балалар әдәбиятының әдәби-тарихи торышын яктырткан «Башкорт балалар әдәбияты үсеше проблемалары» (1986) монографиясе бу өлкәдә беренче хезмәт булып тора. Озак еллар әлеге хезмәт педагогик югары уку йортларында дәреслек итеп кулланыла һәм мәсьәләнең методологик нигезләрен ачыклаучы фундаменталь чыганак буларак бәяләнә.

Галимнең аерым язучыларның әдәбиятта тоткан урынын, әдәби шәрехләү закончалыкларын куллану үзенчәлекләрен, иҗат стилен осталык белән ачыклаган иҗади портретлары һәм этюдлары да бихисап. Татар һәм башкорт әдәбияты тарихында С. Сафуанов игътибар үзәгенә алган әдипләр арасында Кави Нәҗми, Фатих Хөсни, Нәкый Исәнбәт, Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов, Давыт Юлтый, Ибраһим Гази, Сәгыйть Агиш, Һади Такташ, Максуд Сөндекле, Хәниф Кәрим, Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Риза Ишморат, Габдрахман Әпсәләмов, Мирсәй Әмир, Илдар Юзиев, Әмирхан Еники, Ногман Мусин һ.б. исемнәр бар.

Соңгы елларда төбәктә барган әдәби процессларны өйрәнүдә, шунда яшәп иҗат иткән язучыларның тормыш юлын ачыклауда һәм әсәрләрен барлауда вакытлы матбугатны гаять әһәмиятле итеп күргән тикшеренүләр дә үткәрде. Ул Башкортстанда 1910 елдан башлап Бөек Ватан сугышына кадәр татар телендә

чыгып килгән яшьләр матбугатының тарихын яктырткан «Яшь көч»тән «Өмет»кә» (1998) исемле күләмле материал тәкъдим итте. Башкортстандагы татар вакытлы матбугатының барлыкка килү һәм үсү юлларын гәүдәләндергән «Башкортстандагы татарча гәзитләр тарихыннан» (2005), 1911 елда Троицк шәһәрендә чыга башлаган «Акмулла» исемле көлке журнал тарихына багышланган «Мәшһүр шагыйрь наменә» (2007) мәкаләләрен бастырды.

С. Сафуанов Язучылар берлеге әгъзасы буларак, иҗади оешманың эшчәнлегендә дә актив катнашып килде. Башкортстан Республикасы Язучылар берлеге каршындагы татар язучылары берләшмәсе идарәсе әгъзасы булды. Ул 1994 елдан «Тулпар» яшьләр журналының әдәбият бүлеге мөдире булып хезмәт итте, яшь иҗатчыларны үстерүгә зур өлеш кертте. Вакытлы матбугат битләрендә хәзерге татар әдәбияты үсешенә кагылышлы мәкаләләрен урнаштырды, башлап язучыларга киңәшләр бирде, әдәби әсәрләрне тикшерү һәм редакцияләү эшендә актив катнашты. Аның хәер-фатихасы белән күп кенә каләм тибрәтүчеләр вакытлы матбугат битләрендә әсәрләрен бастырды, яшь һәм башлап язучылар олы иҗат юлына чыкты.

С. Сафуанов үзен язучы буларак та сынап карады. Үсмер чагында туган ягы белән рухланып язылган беренче шигыреннән соң, төрле елларда кечкенә хикәяләр, очерклар белән бергә, күләмлерәк әсәрләрен дә вакытлы матбугат битләрендә бастырды. «Рәхилә үлгән карават» (1995), «Бикмәттәге хикмәтләр» (1999) һ.б. әсәрләре аны язучы буларак та тарихка теркәде. Суфиян Сафуановның иҗади мирасын тикшерү, аның кыйммәтен ачыклау әдәби тәнкыйть алдында торган бурычларның берсе булып кала килә.

1996–2003 елларда Башкорт дәүләт педагогия институтының (2000 елдан – университетының) татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире булып эшләде. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр туган тел һәм әдәбият укытучылары әзерләүдә катнашты, үзен мөгаллимлек хезмәтенә багышлады. «Кардәш халыклар әдәбияты», «Татар әдәбиятын Башкортстан белән бәйләп өйрәнү» уку курсларының фәнни-методик нигезен ачыклады, программалар төзеде, методик күрсәтмәләр язды һәм материаллар туплады. Шул уңайдан «Галимҗан Ибраһимов һәм Башкортстан» (2000), «Тукай һәм Башкортстан» (2000) кебек уку әсбапларын бастырды. «Зур абруйлы әдәби тәнкыйтьче, әдәбият белгече, педагог «Башкортстандагы татар язучылары» дигән китаплар сериясен чыгаруны нигезләде» [Исламов, б. 3]. Күренекле галим шулай ук, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов белән бергә, Гаяз Исхакый, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Мирсәй Әмир, Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еники һ.б. иҗатларындагы Башкортстан белән бәйләп торган үзенчәлекләрне, тарихи һәм әдәби фактларны ачыклауга күп көч салды. Шуның нәтиҗәсе буларак, ярты гасыр буена алып барган тикшеренүләрен гомумиләштереп, «Рухи күперләр» (2006) исемле китабын бастырды. Галим

чын-чыннан әдәбиятлар арасында мәдәни күпер сала алды. Үзе әйтүенчә, «Шундый көчләр барында заманның дуамал җилләре дә, тормыш дәрьясының кисәк кенә купкан дулкыннары да бу рухи күперне җимерә дә, какшата да алмас» [Сафуанов, б. 14]. Китапта урнаштырылган материаллар өч төркемгә бүлеп бирелгән һәм бай фактик материалларга нигезләнгән. «Дуслык хисе – йөрәк түрендә» дип аталган беренче бүлектә Башкортстаннан читтә туып-үскән язучыларның республика белән бәйләнеше өйрәнелә. Әлеге бүлектә Г. Тукай, Г. Исхакый, Һ. Такташ, М. Җәлил, Х. Туфан, К. Нәҗми иҗатларына тәфсилле анализ биреп, тирән гомумиләштерүләр ясый, яңа материалларны фәнни әйләнешкә кертә. «Туган туфрак тойгысы» бүлегендә Башкортстанда туып-үскән, әмма аннан читтә яшәгән әдипләр иҗатының туган як җирлегендә тамырлануын Г. Ибраһимов, С. Рәмиев, В. Солтанов, Ф. Кәрим, Н. Исәнбәт, М. Әмир, Ә. Ерикәй, Ә. Еники, Г. Кашшаф мисалында тулысы белән ачып бирә. Китапның өченче «Шагыйрьләргә Афинадан да бай» дип исемләнгән бүлеге Башкортстанда туып, шунда яшәп иҗат иткән татар язучыларының эшчәнлеген өйрәнүгә багышланган. Галим заманында әдәби-мәдәни үзәкнең берсенә әверелгән Уфа шәһәре белән бәйле күп кенә вакыйгаларны, шәхесләрне телгә ала, тирән тарихи-типологик анализ ясый. Шулай ук, илдә үзгәртеп кору чорында тернәкләнеп киткән татар әдәбияты вәкилләре А. Магазов, Ә. Гыйззәтов, Ф. Габдерәхим, М. Нәзиров, Х. Мөдәрисова, Ә. Әһлиуллин иҗатларына багышланган аерым мәкаләләр белән бергә, гомуми әдәби процессны анализлаган мәкаләләр дә тәкъдим итә һәм «кече күләмле әсәрләрне җентекләбрәк тикшерү киләчәктәге бурыч булып кала» [Сафуанов, б. 324] дип билгели. Хезмәттә Башкортстандагы татар әдәбияты торышына, исемнәре билгеле булган әдипләр С. Поварисов, М. Кәбиров, К. Кара, Р. Сабитов, Д. Булатова әсәрләре янәшәсендә әдәбиятка аяк басып килүче яшь каләм тибрәтүчеләр иҗатына да урын бирелә. Шуны да билгеләргә кирәк, галим фатиха биргән күп кенә каләмкярләр бүгенге әдәби процесста гомуми татар сүз сәнгатенең төп көчләре төсендә тәкъдир ителә. Китапның соңгы бүлеге галим С. Сафуановның «Башкортстан җирлегендә татар әдәбияты» дигән гыйльми тикшеренүләренең нигезен тәшкил итә. Әлеге юнәлештә ул студентларның һәм аспирантларның фәнни эшләренә җитәкчелек итте, яңа буын укучылар, галимнәр тәрбияләде, чын-чынлап үзенең фәнни мәктәбен булдырды. Хәзерге әдәби тәнкыйтьтә Ләйсән Кәшфи, Альбина Хәлиуллина, Рәүф Идрисов, Илдус Фазлетдинов, Дилбәр Булатова, Руслан Сөләйманов, Фәния Габидуллина һ.б. алып барган эшчәнлек – Сафуанов нигезләгән фәнни мәктәп нәтиҗәсенең күркәм чагылышы. Бүгенге көндә бу юнәлештә дистәләрчә фәнни мәкаләләр язылды, фәнни-гамәли конференцияләр үтте, конкурслар оештырылды, берничә уку әсбабы, фәнни-методик һәм әдәби-популяр китаплар

басылып чыкты. Шулай ук өлкән буын галимнәр Суфиян Поварисов, Рәиф Әмиров, Сәгыйдулла Хафизов һ.б. язган фәнни-тәнкыйди мәкаләләр Башкортстандагы татар әдәбияты үсешенә үз өлешен керттеләр.

Суфиян Сафуанов илдә үзгәртеп кору башланган чорда үзен талантлы журналист буларак та танытты. Республикада татар телендә чыгып килгән «Өмет» яшьләр газетасы, «Тулпар» журналын оештыруга күп көч салды. Шулай ук «Гасыр» газетасында басылган хәбәрләре, мәкалә-очерклары аның күпкырлы эшчәнлегенә бер дәлил [Амиров, с. 11].

Әдәбиятны ил күләмендә танытуга, башка милләтләрне дә милли казанышлар белән таныштыруга булышлык иткән күпсанлы мәкаләләре һәм язмалары «Большая советская энциклопедия», «Кыскача әдәби энциклопедия», «Әдәби энциклопедик сүзлек», «Лермонтов энциклопедиясе», «Башкортостан. Кыскача энциклопедия», «Татар энциклопедиясе» һәм башка әдәби белешмәлекләрдә урын алды.

С. Сафуановның әдәби-тәнкыйди эшчәнлеге хакында Г. Ломидзе, Г. Рамазанов, М. Рахимкулов, Г. Хөсәинов, Т. Таһиров, М. Гайнуллин, А. Әхмәдуллин, Р. Амиров, Ә. Харисов, Р. Шәкүр, В. Исхаков һ.б. үз фикерләре белән бүлештеләр. Күпкырлы талант иясенең рухи мирасын туплау юнәлешендә 2015 елда Рәиф Әмиров тарафыннан әзерләнгән «Бикмәттә дә таулар бар» китабы беренче талпыну булып тора.

Алда әйтелгәннәрдән мәгълүм булганча, С. Сафуановның гыйльми эшчәнлегенә тематик төрлелек, киң колачлылык һәм фикер тирәнлеге хас. Җитди фәнни мәсьәләләрне хәл итәргә алынган, төрле өлкәләрдә бердәй мәгълүматлы, энциклодепик белемгә ия, татар, башкорт, рус телләрендә иркен язучы эрудит галим бай рухи мирас калдырды. Ул «Башкортстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» (1981) дигән мактаулы исемгә лаек. 1963 елда Россия һәм Башкортстан Язучылар берлегенә әгъза булып кабул ителә. Башкортостан Республикасы Язучылар берлеге каршындагы татар язучылары берләшмәсе идарәсе әгъзасы булып тора. Әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен В.П. Бирюков (1988), Ә. Атнабаев (2001), Ф. Кәрим (2007) исемендәге премияләр белән бүләкләнә.

Суфиян Гаяз улы Сафуанов 2009 елның 30 ноябрендә Уфада вафат булып, туган авылында җирләнде.

**Әдәбият**

*Амиров Р.* Аксакал литературных наук: Суфияну Сафуанову в дни 75-летия открытое письмо-признание // Истоки. 2006. Вып. 46. С. 11.

*Исламов Ф.* Әдәбиятларның үзара бәйләнешен өйрәнүче // Кызыл таң. 2001. 10 ноябрь.

*Сафуанов С.* Рухи күперләр. Уфа: Китап, 2006. 376 б.

***Хәлиуллина Альбина Габит кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты*
*ahmali76@mail.ru*

УДК 821.512.145-21

*Р.Ф. Харрасова*

# «ЯҢА ТЕАТР ЭСТЕТИКАСЫ» ТӘҖРИБӘЛӘРЕННӘН: Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» драмасы

В идейно-эстетическом развитии татарской драматургии начала XX века особая роль принадлежит известному писателю, литературному критику и общественному деятелю Г. Ибрагимову. Тема революции определяет исходные принципы создания его историко-героической драмы «Новые люди». В пьесе масштабно раскрываются картины революционной борьбы деревенской бедноты за новое общество, величие самой эпохи и героика ее важнейших событий. Наиболее отличительными чертами пьесы «Новые люди» являются общественно-классовый конфликт, героический и оптимистический пафос, масштабность событий, массовость народных сцен, типичность образов, правдоподобие созданных картин, документальность, агитационность.

**Ключевые слова:** татарская драматургия, история татарской литературы, творчество Г. Ибрагимова.

Узган гасырның беренче яртыеллыгында бигрәк тә марксист язучылар иҗатында һәм фәнни эзләнүләрендә милли барышны социаль тарих кысаларында яктырту үзмаксат итеп куела. Әлбәттә, татарларда бу төр юнәлешләрнең башында Ш. Усманов, Г. Ибраһимов кебек инкыйлаби көрәшләргә тартылган көчле шәхесләр тора. Яралышы башында эстетик, аннан да бигрәк этик эчтәлекне алга куйган, әмма тора-бара иҗтимагый функцияләрен дә көчәйтеп җибәргән драматургиябез яңа шартларда булып узган һәм агымдагы иҗтимагый-тарихи вакыйгаларны чагылдыруга юнәлтелә, ул заман фәненә һәм җиңеп-ныгып барган идеологиягә нигезли. Иҗтимагый актив, сәясәт казанында кайнаучы драматурглар әлеге чорга кадәрге вакыйгаларны, Г. Ибраһимовның «Иҗтимагый-әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы»нда белдерелгәнчә, «заманча ысулларга» таянып анализлый, ә нәтиҗәләрен үзләренә яхшы таныш тормыш материалы аша әдәбиятыбызда чагылдыра.

Иҗтимагый-социаль вакыйгаларны, әдәби барышны 1917 елга кадәр дә даими яктырткан Г. Ибраһимов, егерменче еллардан башлап, әдәби хәрәкәтләр тарихын да иҗтимагый-сыйнфый нигезләргә салуны бурыч итеп куя һәм бер-бер артлы мәкаләләр яза башлый. Ул әдәбиятчыларга гына түгел, киң җәмәгатьчелеккә сүз сәнгате үсешендә кайсы һәм нинди дәвергә кергәнебезне, аның эчтәлеге нинди булырга тиешлекне аңлату эшенә зур көч белән керешә. Болар әдипнең мәкаләләренә куйган кайбер исемнәрдә дә чагыла. «Татар әдәбиятында өченче дәвер (Аңларга тырышыгыз!)», «Татарның соңгы тарихында өч дәвер (эпоха)

(“Аңлау” юллары)» һ.б. Тәнкыйтьче «Аңларга тырышыгыз, туганнар!»да бу хакта кистереп болай ди: «Без, коммунистлар, әдәбият мәсьәләсенә тик марксизм ноктасыннан гына килергә тиешле <…> Әдәбиятны марксизм үлчәвенә салу өчен, марксизмның үзен яхшы өйрәнү белән бергә, марксизмны татар тормышына татбикъ итә белергә, марксизм буенча татар тормышындагы мәсьәләләрне тәхлил кыйлу юлларын аңларга кирәк» (Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. 1978, V т., б. 392–393).

1917 ел һәм аннан соңгы вакыйгалар сәхнә әдәбиятыбызга сизелерлек эзен сала. Бер яктан, әлеге чорны тасвирлаган әсәрләр языла, икенче яктан, хәтта гаилә эчендәге, ир һәм хатын-кыз арасындагы һ.б. мөнәсәбәтләрне яктыртканда да, еш кына, мәсьәләргә инкыйлаби яссылыктан якын килenә. Мәдәнияткә бик нык тартылып киткән урта катламнарның гына түгел, гомумән чор хәрәкәтләрендә зур урын тота башлаган гавам тамашачысының заманны чагылдырган әсәрләргә ихтыяҗлы чагы бу. Шуны аңлап алган сәнгатькәрләрдә кинохрониканы үстерү, берьюлы күп кешегә адресланган фильмнар төшерү, театрлар санын арттыру һәм аларның репертуарларын заман ихтыяҗларын үтәүче әсәрләргә баету, спектакльләрдә массалар хәрәкәтен чагылдыру, кыскасы, театрга социаль-сәяси мәгънә бирү теләге уяна. Кино сәнгате әле үсеш алмаган чорда татарлар илгә, аерым кешеләргә, төрле социаль катламнар психологиясенә инкыйлаб алып килгән үзгәрешләрне, Яңа заманда массалар, фиркаләрнең социаль-иҗтимагый хәрәкәтләрен сәхнә сәнгате аша чагылдырырга мәҗбүр була. Шул ук вакытта Ш. Усманов оештырган шәһәр тамашалары, драматургларның күп геройлы әсәрләре, алар нигезендәге спектакльләр татар зыялыларын фильм төшерү сәнгатенә дә әзерли башлый – пьесалар билгеле бер дәрәҗәдә аларга сценарий язу нигезен дә бирә, әмма… монысы аерым тема.

Бигрәк тә егерменче еллардан башлап, Россиянең зур шәһәрләрендә кешегә үзенең кемлеген, кайсы социаль катламга караганлыгын төшендерерлек, инкыйлабны аңлатырлык героик драмалар шактый языла һәм куела. Г. Ибраһимовның вакыйгаларны киңләп иңләгән, монументаль характердагы «Яңа кешеләр»е дә – әлеге юнәлештәге эшләрнең берсе. Шул ук вакытта аны заман героен, инкыйлабка мөнәсәбәтле чынбарлыкны чагылдырган, яңа кыйммәтләрне алга куйган публицистик драма кысаларында да карарга кирәк.

Узган гасырның егерменче еллары – режиссерларның мәйдан театры турындагы хыяллары, әдәби геройлар тормышын кечкенә сәхнәләрдән урамнарга алып чыгарга, театрны агитация пафосы белән сеңдерергә омтылган чоры. Инкыйлабта миллионнар катнашырга тиеш булган кебек, сәнгатькәрләр тамашачының да һич югы меңнәр булуын тели. Җитмәсә, әдипләргә Октябрь вакыйгаларын шушы төр әсәрләр белән билгеләп узу вазифасы йөкләтелә. Шуңа җавап

рәвешендә, русларда 1920 елның 19 июнендә «Кышкы сарайны алу», бер көннән соң «Россияне блокадага алу» кебек тамашачыны да активлаштырган, хәрәкәткә тартып керткән, импровизациягә зур урын биргән театр тамашалары уздырыла. Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр»е, шулай ук, Октябрь инкыйлабының өч еллыгы уңаеннан иҗат ителә. Ул көтеп алына, бер үк вакытта Казанда да, Уфада да куела, театрлар тарихында зур вакыйга рәвешендә бәяләнә.

Г. Ибраһимов иҗтимагый тормышның алга барышында үзаңы үскән гади халыкка зур өмет баглый һәм, «Яңа кешеләр» пьесасы белән, аларны башкача яшәргә, бердәм көрәш фронтына кушылырга өнди. Әсәрнең, әлеге дә баягы агитацион рухын, ирекле композициягә корылуын, күренешләрдә катнашмаучы массаның зурлыгын, гайре табигый дәрәҗәдәге динамикасын кабул итмәүчеләр пьеса камилләшеп бетмәгән, сәнгатилеге түбән дип бәяләргә мөмкин. Әлеге сыйфатлар – «Яңа кешеләр»нең җитешсезлеге булмыйча, нәкъ менә публицистик пьесаларның иҗат ителү алымнарыдыр. Г. Ибраһимов драмасы ул төр әсәрләргә һәрьяклы җавап бирә һәм ул саналган сыйфатлары белән кызыклы, анализ өчен игътибарга лаек.

Инкыйлаби юнәлешләрнең башында торган һәм инкыйлаб темасын иҗатының төп юнәлешенә әверелдергән Г. Ибраһимов «Яңа кешеләр»дә, традицион драматургиядәге кебек, хыялында туган әдәби уйланмаларга зур урын бирми, ул бары тик үзе күргән, үзе дә катнашкан вакыйга-күренешләргә таяна, документальлекне эчтәлекнең ышандыргыч көче итә. Әдип әлеге әсәре белән яңага таба хәрәкәтнең котылгысызлыгын, шул юлдагы уңышларның кирегә кайтарылмаслыгын, каршы көчләрнең ахыр чиктә барыбер җиңеләчәкләрен раслый.

«Яңа кешеләр»дә тышкы каршылыклар, эчкеләренә караганда, алгырак позициягә чыга, бик нык калкуландырыла, конфликтта теләсә кайсы тамашачы таный алырлык, тормыштан алынган типлар катнаша. Болар – руханилар, авыл ярлылары, ялчылар, байлар, ак һәм кызыл командирлар, зыялылар һ.б. Әлеге социаль төркемнәрнең үз эчендә дә бүленеш бар, һәм инкыйлаби көрәш көчәеп китү, аның авылга да барып җитүе шартларында уртак социаль чыгышлы кешеләр фронтның капма-каршы якларына да басарга мөмкин. Әйтик, зыялылар арасында яшь, үткен мөгаллимә, дөньяга күзе ачылгач партиягә кергән Камәрне һәм милләтче татар зыялысы Әхтәм Банаевны күрәбез. Әдип милләтче героен, европача киеме, тотышы, сөйләме, уй-карашлары белән гомумхалык мәнфәгатьләрен гомуммилләтнекеннән өстен куючы «кызыл» партия эшенә баштанаяк чумган һәм икенче күренештә кыйналганганлыктан, йөзе яралы, канлы гимнастеркалы, иске яулык бөркәнгән кызның капма-каршысына куя. Дөрес, әсәр ахырында, ихласлыгы бик үк ышандырмаса да, заманалар үзгәргәнне аңлап алган Банаев та совет ягына чыга.

Г. Ибраһимов инкыйлабның кешеләр аңына зур үзгәрешләр алып килүен ачу өчен төп игътибарны 55 яшьлек Хәйри бай гаиләсенә юнәлтә. Әдип кайбер гаилә әгъзаларының инкыйлабчылар ягына күчүенең сәбәбе итеп, гаилә башлыгының карт хатыны Фәтхиягә, мәрхүмә кызына, аннан туып калган оныгына карата гаделсез, кансыз, туганлык хисләренә корылмаган мөнәсәбәтен атый. Чыгышлары белән байлар катламына карасалар да, үзләре белдергәнчә, асылда аларның һәркайсы – Хәйри байга бушлай эшләгән ялчы гына. Фәтхия карчыкның улы Вәли, яше утызларда булса да, дөньяның кая барганлыгын әлегә аңлап өлгермәгән һәм иҗтимагый тормышның элекке хәленә кире кайтуыннан саклана, шул ук вакытта ул әтисе йогынтысына да бик нык бирелгән. Хәйри байның Себергә качуы, Вәлинең аннан калган байлыкны саклап калуы инкыйлабның киләчәктә эчкә яшеренгән дошманнары булачакны, сугыш беткәннән соң, көрәшнең аларга каршы юнәлтеләчәген күрсәтә.

Инкыйлаби теманы ачканда геройларны үзара туганлык, әшнәлек, кода-кодагыйлык җепләре белән тыгыз үрү Г. Ибраһимовның прозасында еш күзәтелә. Ул бигрәк тә «Тирән тамырлар» әсәрендә көчле. «Яңа кешеләр»дә бу төр әдәби алымны куллану тамашачыны, сәхнәдә барган вакыйгалардан тыш, үзе һәм нәселе турында да уйлата, эшхәлләрнең хисси тәэсирен көчәйтә. Икенче яктан, ул аларга инкыйлабны кабул итүдәге кыенлыкларны аңларга, күңелләрендәге икеләнүне җиңеп чыгарга булыша. Г. Ибраһимов конфликтта кайсы як хаклы икәнлекне сәяси яктан да, кеше аспектында да чишә. Аның инкыйлаб батыры сыйфатында башкалардан калку тасвирланган Батырханы көрәш файдасына шәхси бәхетеннән тулаем баш тарткан аскетлардан түгел. Пьесада мәгърифәтчелек әдәбиятында күзәтелгән бик күп нәрсәләргә, эш-хәлләргә яңа күзлектән якын килenә. Батырханга Хәйри бай кызы Зәйния, атасы ризалык бирмәгәч,ябышып чыга. Батырхан мәгърифәтчелек әдәбияты геройларыннан үтә кыюлыгы, тәвәккәллеге, активлыгы белән аерылып тора. Ул хәтта котычкыч адымга барган: мәхәббәт өчпочмагын тудыруда катнашкан өченче герой Саткайның, хатыны хакында яман сүз тараткач, башын балта белән чапкан. Ир соңрак байларга ялгыз каршы торуның мәгънәсезлеген аңлаган һәм халык күтәрелешенә кушылган. Боларны күздә тотканда да кыю, намуслы, чибәр, әмма үз сословиесеннән булмаган кызга өйләнгән Батырханны мәгърифәтчелек әдәбиятындагы кайбер схематик иҗат ителгән «актан-ак», «сафтан-саф» персонажларга тиңләү дөрес булмас. Батырхан кебекләрнең үзаңы көчәйгәннән соңгы һәм гади халык аңлавындагы «аклыгы» исә дошманнарын каралту, конфликтны кискенләштерү өчен кирәк. Авыл ярлыларының әйдәманы булса да, Батырхан «туры юл»га зур эчке һәм тышкы каршылыкларны җиңеп баскан. Аның үрнәгендә Хәйри байның кызы,

оныгы, хезмәтчесе авыл ярлыларына кушыла. Әдип инкыйлабның киләчәген тормышка күзе яңа ачылып килгән Тимеркәй кебек яшьләрдә күрә дә.

Г. Ибраһимов пьесаны өч өлешкә бүлә. Пәрдәләр арасында без белмәгән, әмма чамалаган ниндидер хәлләр, вакыйгалар булып уза, авылга әле кызыллар, әле аклар бәреп керә, ул да булмый, илкүләм конфликт беренчеләренең җиңүе белән тәмамлана. Сюжет барышына әллә никадәр герой, социаль төркемнәр катнашса да, көнкүреш вакыйгалары тасвирланмый диярлек, көндәлек тормыш ваклыклары геройлар репликасында гына чагылып-чагылып ала. Шул ук вакытта пьесада инкыйлабка мөнәсәбәтле һәр хәл-күренешкә, вакыйгага зур игътибар бирелә. Драматург, бигрәк тә вакытны сикертү алымын кулланып, сәхнәгә гаугачыл массаларны кертеп, чор вакыйгаларының нинди кызу акканын, яшәешнең давылга охшап калганлыгын күрсәтә, шунлыктан Инкыйлаб образы үзе дә табигать катаклизмы, давыл белән тәңгәлләшә.

Пьесада катнашкан геройларның күплеге, социаль катламнарның төрлелеге, күренешләрнең еш алмашынуы, агымнар хәрәкәте, аларның көрәш һәм үч дәрте, фикер һәм хисләр көче Инкыйлабны тулыканлы күзалларга, масштаблылыгын аңларга гына түгел, ә монументаль стиль тудыруга да булыша. Югарыда әйткәннәрне дәлилләү йөзеннән, әсәрдә катнашкан геройлар санына да игътибар итик. Беренче пәрдәдә аларның саны – 17. Шуларның төп төркеме – үзара туганлык җепләре белән бәйләнгән Хәйри, Зөһрә, Фәтхия, Батырхан, Бибизәйния, Вәли, Тимеркәй. Яшь мөгаллимә Камәр белән Шәйбәк картка да конфликт оешуда күпмедер урын бирелә, эпизодик геройлар сәхнәгә зур массаның бер өлеше рәвешендә кертелә. Болар: Насыйб, Ярми исемле авыл егетләре һәм тәрәзәдән икмәк сораган кызылармеец Габдулла.

Икенче күренештә геройлар саны кискен зурая: алар 50 ләп. Араларында гражданнар канкоешында, ак чехлар белән сугышта кулына корал тотып катнашучылар бар. Инкыйлабка каршылар сафында алпавыт улын, студент, рус офицеры Андреевны, аның урынбасары, яшь татар прапорщигы, хәрби шурачы Галимовны, милли хәрби киемдәге чех сугышчысын, Аксак бояр Колинкинны һәм земский начальник Митри Степаныч Григорьевны, милләтче Әхтәм Банаевны күрәбез. Сан ягыннан алар инкыйлабның төп тарафдарларыннан әллә ни калышмый. Шул ук вакытта сәхнәне массовканы калыплаштыручы персонажлар басып китә. Боларның исемләнмәгәннәре: хатын-кыз, бала-чага, кулаклар, авыл ярлылары, аклар, кызыллар, ике яктан да күзәтчеләр, поплар, муллалар һәм рус, татар, мукшы байлары. Соңгыларының милләтен дә атап, тоткан динен чагылдырып, язучы, әйтерсең, яңа өчен көрәштә дошманның милләте мөһим түгеллекне, советка каршыларның һәр халыктан табылуын аңлата. Пьесаның тәүге күренешләрендә

төп урынны тоткан Вәли, Зәйния, Зөһрә, Фәтхияләр дә – бу пәрдәдә халык арасында гына. Инде кызылларның вакыйгалар барган авылда тулы җиңүе белән тәмамланган өченче өлештә персонажлар саны кими, дошман як төссезләнә, эш-хәлләрдә алардан Үтерүчеләр дип аталган авыл байларының уллары гына күренеп ала.

Зур көрәшләрне, батырларның канлы алышларын тасвирлаган борынгы драматургиядәгечә, «Яңа кешеләр» әсәрендә дини мифологиядән (бу очракта Коръәннән) интертекстлар, сакраль идеяләр еш урын ала, инкыйлаб театрлары стиленә хас булганча, әсәр ахырында көчле музыка (бу очракта «Интернационал») яңгырый. Соңгы күренештә, Батырханнар урамдагы маршка кушылып җырлап чыгып киткәннән соң, Әптерәш карт йортка керә дә кара көчләр үтереп ташлаган мөгаллименең йөзен ача, намазлыгын рәтли. Димәк, ул аңа ясин чыгачак. Шул вакытта тәрәзәдән хәйран булып карап торган Фәтхия карчык: «Ходаем, бар икән кодрәтең! Менә ничә атналар инде, көн үтәләр, төн үтәләр! Туплар! Кызыл әләмнәр! Илаһым, Хуҗам, кайдан килә, кая бара бу бәндәләрең?» – дип тәкърарлый.

Беләбез ки, Фәтхия карчыкның сүзләре – гасырлар дәвамында кешелекне борчыган мәсьәләләр. Һәр халык аларга мифлар, дини яисә фәнни тәгълимат аша үзенчә җавап бирергә омтылган. Г. Ибраһимов үзен дә борчыган әлеге проблемаларны чишкәндә марксистлар теориясенә таянган. Гомумиләштереп әйткәндә: тәүге адәмнәр, әйдәманнарына ияреп, тау куышларында яшәгән, кешелек җәмгыяте тора-бара императорларның үзе теләгәнчә һәм булдыра алганча хакимлек итүе чорына җиткән, хәзер исә хезмәт халкы, намуслы кешеләр бәхеткә, тигезлеккә, иреккә атлый. Драматург фәлсәфи проблеманы сюжет барышында чишкән булса да, сорауны пьеса ахырында яңгырата, җавабын ачык калдыра. Моның белән ул хакыйкать эзләүнең мәңгелек икәнлеген әйтергә тели. Шунысы да бар: әлегә Яңа тормыш хыялда гына яши, төзелмәгән, аны тәгаен күзаллау кыен; гомерләрен хезмәттә һәм Аллага табынып, байларга буйсынып уздырган миллионлаган Фәтхияләр, Әптерәш картларга ул Яңа тормышта урын булырмы, алар киләчәк үзгәрешләрне ничек кабул итәр – анысы да билгесез.

«Яңа кешеләр»нең максаты – массаларны марксистлар күзаллавындагы идеаллар белән таныштыру, килер чорларның уңай каһарманнарын күрсәтү. Шуларның үзәктәгесе – һичшиксез, Батырхан. Аның карашлары марксизм тәгълиматына нигезләнгәнлек ачык сизелеп тора. Әлеге карашлар, бер яктан, моңа кадәр хөкем сөргән сакральлеккә, дин юлындагы әйдәманнарны изгеләштерүләргә, Аллага табынуга һәм аның исеменнән җиткерелгән идеалларны, әхлакны алга сөрүгә каршы килә, советчылар алар каршысына яңа әйдәманнарны, яңа әхлакны, яңа идеалларны куя. Икенче яктан, кызыл көрәшчеләр изге китапларда тасвирланган гадел дөньяны, корал

алып, үз көчләре белән, тормышны анализлап, үзләре чыгарган нәтиҗәләргә нигезләнеп корырга һәм адәм балаларына өмет биреп торган җәннәтне дә җирдә төзергә тели. Инде алар мәгърифәтчеләр кебек дөньяны акыллы кешеләр ярдәмендә үзгәртүне дә хата дип таба. Әле кайчан гына кызылларның кайбер гамәлләрен кабул итмәгән Шәйбәк бераздан Батырханга: «Мин сиңа башта бик ачуланган идем. Инде фәкыйрь халык өчен тырышып йөрүләреңне күргәч, барын да кичердем. Хәзер сиңа гомер телим…», – дип белдерә. Димәк, гомере буе бер Аллага гына таянган суфи карт бер аягы белән шулай ук – «яңа кешеләр» ягында.

Текстның шактый зур урын алып торган сакраль катламы, нигездә, әлеге дә баягы авыл диндары Шәйбәк белән бәйле дә. Дөньяга дини күзлектән караган, Илаһи көч кодрәтенә ышанган Шәйбәк карт төрле эш-хәлләр вакытында борынгыларның сүзләрен, тәҗрибәсен искә ала, асылда дөньяның ничек һәм кая таба баруын, хәтта инкыйлаби хәрәкәтләрне дә Алла ихтыярында дип саный. Һәм ул агымдагы вакыйгаларга мөнәсәбәттә болай ди: «Өметсез – шайтан, дигән борынгылар… Аллаһ Тәгаләнең хикмәтен бер чех килеп кенә боза алмас, балалар… Ул явызлар үзләрен Нәмруд, Фиргавен урынына мендереп, безне бәни Исраил хәленә төшергәннәр иде…»

Инкыйлабка катнашучылар барысы да дини тәрбия, белем алган, димәк, иманлы һәм кешелекле булырга кирәклекне, кеше җанын алу Алла карамагында икәнлекне беләләр. Г. Ибраһимов начар һәм яхшы, түбән һәм югары, нәфис һәм җирәнгеч эстетик категорияләр белән эш иткәндә, аларның эчтәлеге заманга бәйле үзгәргәнне күрсәтә, коточкыч канкоешның күпчелек бәхете хакына булганда яхшы эш саналырга хаклыгын һәрдаим ассызыкларга тырыша. Икенче пәрдәдә Батырхан, Кызыл Армия гамәлләрен һәм үзен аклагандай, башта кеше җанын кыюга каршы булганлыгын, әмма, корбаннар күргәч, рухи ныгуын, моның кирәклеген аңлауга таба адым ясавын сөйли. Ул үзеннән сүз көткән халыкка: «Безгә дә, безнең эшче-крестьян халкына да контрреволюционерларның башлары өстеннән азатлыкка барырга туры килә… Башка юл юк...», – ди. Шул вакытта Шәйбәк карт Батырханны кан түгүдән сакланырга чакыра, чүп дип туфрактан алып ыргытканда, ашлыкны әрәм итәргә мөмкинлеген искәртә. Ике якның тигезсез бәрелеше вакытында нәкъ менә гөнаһсыз һәм дин кушкан кануннар белән генә яшәгән, халык изгеләштергән, һичкемгә зыяны тимәгән Шәйбәк карт үтерелә дә. Олы яшьтәге аксакалның үлеме бик символик. Ул узган чорларга нокта куйгандай. Шәйбәкнең җаны инкыйлабка каршы яклар тарафыннан кыелса да, бу факт иске кануннарның киләчәктә юкка чыгарылачагын сөйли һәм шул ук вакытта әлеге хәл кара көчләргә карата халыкта нәфрәт уятуны да күздә тота.

«Яңа кешеләр»дә мәгърифәтчелек драматургиясендәге

ак һәм кара геройларның этик пландагы көрәшен үзара кискен каршы куелган ике якның кеше ирене өчен көрәше алмаштыра. Сюжет үстерелешендә аерым бер геройлар күбрәк хәрәкәт итсә дә, шәхси тормышларына да пәрдә ачылгандай булса да, персонажларны гомумиләштереп, инкыйлаб яклылар һәм аңа каршылар дип карарга, ягъни әлеге төркемнәрне Революция һәм Контрреволюция төшенчәләре белән билгеләргә, зур фәлсәфи-символик образлар сыйфатында ачу таләп ителә кебек.

«Яңа кешеләр» инкыйлабтан соңгы драматургиядә традицион мораль-этик принципларның трансформациясе, ягъни инкыйлаби әхлакны алга сөрү күзәтелгәнне сөйли, чөнки анда ярлы халыкның, кызыл сугышчыларның теге яки бу «тискәре» гамәлләре иҗтимагый алга китеш һәм халык бәхете хакына дип күрсәтелә, гражданлык бурычы сыйфатында бәяләнә. «Яңа кешеләр», шулай ук, инкыйлаби-тарихи драмаларда жанр сыйфатларының байлыгын, ул төр әсәрләрнең күпмедер дәрәҗәдә очеркка тартымлыгын дәлилли. Пьеса массалар тартылган канкоешларның күплеге, бер үлемнең башка үлемнәргә китерүе, инкыйлаб чорындагы гаилә һәм социаль катламнар, аерым кеше кичергән фаҗигаләрне чагылдыруы белән трагедиягә, бигрәк тә «оптимистик трагедия»гә тарта башлый. Анда оратор сөйләменә, пафослыкка, патетикага, башка төр хисләргә зур урын бирелә, матәм һәм башка көйләр яңгырый, сәхнәнең арткы планында һәрвакыт күзәтүче, эш-хәлләргә мөнәсәбәт белдерүче гавам бар.

Г. Ибраһимов «Яңа кешеләр»дә халык һәм әйдаманнар, юлбашчылар арасындагы мөнәсәбәтләрне ачканда эксплуататор катламның Ленинга карата тискәре караштa торганлыгын да күрсәтеп уза. Әдип, шулай ук, массаларга барып ирешкән теге яки бу фикерләрнең гавамның үзен, аерым катламнарын кузгатып җибәрә алганлыгын аңлатырга тели. Халык массасында, социаль төркемнәрдә барган эчке үзгәрешләр сыйнфый каршылыкны кызыллар, ярлылар файдасына хәл итә. Пьесада нәкъ менә эчке барыш, халык күңелендәге кичерешләр, алар аңындагы күтелгән һәм кайчак күтелмәгәндә уяну драманың үзәк баганасын тәшкил итә.

Г. Ибраһимов, сәнгать экспериментны рәвешендәрәк иҗат ителгән «Яңа кешеләр»е белән «Яңа театр, яңа әдәбият эстетикасы»н алга сөрә һәм заман сәнгатендә шулай ук түнтәрелеш баруын сөйли. Әдип, нигездә, реалистик иҗат юлыннан атлаган татар театрының алга таба социалистик күазллауларга гына нигезләнеп яшәргә хаклылыгын расларга омтыла. Ул, актуаль-сәяси тема булган Искедән Яңага күчешне яктырткан пьесасын сәхнәләштергәндә, режиссер уйланмалары ярдәмендә кайбер персонажларны, әсәрдә җирлек ролен уйнаган һәм вакыйгалар масштаблылыгын чагылдыру максатыннан файдаланган исемсез массаны хәтта тамаша залына күчерергә мөмкинлекне дә күздә тоткандыр кебек.

«Яңа кешеләр» – чын мәгънәсендә яңа кешегә адресланган һәм аны тәрбияләүне күздә тоткан әсәр. Зур тарихи дәвер булып теркәлгән Инкыйлаб чорын тасвирлавына карамастан, кызганыч ки, шул заман агитациясе вазифасын үтәгәнлектән, пьеса кыска арада актауальлеген югалта, әмма яңадан туачак әсәрләргә сыйнфый көрәшне чагылдыруның, инкыйлаб вакыйгаларын сәхнә сәнгате аша марксистларча аңлатуның үрнәге булып тора, аларга социаль оптимизм, патриотизм рухы, билгеле бер дәрәҗәдә пафослылык биреп өлгерә. Г. Ибраһимов пьесасы алып килгән бөтенхалык көрәше пафосының орлыклары аннан соңгы драматургиядә, чыннан да, уңышлы туфрак таба. Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр»е социаль характерлы, чыгышлы, сыйнфый идеологияне көрәш коралы иткән, актив, шәхси тормышын арткы планга куйган, әмма бөтенләй үк онытмаган, эш-гамәлләре һәм карашлары ышандыргыч көчкә ия заман героен иҗат итүнең эстетик принципларын нигезләүгә юл сала. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, автор, билгеле бер дәрәҗәдә читкә ташлануына карамастан, инкыйлаби көрәш тарихын шактый тормышчан ача һәм инкыйлабны яңа гадел җәмгыять төзү идеясе белән аклый.

***Харрасова Рифә Фатхрахман кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Ф.И. Габидуллина***

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ЯШЬ ЙӨРӘКЛӘР» РОМАНЫ: ЖАНР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Конец XIX и начало XX веков запечатлелись в истории татарской литературы, как время поиска новых стилей и жанров, способных художественно высветить пробуждение национального самосознания татар, начавшуюся борьбу за освобождение от духовного застоя. В результате этого в прозе стремительно возрастает интерес жанру романа. В статье исследуются авторские поиски и литературное творчество в данном жанре талантливого писателя, выдающегося человека и ученого Галимджана Ибрагимова (1887–1938).

**Ключевые слова:** Г. Ибрагимов, начало XX века, литературные жанры, роман.

XIX йөз ахыры халкыбызның милли үзаңы уяну, татарларны рухи торгынлыктан азат итү өчен башланган көрәшне яктырту өчен яңа ысул һәм жанрлар эзләү дәвере буларак билгеле. Нәтиҗәдә прозада роман жанрына игътибар арта. Бу хәл татар әдәбияты алдына яңа заман куйган мөһим бурычларны әлеге жанр өлкәсендә зур тәҗрибә туплаган Европа әдәбиятларындагы кебек үк роман ярдәмендә уңышлырак башкару мөмкинлегенә инану белән дә һәм, бер үк вакытта, бу форманың Көнбатышка йөз тота башлаган укучылар белән язучылар өчен күпмедер дәрәҗәдә модага әверелүе белән дә бәйләнгән иде [Габидуллина, с. 50].

Шундый каршылыклы һәм катлаулы иҗтимагый-социаль шартларда XX йөз башы татар әдәбиятында роман жанрының төп вазифасын һәм үсеш юлын үз иҗаты белән күренекле шәхес, талантлы язучы һәм галим Г. Ибраһимов (1887–1938) дәвам итә. Әдипнең иҗат мирасында роман жанры аерым урын алып тора. Аның безгә роман жанрында иҗат иткән дүрт әсәре мәгълүм. Әдипнең роман жанрында беренче тәҗрибәсе булган «Яшь йөрәкләр» 1913 елда дөнья күрә. Аннары бер-бер артлы «Безнең көннәр» (1920), «Казакъ кызы» (1924) һәм 1928 елда бүгенге көндә күп төрле бәхәсләргә сәбәпче булган «Тирән тамырлар» романнары басылып чыга. Әдәби иҗатның төп бурычын халыкка һәм җәмгыятькә хезмәт итүдә күргән Г. Ибраһимов әлеге жанр хакында болай дип яза: «...бигрәк тә романнар, кызык өчен, укып, көлеп тә ахырында ташлар өчен генә язылмый һәм язылмаска тиеш. Анда мөхәррирнең әйтергә теләгән бер уе, күрсәтергә теләгән бер күренеше, халык һәр көн күреп, сөйләп тә сизми кичкән мөһим вә хас бер мәгънә була» [Ибраһимов, 1960, б. 67]. Әдәби әсәр чорның иҗтимагый таләпләренә җавап рәвешендә дөньяга чыга. Г. Ибраһимов «хәят белән реаль әдәбият арасындагы мөнәсәбәтне

художество әсәрләрендә чорның актуаль проблемалары яктыртылуда күрә дә» [Нуруллин, б. 6]. Шундый катлаулы проблемаларны яктырту өчен әдип нәкъ менә роман жанрын сайлый. Әдәбият галиме Х. Хәйринең Г. Ибраһимовны «...язучыларның әдәби оста галиме һәм романнар остасы» дип ассызыклавы да очраклы түгел [Хәйри, б. 137]. Бәхәссез, тормышны танып белү, герой характерын һәм аның эволюциясен күрсәтү өчен роман иң кулай жанр.

Әдәбият галимнәре «язучының роман жанрына мөрәҗәгать итүен революцион күтәрелеш елларында әдәбият алдында торган бурычларның зурлыгы, аның художество осталыгының үсүе» белән дә аңлаталар [Гыйләҗев, б. 142].

Алга таба без «Яшь йөрәкләр» романына киңрәк тукталырбыз. Әдәбият галиме Д. Заһидуллина билгеләп үткәнчә, әлеге әсәр «...XX йөз башында иҗат ителгән олы эпик жанр үрнәкләре арасында фәлсәфи характеры белән аерылып тора. Сюжет бирелеше белән ул шулай ук үз чоры тормышын тергезә» [Заһидуллина, б. 8]. Роман өчен алынган материал композицион яктан җыйнак итеп бирелгән. Сюжет хәрәкәтендә өстенлекне үзәк геройлардан Җәләш мулла, Зыя, Сабир һәм Мәрьямнең рухи үзгәрешләренә нигезләнгән борылыш тәшкил итә. Образларның үсеш-үзгәрешен күрсәтү максатыннан әдип аларны төрле көтелмәгән ситуацияләргә куеп тасвирлый һәм бу вакыйгалар аларны төрле яклап ачуга хезмәт итә.

Әдәбият галиме М. Хәсәнов «Яшь йөрәкләр»нең жанры ягыннан психологик роман булуын билгели, һәм биредә «...иҗтимагый әһәмиятле мәсьәлә геройларның тирән, психологик кичерешләре аша сурәтләнгән», – дип яза [Хәсәнов, б. 343]. Күренекле тәнкыйтьче, әдәбият галиме Җ. Вәлиди дә үз вакытында романның нәкъ менә романтик рухлы һәм психологизм белән сугарылган булуына игътибар итә: «Галимҗан әфәнде монда кирәгеннән артык шәхси һәм лирик (эчке шагыйрь) булып күренә шикелле. Ул, тормышның иң ачык күренеп торган ноктaларыннан бигрәк, үзенең хыялындагы ялтыраган образларны күрсәтә» [Җәләй, 1913, 28 февраль].

«Яшь йөрәкләр» романының үзәгендә искелек белән яңалыкның көрәш вакыйгалары тасвир ителгәннәр: «...мөхәррирнең романда күрсәтергә теләгән төп идеясе – иске тормыш белән сәгадәткә ирешергә ашкынган яшь тормышның көрәшен күрсәтү» [Сәйфи-Казанлы, б. 50]. Иске тормыш вәкилләре: Җәләш, Гәрәй мирза һәм аларның якыннары; яңа тормыш төзергә омтылучылар: Сабир, Зыя, Госман, Сәлим һәм Камилә кебекләр. Гадәттә романның конфликтын аталар белән балалар арасындагы каршылыкка кайтарып калдыралар, әмма бу аның идея-эстетик кыйммәтен тарайту булыр иде [Ибраһимов, 2002, б. 9]. Романда гомумән татар халкының хәле, милләт язмышы һәм анын киләчәге мәсьәләсе дә күтәрелгән. Ул татарның патша хакимияте алып барган

колониаль сәясәте шартларында яшәвеннән тирән ризасызлык, милли азатлыкка омтылыш рухы белән сугарылган. Болар – һәммәсе шәхес иреге таләбе аша чагылдырылган.

Романда Зыя образы аерым игътибарга лаек. Язучының уңай идеалы образда гәүдәләнгән, әсәрдәге башка әдәби каһарманнар аңа мөнәсәбәттә бирелгән, барлык вакыйгалар аның тирәсенә тупланып сурәтләнгән. Зыяның төп хасияте – музыкаль сәләт иясе булуында. Бу сыйфат аның сабый чагында ук беленә һәм үсә барган рухи ихтыяҗларының эчтәлеген, юнәлешен билгели. Аңа татар көйләрен ишетү, кубыз яки гармун уйнау – яшәү өчен зарури булган мөһим шартларның берсе. Ләкин рухи ихтыяҗлары ул яшәгән тормыш белән каршылыкка керә, музыкага булган омтылышларын канәгатьләндерү өчен шартлар аның өендә дә, мәдрәсәдә дә, гомумән, татар дөньясында юк.

Зыяның рухи ихтыяҗларына, идеалларына каршы килә торган төп көч башта аның этисе Җәләш мулла образында гәүдәләнә. Ул – кадими карашлы гаилә башлыгы. Әдип аның шөһрәт сөю сыйфатын аеруча калку итеп сурәтли. Җәләшнең нәсел-нәсебе бик мәшһүр булган. Әмма аның үзендә ата-бабаларындагы зурлык та, абруй да юк. Бары тик аларның күләгәсе генә бар. Нәкъ менә шул аңа тынгылык бирми. Ул башта зур шәһәрнең беренче мәхәлләсенә мөдәррис булу турында хыялланган. Ләкин тормыш шартларының комачаулавы аркасындамы, башка сәбәптәнме, моңа ирешә алмаган. Бары тик авыл мулласы гына булып калган. Аның шөһрәт сөючән табигате бу хәле белән, әлбәттә, килешә алмый. Ул хәзер үзе ирешә алмаган максатка уллары ирешер дип өметләнә.

Ләкин роман сюжетыннан күренгәнчә, XX гасыр башында татар тормышы инде нык үзгәргән. Җәләшнең карашлары улларының карашына туры килми, аның идеаллары хәзер Зыя һәм Сабир кебек яшьләргә идеал була алмый. Ә Зыя образы нинди характер сыйфатына ия соң? Аның максаты, яшәү идеалы – туган халкына хезмәт итү, аны газаплы тормыштан коткару, азатлыкка чыгару. Ул үзе музыка җанлы шәхес булганлыктан, халыкны бәхетле итүче төп көчне дә музыкада күрә. Аның уенча, музыка халыкның аяныч хәлен аның үзенә аңлатып бирәчәк, аңарда якты киләчәк өчен көрәш утын кабызачак. Ул шуңа күрә музыкаль хисләрен туган халкына җиткерү, күңелендәге музыканы халык күңеленә салу һәм шуның аркылы аның язмышын җиңеләйтү турында уйлана. Ләкин Зыя үзенең күңелендәге музыкаль ялкынны, изге теләкләрне халыкка җиткерә алмый. Чөнки аңа музыкаль тәрбия бирелмәгән, татар дөньясында аның өчен шартлар да юк. Бу образда табигый талант белән иҗтимагый халәт һәм гаилә тәрбиясе арасындагы тәңгәлсезлек, каршылык чагылган. Г. Ибраһимов Зыя шикелле рухи тормыш өчен яратылган шәхесләргә татар дөньясында хәтта беренчел шартлар юклыгын күрсәтә.

Романны укыгач, урынлы сорау туа: үзенең рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерергә омтылган шәхес гаеплеме, яисә моның өчен тиешле шартларны тәэмин итмәгән тормыш гаделсез корылганмы? Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларның бөтен асылы соңгысын раслый. Әнә аның иң калку гәүдәләнеше: «Менә тормыш! Менә синң хөррияте шәхсия! Яшәргә уйлыйсың, бәхет эзлисең! Бар да әрәмгә! Бар да юкка!.. Имеш, музыка хәрам! Җыр хәрам!... Син безне хәят өчен яратмагансың, син безне туган көнебездән алып авыр трагедия эченә ташлагансың!.. Безгә хәят кирәк, безгә ирек кирәк... Бу теләкләрнең барысын да син үзең биргәнсең. Ләкин мохит моңа каршы бара. Тормыш безне кыса, безнең пакь вә гали теләкләребезгә, мәгъсүм тойгыларыбызга гөнаһ дип карый...» [Ибраһимов, 2002, б. 115]. Бу юллар Россия империясенең татар халкын шундый аяныч хәлгә китергән милли колониаль системасына ләгънәт булып яңгырыйлар. Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларны тиешле эзлеклелектә ахырына кадәр дәвам иттерсәң, татар тормышын, аның Россия империясендәге социаль-сәяси хәлен тамырдан үзгәртеп кору кирәк дигән нәтиҗә килеп чыга. Зыя образына йөкләнгән идея-эстетик мәгънә әнә шуннан гыйбарәт. Әмма авторның уңай каһарманы мондый зур эшкә әзерме соң? Һич юк. Чөнки ул «сүлпән шәхес, җанлы иҗтимагый эшчәнлеккә сәләтсез, татар дөньясындагы гаделсезлекне күреп, газап чигүче генә. Аның ихтыяр көче дә, романтик идеалларының реаль тормышта социаль-сәяси таянычы да юк, язмышы аяныч...» [Ибраһимов, 1974, б. 10]. Зыяның язмышы аның мәхәббәт фаҗигасе белән бергә үрелеп сурәтләнгән. Уңай каһарманның хыялый булуы, гамәли эшкә сәләтсезлеге аның мәхәббәтендә дә чагыла. Аның яшәеш мохите дә тар. Сабый чакта ук аңа «мужик» малайлары һәм кызлары белән аралашырга рөхсәт ителми. Ул әнисе куенында гына үсә, авылда торса да, андагы тормышны белми, аның кешеләре белән аралашмый. Зыя белән сабый чактан ук бергә уйнап үскән бердәнбер бала – Гәрәй мирза кызы Мәрьям була.

Мәрьям – нечкә күңелле, кайнар йөрәкле, хыял белән яшәүче бер туташ. Әтисе аны, «аздырудан куркып», гимназиягә дә бирмәгән. Ул «Гәрәй мирза хәрәмендә», әнисе кочагында, «Әлфе ләйлә вә ләйлә» әкиятләрен, мәхәббәт романнарын укып кына үскән, аның хыялын шулар азыкландырган. Яшьтән үк Мәрьямгә авыл кызларыннан өстенлеген әйтеп, «Мәрьям туташ» дип тукып торганнар. Туташ авылда үссә дә, Зыя кебек үк, авыл тормышын белми, белергә дә теләми. Ул шул тормыш эчендә, әмма аның «матдилегеннән», «тупаслыгыннан» әллә никадәр югары тора. Зыяның Мәрьямгә булган мәхәббәтендә шәхес азатлыгы, рухи ирек идеяләре гәүдәләнгән. Галимә Р.А. Минһаҗева билгеләп үткәнчә «...әсәрнең гашыйк каһарманнары Зыя белән Мәрьям төрле психологик халәтләрдә биреләләр»

[Минһаҗева, б. 129]. Ләкин романтик мәхәббәт чынбарлык кануннары белән килеп бәрелешә. Зыяның солдатка алынуы аның язмышын хәл итә. Әлеге образларда шәхес белән яшәеш арасындагы каршылыкның бер төрле чишелеше бирелсә, Сабир образында ул башкача хәл ителгән. Зыя шикелле үк, Сабир да Җәләшнең карашлары белән риза түгел. Ул да әтисе күрсәткән юлдан барырга теләми, аның идеалларын кабул итми, татар дөньясының иске тормыш нигезләренә каршы чыга. Бу яктан ул Зыя белән бергә бара. Ләкин идеал мәсьәләсендә Зыядан аерыла. Ул халык язмышы турында борчылмый, аны газаплы тормыштан коткару хакында уйланмый. Аңа шәхси иминлек кирәк. Шәхес белән чынбарлык арасындагы каршылыкны ул башкача хәл кыла: шәһәрне ташлап, ерак бер авылга, «мужик арасына» яшәргә китә. Шәһәр ыгы-зыгысыннан туйган Сабир рухи тынычлыкны җиргә һәм үз аты белән сабанына хуҗа булуда таба. Ул шунда үзенә оя корып, тыныч яшәргә омтыла. Асылда ул татар авылында XX гасыр башында барлыкка килгән яңа катлауны чагылдыра.

Роман жанрының үз кануннары, үзенчәлекләре, таләпләре бар. Әмма кануннар романчыдан бертөрлелекне таләп итмиләр. Алар әдипнең индивидуаль стилен, иҗади йөзен ачарга чикләнмәгән мөмкинлекләр бирә. Г. Ибраһимов үз романында тормышның бер өлешен шактый җентекләп тасвирлый. Ваклап сурәтләү, хикәяләү әдипнең, гомумән, үзенә хас иҗат ысулы.

Югарыда әйтелгәнчә, романчы сурәтләү материалы итеп шул чор өчен гыйбрәтле күренешне ала. Әсәрнең телендә әдипкә хас ике үзенчәлекне тоемларга мөмкин, аеруча шушы ике элементның үрелеп баруы күзгә ташлана. Беренчесе – интим хисләрне тасвирлауда кулланыла торган җылылык, нәфислек; икенчесе – тормышның авыр якларын сурәтләгәндәге кырыслык. Мондый төр сурәтләүләр нәкъ менә әсәрнең реалистик юнәлешен билгели дә инде. Романда диалог формаларын төрлеләндерүгә һәм эчке монологларга да киң урын бирелә. Нәтиҗәдә «Яшь йөрәкләр» романы XX гасыр башы татар прозасының эстетик тәэсир көче артуына, сурәтләү чараларының баюына, камилләшүенә дә ярдәм итә.

И. Нуруллин «Яшь йөрәкләр» романының иҗат методын ачыклап, «романтизм принципларында торган хәлдә, реалистик сурәтләү алымнары белән баюын күрсәткән әсәр» дип билгели [Нуруллин, б. 117]. Бу хәл язучыны образлар иҗат итүдә яңа алымнар эзләүгә китергән. Әсәрдә геройлар яшәгән мохитне, социаль шартларны сурәтләүгә шактый зур урын бирелә. Язучы төп образларны иҗат иткәндә типик һәм шәхси сыйфатларның берлегенә ирешергә тырыша. Кыскасы, «Яшь йөрәкләр» романы кеше белән җәмгыять, шәхес белән тирәлекнең бәйләнештә булуын, характерның иҗтимагый шартлар тәэсирендә формалашуын раслый. Әсәрдә романтизм иҗат методы

өстенлек итсә дә, ул реализмга хас сурәтләү чаралары белән үрелеп бирелә.

Шушы рәвешле, Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы XX йөз башы татар әдәбиятындагы роман жанрын, җәмгыятьтә барган үзгәрешләргә мөнәсәбәттә, яңа форма, яңа эчтәлек белән баетты.

**Әдәбият**

*Габидуллина Ф.* Проблемы изучения жанровой природы татарского романа // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота. Ч. I. № 7 (25). 2013. С. 49–51.

*Гыйләҗев З.З.* Г. Ибраһимовнын «Яшь йөрәкләр» романында цензура бәяләмәсе // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 156–159.

*Заһидуллина Д.* Язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе // Мәгариф. 2012. № 2. Б. 6–9.

*Ибраһимов Г.* Әдәбият мәсьәләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. 244 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 1 т. 510 б.

*Ибраһимов Г.* Яшь йөрәкләр: сайланма әсәрләр. Казан: «Хәтер» нәшрияты (ТаРИХ), 2002. 543 б.

*Минһаҗева Р.Ә.* Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» әсәрендә романтик бакча мотивы // Г. Ибраһимов мирасы һәм төрки дөнья: Г. Ибраһимовның тууына 125 тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (17 апрель, 2012 ел) . Казан, 2012. Б. 129–130.

*Нуруллин И.* XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1966. 427 б.

*Сәйфи-Казанлы Фатыйх.* «Яшь йөрәкләр» (Тәнкыйть) // Хокук вә хәят. 1913. № 3. Б. 49–54.

*Хәйри Х.* Тарихи роман жанры // Метод, стиль, жанр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. Б. 125–142.

*Хәсәнов М.* Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 3 т. Б. 338–358.

***Габидуллина Фәридә Имаметдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*Алабуга институты доценты*

УДК 821.512.145-32

***Р.Ә. Минһаҗева***

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ТАТАР ХАТЫНЫ НИЛӘР КҮРМИ» ӘСӘРЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ ВАРИАНТЫНА БЕР КАРАШ

В повести «Судьба татарки» (1910) Г. Ибрагимов ярко высветил проблему социальной и духовной дискриминации женщины в татарском обществе. Главная героиня повести Гульбану, рожденная для любви и семьи, оказавшись в положении женщины-рабыни, вынуждена бежать из семьи, от злой свекрови, ненавистного мужа, в конечном счете и от своего женского начала. Однако Г. Ибрагимов вслед за своими наставниками Ж-Ж. Руссо, Л. Толстым доказывает, что нарушение естественной гармонии не делает человека счастливым. Автор считает, что лишь в равенстве, естественном разделении социальных ролей татарская женщина может обрести подлинное счастье.

**Ключевые слова:** естественные права человека, дитя природы, гисъянизм, гендерное равенство, романтическое бунтарство, утрата природного естества, освобождение женщины.

Галимҗан Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» (1909, 1910) әсәренең Октябрь инкыйлабына кадәр иҗат ителгән беренче романтик варианты укучылар аудиториясенә нибары 2003 елны гына килеп иреште [Ибраһимов, 2003]. Ә бит, Ф. Мусин искәртүенчә, «революциягә кадәрге татар дөньясын объективрак сурәтләү ягыннан нәкъ менә беренче вариантлар игътибарга лаек, чөнки ул вакытта әдип әлеге дөньяны гомуммилли позициядән торып яктырта, шунлыктан аның турында дөресрәк фикер йөртә» [Мусин, б. 14].

1929 елда әсәрнең төзәтелгән, өр-яңа сюжетка корылган, социалистик реализм принципларына таянган ахыргы варианты чыккач, кызганыч, беренче басма арткы планга чигенә, «сәнгатьлелеге ягыннан бик зәгыйфь эшләнгән», иҗатының таңы – өйрәнчек чорда язылып, совет чоры әдәби эшчәнлегенә әзерлек ролен генә үтәрлек дәрәҗәдә була.

Бу мәкаләнең максаты – Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәренең беренче вариантына күзәтү ясау, повестьның әдәби-эстетик табигатен ачу.

Әсәр 1909 елда Уралның Миасс заводында язылып, тәүге тапкыр 1910 елда Башкортстанның Стәрлетамак шәһәрендәге «Нур» матбагасында дөнья күрә. Бу повесть (әмма шул чор әдәбият белеме кануннарына таянып, автор аның жанрын роман дип билгеләгән һәм I басмада ул роман буларак күрсәтелә) әдип иҗатының романтик чорына караган беренче күләмле әсәрләреннән санала.

Г. Ибраһимов бу әсәренә җирлек итеп, XIX гасырда халкыбыз арасында киң таралган, халыкара сюжетка корылган «Җиде кыз» бәетен алган. Хәтерләсәк, бәеттә җиде татар кызының

ирләр киеме киеп, туган җирләреннән качып китүләре һәм бер мәдрәсәдә укып белем алу мажаралары сурәтләнә. Повестьның кереш өлешендә автор татар хатын-кызларының, коллык газапларына түзә алмыйча, нәнә шул «Җиде кыз» бәетендәгечә, ирләр булып киенеп яшәргә мәҗбүр булулары хакында искәртә: «Шул ачы хакыйкатьне мин үзем ике мәртәбә очраттым: берсе – Стәрлетамак өязендә, икенчесе Оренбургта булып, һәр икесе дә егерменче гасырдадыр. Стәрлетамак өязендәгесен тикшергәннән соң, кулыгызга менә шул сәхифәләр каралады» [Ибраһимов, 2003, № 4, б. 81]. Бөек Октябрь инкыйлабыннан соң язылган «Татар хатынының тарихи үсүе» исемле мәкаләсендә ул: «Бу әкият имәс, ул – хәкыйкать. Миңа үзем, авыр язмышка түзә алмый, ир булып качкан хатын фаҗигасенең эчендә булырга туры килгәне бар» [Ибраһимов, 1984, б. 218], – дип яза.

Шунысын искәртергә кирәк, XX гасыр башы татар хатын-кызларының үз язмышлары белән килешеп, газап чигеп яшәүләрен дәвам иткән чор өчен сюжет артык романтикалаштырылган, сирәк очрый торган күренеш булып каралырга хаклы.

Повесть саф романтик кимәлдә иҗат ителгән. Анда «табигый кеше», рухи хөрлек, шәхес азатлыгы, хатын-кыз бәхете мәсьәләләре француз философы Ж.-Ж. Руссодан килә торган карашлар тәэсирендә бирелә.

Үзәк каһарман Гөлбану романтик герой буларак сурәтләнә. Француз романтизмы буенча галим Д. Обломиевский романтик каһарманны түбәндәгечә характерлый: «Романтический герой – это человек беспокойный, взволнованный, ищущий, не примиряющийся с существующим, устремленный к новому, враждебно относящийся ко всему застойному и косному» [Обломиевский, с. 5]. Образ тудыруда гареб романтизмы алымнарын да иркен кулланган Г. Ибраһимовның төп каһарманы Гөлбануга романтик геройны характерлаучы барлык сыйфатлар да хас.

Әсәрдә Гөлбануның тормышын шартлы рәвештә өч этапка бүлеп карарга була: I. Балачак, үсмерчак. II. Хатынлык – коллык еллары. III. Ир-Габдулла булып яшәгән чоры.

Гөлбану – Нурый карт белән Фәтхия карчыкның уллары арасында бердәнбер кыз бала. Автор, Гөлбануның балачак-үсмерчак чорын сурәтләгәндә, руссоистларча, аның чын мәгънәсендә «саф табигать баласы» булуына басым ясый. Мәсәлән, кызның, табигать үзе тудырган балчык, туфрак, таш, агач кебек табигый материаллар белән яисә үз куллары белән ясаган уенчыклар белән көннәр буе рәхәтләнеп уйный алуы безнең игътибарны Ж.-Ж. Руссоның педагогик өйрәтмәләренә юнәлтә: «Серебряные, золотые, коралловые бубенчики, граненый хрусталь, всякой цены и всякого вида погремушки – сколько бесполезных и гибельных приборов! Ничего этого не нужно – никаких бубенчиков, никаких погремушек! Маленькие древесные ветки, с плодами и листьями, головка

мака, в которой гремят зерна, солодковый корень, который ребенок может сосать и жевать, будут забавлять его столько же, сколько эти великолепные безделушки, и будут хороши тем, что не станут приучать его к роскоши с самого рождения» [Руссо, 1961, с. 67]. Гөлбануның киенүенә килгәндә, бар нәрсәсе дә купшылыксыз: өстендә гади бер күлмәк, башын да яулык-фәләнгә яшерүнең кирәге юк, аягына да чабата-оек киеп мәшәкатьләнмәскә була. Кызның үсеше дә авыл кешесенең табигый тормыш барышына көйләнгән, хезмәткә өйрәнү дә, яшь үзенчәлеген искә алып, җиңел генә, уен кебек башкарыла. Ун яшьтә ул инде өй эчендәге вак-төяк хезмәтләрне башкара башлый, кул эшләреннән тегәргә, бәйләргә, чигәргә өйрәнә, 13–14 яшьләреннән киндер сугарга керешә. Нәкъ менә бу вакыттан ул да, башка авыл кызлары кебек, зур дикъкать һәм осталык белән үзенә бирнә әзерли башлый, гаилә тормышында кирәк булачак һәр эшкә өйрәнеп калырга омтыла.

Гөлбануның тырышлыгы, эшкә уңганлыгы, авылда иң алдынгы кызлардан саналуы «өмә»ләрдә күренә. Кызның, нәрсәгә алынса да, беренчелекне бирмәгәнен күрсәтү максатыннан, автор бик теләп әсәр тукымасына ел фасылларына бәйле рәвештә халкыбызның җырлы-биюле өмәләрен – этнографик тасвирларны кертеп җибәрә.

Күренеп тора, Г. Ибраһимов боларның барысын да фольклорчы-этнограф күзлегеннән дә сурәтли: җәй көне – ялан һәм иген эшләре белән бәйле өмәләр, көзен – тула басу өмәсе, каз өмәсе, кышын – өмәләр тынып торган чорда – аулак өйләргә җыелып, күмәкләшеп күңел ачулар һәм башкалар. Гөлбануның гадәттәгедән үзгә табигать кызы булуын авторның табигать культын үзенчә раславында күреп була: «Аның табигый булган бәгъзе бер камәләтенә карагандa, «табигать бу кызны, үзенең иң соңгы мәһарәтен сарыф итеп вөҗүдә китергәндер» диясе килерлек, табигатьнең аңарга биргән имтиязларыннан әүвәл күзгә чалынганы – аның матурлыгыдыр, матурлыкта ул авылда бер иде» [Ибраһимов, 2003, № 4, б. 88]. Гомумән, Гөлбану – табигать-Ана тудырган иң гүзәл сәнгать образы итеп бирелә.

Гөлбануның характер табигатендә рухи хөрлек чалымнары, ирек сөючәнлеккә омтылыш үзен бик иртә, кыз чактан ук сиздерә башлавын күрәбез. «Беррәттән санаганда бу нәрсәләр байтак күренсә дә, 360 көнне фәкать шул кызыклар белән генә уздыру Гөлбануга авыр, күңелсез тоела иде. Ул боларны, гадәттә, бикләнеп ятып та вакытлы гына уенга, иреккә чыгарылган кебек хис кыла иде. Күңеле боларга канәгатьсез иде. Күбрәк тели, ирек сөя иде. Ләкин булмый иде. Ул болардан калган озын кышның көннәрен һәм башка фасылларны, дүрт стена эченә бикләнеп, ата-анасы күрмәсә, тәрәзә аркылы урамга карап үткәрергә мәхкүм вә мәҗбүр иде» [№ 4, б. 87].

Үзәк каһарманның бирелеше аша, язучы татар кызларының соңгы чик тыюлыкта

яшәргә мәҗбүр булуларын күрсәтә. Югарыда телгә алынган өмә-бәйрәмнәр исә алар өчен бераз аралашу мөмкинлеге тудыру, бертөрле үтүчән тормышларын ямьләндереп җибәрүләре белән дә кадерле.

Нәкъ менә бу чараларда Гөлбануның башка кызлардан аермалы тагы бер һөнәрен күрә алабыз: ул бик оста итеп гармунда уйный. Әүвәл, кызның бала чактан ук абыйларыннан өйрәнеп, бу уен коралында моңлы итеп өздереп уйнавы, авыл яшьләренең аулак өйләрдә үткәрелгән җырлы-биюле уеннарын тагы да ямьләндереп жибәрүгә хезмәт итсә, соңрак ул Гөлбануның бердәнбер дустына, юлдашына әверелүенә, Габдуллалыгын раслаучы дәлил хезмәтен үтәүгә кайтып кала.

Г. Ибраһимов Гөлбануга белем бирү мәсьәләсенә дә руссоистларча якын килә. Үзенең «Эмиль яисә тәрбия хакында» (1762) китабында француз философы Ж.-Ж. Руссо мондый фикер әйтә: «Женщина должна многому выучиться, но лишь тому, что ей надлежит знать» [Руссо, 1981, с. 555]. Гомумән, аның бу педагогик романында хатын-кыз тәрбиясе турында әйткәннәренең барысын да гомумиләштерсәк, кыз баланың бөтен зиһене һәм игътибары, башлыча, аның киләчәктәге төп бурычы – иренә яхшы хатын булу һәм бала тәрбиясе нигезләрен яхшы үзләштерүгә юнәлтелергә тиеш була.

Күрүебезчә, Гөлбануның алган белем-күнекмәләре дә Ж-Ж. Руссо тәгълиматындагы таләпләргә җавап бирә: «Ике бишнең ун булуын тиз үк белсә дә, ике унөчнең егерме алты булуы, утыз белән унбишнең кырык биш булуы кебек чобалчыкларны, озак исәпләми, чыгара алмый иде. Һәм шулай булуы табигый дә ... чөнки аның башы бу тугрыда һич уйламагандыр ... Бу фәннәрдән нәкыс (кимлек, җитешсезлек) булса да, педагогия – бала тәрбиясе фәненнән хәбәре күп иде... » [Ибраһимов, 2003, № 4, б. 87]. Ихтимал, шул сәбәпле, абыстайда дүрт ел укыгач, «остабикә булмас әле» дип, аны укуыннан да туктаталар.

Мәгълүм булганча, дөнья һәм рус әдәбияты яссылыгында Г. Ибраһимовның Гөлбануы – саф руссочыл-толстойчыл рухтагы камил герой: ул бары тик мәхәббәт өчен яратылган, эшкә уңган, гаилә тормышына балачактан ук әзерләнгән, белеме дә кирәк хәтле генә, өстәвенә, саф авыл кызы – чын гамәлдә табигать баласы. Соңрак мондый рухтагы, «әлифне таяк дип белмәсә дә», гаилә өчен яратылган, үзенең асыл «кавемен» саклап калган табигый инсанны Г. Ибраһимовның икенче бер күләмле романтик әсәре «Яшь йөрәкләр» (1912) романында Камилә образында очратачакбыз.

Гөлбануның кыз хәятеннән үк өметләнеп көткән бердәнбер хыялы – яраткан кешесенә киявгә барып, бәхетле гаилә кору. Әмма, кызганыч, кызның бу теләкләре тормышка ашмый, әтисе Нурый карт, беркем белән дә киңәшләшмичә, аны авылларыннан 25 чакрымда урнашкан Курайлы авылына, Зариф байның улы Закирга бирергә карар кыла.

Ноябрь ае – татар авылларында туйлар чоры. Ай ахырында,

кышка аяк басканда, Гөлбануның да туе көтелә. Аның, Закирлар гаиләсенә килен булып төшкәч, чын мәгънәсендә корбанга әверелəчәген, хәятенең фаҗигале чоры якынлашуын сюжетка органик рәвештә үрелеп киткән җыйнак табигать сурәтләре дә хәбәр итә. Мәсәлән, туй көннәрендәге табигать торышын автор түбәндәгечә тасвирлый: «Кыш, үзенең ак кардан гыйбарәт кәфеннәре белән килеп, бөтен кяинаттан хәятне алмыш, кәфенләмеш иде. Аның дәһшәте һәрнәрсәне дер-дер калтырата иде» [№ 4, б. 95]. Күрүебезчә, табигать манзараларына көтелəчәк хәлләрнең алхәбәрен җиткерү кебек мөһим роль йөкләнгән. «Кыш-кәфен» дигән үзенчәлекле чагыштыру-параллелизм алымына мөрәҗәгать итү, символик җил, буран образларын эзлекле рәвештә кертеп җибәрү болай да шомлы пейзажның гәүдәләнешен тагы да арттырып җибәрәләр. Шулай ук автор, романтик язучы буларак, Гөлбануның эчке кичереш-бәргәләнүләре белән табигать арасында тиңләштерүләр үткәрә.

Туй көне белән никах бергә булып, кыздан ризалык сорап торуның кирәген дә тапмыйлар, барысы да әүвәлге гадәт буенча формаль рәвештә башкарыла. Беренче зөфаф кичәсендә үк ул Закирның үзе өчен ят, «чирканчык», хайвани табигатьле зат икәнен күреп, күңеле һәм тәне белән кабул итмәсә дә, шәрекъ хатын-кызының канына сеңгән сабырлыгы, ата кеше сүзенә булган хөрмәте, ир-атка булган ихтирамлы мөнәсәбәте аны буйсынырга өнди. Ата кешенең карарын, нинди булуга карамастан, аяк астына салып таптау аның өчен ят нәрсә. Гөлбануны да, беренче нәүбәттә, ата-анасына булган хөрмәт-ихтирамы, язмышы белән килешергә, иренә тулаем буйсынырга мәҗбүр итә.

Шулай итеп Гөлбану тормышында хатынлык-коллык чоры башлана. Килен булып төшкәч, ул чын мәгънәсендә хокуксыз инсанга әверелә. «Хәзерге хәле белән кызлык чагын чагыштырып караганда, кызлык – хөрлек, киленлек – коллык, диярлек иде. Аңарга һичбер илтифат, игътибар юк, яшь килен булгач, ул хокуксыз ... һәркемнән түбән... Һәркемгә мәхкүм иде. Һәркем аңарга әмир, хаким була, һәркем аны җиңә һәм җигә иде» [№ 4, б. 102].

Гаделсез хатынлык чоры тормышының төп лейтмотивы булып елау мотивы калкулаша. Әсәрдә беренче тапкыр Гөлбану Закирга кияүгә барачагын белгәч елый башлый һәм шуннан башлап күз яше аның даими юлдашына әверелә. «...кызының риза булмыйча көн-төн елаганын Фәтхия карчык Нурыйга әйтеп, Нурый моны үз күзе белән күрсә дә, һичбер йомшармады» [№ 4, б. 94]. «Гөлбану, Фәрит мулланың кызы Нәфисә дусына елап, аның аркылы Фәриткә үзенең риза түгеллеген белдерсә дә, аннан да һичбер файда чыкмады» [№ 4, б. 94]. «Аның күз яше кыйммәт, дип, берәү дә игътибарга алмады» [№ 4, б. 94]. «Күзе даими агар чишмә хәлен алып, көн-төн ул гүзәл күзләрдән алсу йөзен каплап энҗе бөртекләре түгелә иде. Ул һаман еглый гына иде. Ләкин бу яшьләр

файда бирмәде» [№ 4, б. 94]. «Еглап башы да каткан иде» [№ 4, б. 97]. «Еглау гадәте озатылган һәр кызда да бар... ләкин бигрәк мәнфүр күргәнгә, Гөлбануның еглавы дәхи башка, дәхи моң иде» [№ 4, б. 100]. «Аның аяныч хәле һәм күз яше бирәүгә дә кыйммәт түгел ... бирәүнең дә мәрхәмәт хисен уятмый иде. Еглаганын күрсәләр, аңарга бик залимәнә тавыш белән:

– Сидермә күзеңне!.. – дип кенә куялар иде» [№ 4, б. 102].

«Тыштан никадәрле белдермәскә тырышса да, эченнән һәр заман еглый .... яна ... көя иде» [№ 4, б. 103]. «... ихтыярсыз аның күзеннән мөлдер-мөлдер яшьләр тәгәрәп, йөзеннән эз салып китәләр, ул аларны тыймый, еглый иде» [№ 4, б. 103]. «Аулак тапса, мотлак еглый, Аллага зарыйлык кыла, ялвара үлем дә сорый иде» [№ 5, б. 125]. Бите карачкыл-сарыга әйләнеп, күзләре эчкәрәк баткан, караган саен бер аянычлык хис кылына, “минем еглыйсым килә”, дигән бер күренеш сизелә иде» [№ 4, б. 103]. «Гөлбануның күз яше бирәүгә дә кыйммәт түгел... Җылап җаны чыксын, аны химаяче юк... булса да булдыра алмыйлар... » [№ 5, б. 126]. «Ул дәхи еглады. Бусы зәһәрле дә... агулы да иде» [№ 5, б. 126].

Еш кулланыла торган сентименталь-романтик мотив буларак, елау – Гөлбануның бик хисчән, нечкә күңелле, башка персонажлардан кискен аерылып торучы образ икәнлеген бәян итү белән бергә, укучыда да Гөлбануны ихлас күңелдән яклау теләге уятмый кала алмый.

Гөлбануга каршы куелган Закирның үтә дә тискәре персонаж икәнен күрсәтү өчен Г. Ибраһимов натуралистик алымнарның ике төренә дә – натурализм-фотографизм, натурализм-биологизмга мөрәҗәгать итә. Әйтик, бар яктан килгән Гөлбану янында физиологик-биологик алым белән гәүдәләндерелгән Закир образы укучыда нәфрәт хисе уята, Гөлбануның хәлен тагы да кызганычрак итә: «... колга кебек озын буе, кап-кара шадра, кашсыз вә чобар йөзе белән күренеп, агач кебек куллары белән кысып, сөйкемсез иреннәре белән үбә башлагач, Гөлбануның күңелендәге нәфрәт вә кәраһәт (чиркану) бигрәк артты» [№ 4, б. 97]. Ә инде Закирның соңгы тапкыр исереп кайткандагы халәтен, бар килеш-килбәтен күрсәтүдә натуралистик тасвирлау иң югары ноктасына җитә: «Закир бик нык исерек иде. Күзене адәм куркырлык рәвешле кызыл кан баскан, йөзе тузан, пычрак, авызы күбекле иде» [№ 5, б. 127]. «Төн буена шулай үзенең сасы, нәҗесле тыны-сулышы белән җанны рәнҗетеп, Фәтхия әбинең кадерләп үстергән назлы, иркәле Гөлбанусының кечек авызы, кызыл иреннәреннән аракы аңкып торган пычрак, сасы, күбекле, селәгәйле авызы белән үбеп, суырып җирәндереп чыкты. Закир йоклап киткәнче үзенең аракылы, селәгәйле, пычрак, күбекле авызын Гөлбануның кыйммәтле авызыннан алмады. Үпте.. Суырды. Болар Гөлбануны чиктән тыш җирәндерде, биздерде. Аның бөтен җаны, күңеле җирәнә, косасы килә иде» [№ 5, б. 127–128].

Өч еллык киленлек хәяте Гөлбануның табигый яшәешен, билгеле, бик нык җимерә. Тикмәгә Г. Ибраһимов, кызның кияүдәге хәлен җан асрауга тиң икәнен күрсәтү өчен экзистенциаль әдәбиятның лексик чараларына – бер синонимик ояга кергән экспрессив фигыльләргә мөрәҗәгать итмәгән: *изелә; яна; көя; өзелә; сызлана; борчыла; газаплана; кыйнала; тиргәлә; ялвара; үлем сорый.*

Әнә шундый авыр пычрак тормышта бәрелеп-сугылып яшәүче Гөлбану, тәмам сабыры калмагач, Закирның чираттагы көчле котыруыннан соң качарга ният кыла. Бу мизгелдә аның күңелендә ике төрле фикер-хис көрәше бәрелешә: беренчесе – *Акыл-хис* – «Син китәргә, качарга тиеш» дисә, икенчесе – *Өмет* – «Түз әле.. бәлки төзәлер», дип китмәскә өнди. «Хиссият аның тора алырлык тәкате калмаганына ышандырды» [№ 5, б. 126]. Һәм патриархаль аң белән тере инсанның бәхеткә булган табигый омтылышы коллизиясендә *Акыл-хис* җиңеп чыга.

Әйе, мең төрле газапларга түзү, бертуктаусыз уйланулар, кипмәгән күз яшьләре, төп героиняны катарсис хәленә җиткерә, характерына гыйсъянчылык оеткысы сала. Гыйсъянчылыкның көчле тәэсирендә ул, Сабира-Закир хакимлегеннән качып, көтмәгәндә, танышлары Галиулла белән Шәрифәләргә ияреп, туган иленнән Троицк якларына чыгып китә. Җаны сөймәгән, тискәре ирлек сыйфатларына гына ия ире Закир, усаллыгы белән дан тоткан каенанасы Сабиралар йортында кыйналып, рәнжетелеп, хокуксыз яшәүгә тәмам сабырлыгы калмагач, рәхимсез патриархаль кануннарга каршы гамәл кылырга мәҗбүр була. Каһарман холкындагы шушы сыйфатларны күздә тотып, совет чорының күренекле әдәбият галиме Г. Халит Гөлбануны «бунтарь героиня» дип атый [Халит, б. 132]. Аның шәкерте Ф. Бәширов та бу фикерне кире какмый: «...1909 елда тәмам ителгән “Татар хатыныниләр күрми” повестенда кимсетүләргә түзә алмыйча, өеннән качып китеп, ирләр киемендә ил гизәргә җөрьәт иткән горур Гөлбану шул гыйсъянчылыкның беренче чаткылары булды» [Бәширов], – ди. Тәнкыйтьче Ф. Галимуллин да: «Г. Ибраһимовның Зәкие (“Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы”), Гөлбануы (“Татар хатыны ниләр күрми”) шулай ук гыйсъянчы геройлардан саналырга хаклы» [Галимуллин, б. 23] – дип искәртә.

Автор Гөлбану төпләнгән Сөләйман авылы тирәсе табигатенең матурлыгын руссочыл-романтик рухта тасвирлый, саф табигать күренешләрен, андагы күчмә тормышны идеаллаштыра: «Тирә-ягы гомумән урман вә тау булганга, мәнзара табигыйясе фәүкыльгадә (гадәттән тыш) гүзәл булып, әһалисе (иясе, халкы) гомумән башкорттыр. Бу башкортларда җир, су, урман, агач, бик хисапсыз күп булып, бу елларга кадәр авыл авылга бүленмәгән иде» (№ 5, б. 129). «Мондагы табигый күренешләрнең гүзәллеге адәмне хәйран итәдер. Кайда карасаң да, ямьяшел агач белән капланган өлкән вә биек-биек таулар, урманнар,

коргыйлар, акланнар, җимешле агачлар арасыннан, таш эченнән шылдыр-шылдыр агып яткан көмеш кебек елгалар адәмнең мәхәббәтен җәлеп итә… рәхәт вә шатлык бирә… уйлата… уйгатадыр. Ләкин башкорт моны сизми, ул йоклый гына… <…> Монда хәят мөхарәбәсе (сугыш) юк, икътисадый җәһәтеннән кайгы-хәсрәт тә күрми, тыныч рәхәт яшиләр. Гали матлаблар (теләнелгән, таләп ителгән), уку вә укытулар өчен баш вату күптән юк» [№ 5, б. 129–130].

Әмма, Гөлбану иркен сулыш алырга да өлгерми, аңа икенче тапкыр ир хатыны булу әзерләнеп куелган була. Илле биш яшьлек башкорт бае Солтан Гөлбану табигатенә бөтенләй дә туры килми: «Бик юан корсаклы, калын гәүдәле, урта буйлы, ифрат симез, кып-кызыл йөзле, чал сакаллы...» [№ 5, б. 130].

Икенче ире караклар кулыннан вафат булгач, аны өченче мәртәбә 11 яшьлек сабыйга (!) – Солтанның энесенә хатын булырга күндерәләр. Ояты, көлкелеге, хурлыгы белән монысы, алдагы ике никахка караганда да авыррак, аянычлырак булып чыга: «Оят... намуска авыр, өзелә, өзгәләнә... әллә нишли иде. Тыштан белдермәсә дә, эчендә утлар яна иде... көя... еглый... ватыла иде» [№ 5, б. 131]. Бу өченче очракта Г. Исхакыйның «Башкорт бәхете» хикәясендәге кебек халәт барлыкка килә.

Мәгълүм булганча, өч ир белән дә Гөлбану бәхетле була алмый: физиологик-җенси табигате, саф йөрәге, җаны аларның барысын да кире кага.

Әсәрдәге ир-ат җенесенең хатын-кыздан һәрьяклап өстенлеге, хатыннар затына карата булган чиктән ашкан мәрхәмәтсезлеге, үз вәкаләтләрен арттырып җибәрү гадәте борын-борынгыдан килгән, үзгәртеп булмас хәл кебек кабул ителә.

Гөлбануның ирләре: беренчесе – сасы, эчкече ... ; икенчесе – карт, юан корсаклы, шәһвәтпәрәст (җенси дәртле); өченчесе – балигъ булмаган сабый. «Ир – хатын» мөнәсәбәтенең өч төрле моделендә дә хатын-кызның теләге, җәмгыятьтәге роле ирләренекенә караганда диаметраль капма-каршы. Шуңа да Гөлбану табигатьнең аны хатын-кыз итеп яратуына ләгънәт укып, ирләр рәтенә күчәргә ният кыла.

XX гасыр ахырында – XXI гасыр башында кеше җенесенең биологик һәм социаль мәгънәләрен аерып күрсәтү максатыннан, әдәбият белемендә дә *гендер* төшенчәсе активлашып китте. (Бу төшенчәне – җенеснең иҗтимагый конструкциясен фәнгә Америка психоаналитигы Роберт Столлер кертте.)

Әлеге теория хатын-кыз мәсьәләсен бары тик җенес теориясе күзлегеннән генә караудан баш тарта; кешелек җәмгыяте өчен бик тә актуаль булган хатын-кыз проблемасын иҗтимагый яшәешнең төрле аспектларында яктыртуны зарури дип саный.

Г. Ибраһимов үзенең «Татар хатыны ниләр күрми» повестенда ук инде хатын-кызлар белән ир-атларның социаль статус буенча мөнәсәбәтләрен, аларның җәмгыятьтә тоткан урыннарын

*гендер* теориясе нигезендә гәүдәләндерә. Әмма язучы җенесләр мәсьәләсенә бик тә үзенчәлекле якын килә: кешенең табигый асылы югалуын, әхлакый яктан гарипләнүен руссочыл фикерләр яссылыгында сурәтли. Социаль-әхлакый гаделсезлекләр роман каһарманы Гөлбануны хатыннар-коллар даирәсеннән аерылып, кием алыштырып кына булса да ирләр-хуҗалар сафына басарга мәҗбүр итә. Чөнки, хатын-кыз булып калса, ул ир-ат халкы тарафыннан эзәрлекләнеп яшәячәген яхшы аңлый.

Бу хәлләрдән котылуның бердәнбер чарасы буларак, сюжет тудыручы төп мотив – качу мотивы калкулаша.

Шулай итеп патриархаль яшәү кануннары Гөлбануны иленнән, усал каенанасыннан, явыз ирдән, хәтта үз-үзеннән – хатын-кыз җенесе вәкиле булудан да качарга мәҗбүр итә. Гөлбану, табигатьнең аны хатын-кыз итеп яратканлыгына ризасызлык белдереп, гыйсъянлыкның иң югары баскычына күтәрелә, аның тормышында ирлек – Габдуллалык чоры башлана.

Чәчен кисеп, хатыннар киемен ташлап, ирләр сыйныфына күчүенә хатын үзе дә таң кала: «Ул үзен һәм башлаган фәүкыльгадә (гадәттән тыш) эшен тәмам аңлап, батырлыгына хәйран калмыш иде. Ышанасы килми... әллә бу төшемме? Әллә хыялмы... дидер иде» [№ 5, б. 132].

«Отсутствие гармонии в мире и с миром неизбежно вело героя к душевному разладу. Наиболее острой формой выражения этого разлада становятся образы двойников. Раздвоенность героя кажется самому себе одновременно и самим собой и кем-то совершенно другим, чужим», – дип искәртә әдәбиятчы Н.П. Кубарева [Кубарева, с. 228]. Фикерләр бәхәсе, төрле уйлар көрәше (аң агымы) Гөлбануның эчке дөньясын тәмам яулап алалар.

Инсанның романтиклар яратып тасвирлый торган эчке дөньясы, рухи халәтендәге бу икеләнүләр, шул ук вакытта үз-үзенең гайре табигый кыюлыгына хәйран калу – Гөлбануга коллык богауларын өзү юлына басарга этәргеч бирә.

Һичшиксез, нәкъ менә бу эчке самимилек Г. Ибраһимов Гөлбануының да тәвәккәллеген, кыюлыгын ашландырып җибәрә. Вакыйгалар динамикасында физик яктан нык изелгән Гөлбануның рухи эчке халәтендәге бу бозык җәмгыять кануннарына каршы барырлык көчнең әкренләп өлгерүенә, ахыр чиктә, тышка бәреп чыгуына шаһит булабыз. Галим Д.Д. Обломиевский хаклы искәрткәнчә: «Үзенең яшәргә хокукын дәлилләү өчен, күңеле яхшы кеше бәхәсләшергә, көрәшергә, һөҗүмгә күчәргә, кыю һәм тәвәккәл булырга, гыйсъян һәм протест белдерүче вәкилгә әверелергә тиеш» [Обломиевский, с. 5].

Иҗтимагый һәм көндәлек яшәештә җенесне алыштырып, Габдулла булып яшәү дәрәҗәлерәк, отышлырак күренсә дә, нәкъ менә рухи сафлык, әсәрдән аңлашылганча, Гөлбануның тулы хокуклы ир булып яшәвенә киртә була. Җенесен алыштырып яшәү ялганын ул эчке күңеле, сизгер йөрәге белән һич кенә дә кабул

итә алмый. Табигый бөтенлектән һәм бердәмлектән төшеп калу аны хәсрәтле уй-кичерешләргә этәрә. Бердәнбер дустына, юлдашына әверелгән гармун, аның сагышлы моңы бу сагынуларны тагы да көчәйтә генә. Күңеле түрендә кайнаган хисләр ташкыны, еш кына, үткәндәге кызлык дәверенә, ата-анасы йортына алып кайта. Ахыр чиктә, аның табигый «җирсүе» (туган туфрагына тартылуы), тумыштан кыз булып яратылганлыгы җиңеп чыга. Шул сәбәпләр аркасында әнисе Фәтхияләргә фатирга кергән «Габдулла» үзенең артык сагышлы, моңсу йөзе һәм гайре табигый тотышы белән өй тирәсендәге хатын-кызларда шик-шөбһә уята.

Белүебезчә, «Җиде кыз» бәетендә егетләрнең, асылда, кызлар затыннан булуы мунчада ачыла. «Ир-егет Габдулла»ның да Гөлбану булуы, татар халык бәетләрендәгечә, мунчада фаш ителә.

Әсәрнең 1929 елда язылган укучыга яхшы таныш икенче вариантында Гөлбануның язмышы фаҗигале рәвештә суга батып үлүе белән тәмамланса, тәүге вариант исә төп каһарманның үзенең табигый асылына – Гөлбанулыгына кайтуы белән тәгәлләнә.

Шулай итеп, Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрендә хатын-кызның табигый асылына мөрәҗәгать итеп, аның табигатьнең аерылгысыз өлеше булуын исбатлый. Гөлбану язмышы мисалында, соңгы чара буларак, табигый гармониягә каршы бару хисабына да тулы бәхеткә ирешеп булмау күрсәтелә.

Изтыйраб-мәшәкатьләргә тару чорында язылганга күрә, романда туры мәгънәдә әйтелмәсә дә, хатын-кыз азатлыгы проблемасының социаль һәм милли азатлык мәсьәләсе белән тыгыз бәйләнгәнен күрәбез. Хатын-кыз затына карата булган бу коточкыч газаплардан бары тик бердәм рәвештә, иҗтимагый эчтәлекле гендер юлы белән, табигать-Ана күрсәтмәләрен дә искә алып хәрәкәт иткәндә генә котылырга мөмкиндер.

Иң мөһиме: Г. Ибраһимов өчен кеше – үзенең асылы, физик үзенчәлекләре, хисләре, теләкомтылышлары белән иң беренче нәүбәттә табигать баласы. Аның каһарманы Гөлбану табигый һәм иҗтимагый стихияләр эчендә калган. Аларның дисгармониясе кешене фаҗигагә китерә. Гөлбану да үзенең саф, гайре табигый сыйфатлары аркасында гадел булмаган җәмгыять шартларында меңләгән татар хатыннары кебек яшәүдән баш тарта.

Нәтиҗәдә, җәмгыять белән каршылыкка кергән көчле руссочыл образ – романтик ялгызак Гөлбану образы тудырыла.

Соңрак 1929 елда язылган II вариантта исә Г. Ибраһимов, образ иҗат иткәндә, руссочыл «табигый кеше»не идеаллаштырудан читләшә, герой иң беренче чиратта, җәмгыять тудырган социаль зат булып калкулаша. Октябрь инкыйлабына кадәрге татар хатын-кызларының язмышын чиктән тыш бәхетсез итеп сурәтләү – большевикларның бары тик җәмгыятькә генә хезмәт итүче азат совет хатын-кызын тәрбияләү идеалларына да җавап бирә иде.

**Әдәбият**

*Бәширов Ф.К.* XX йөз башы татар прозасы. Казан: Фикер, 2002.

*Галимуллин Ф.Г.* Табигыйлеккә хилафлык. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.

*Ибраһимов Г.* «Татар хатыны ниләр күрми» (Роман. Беренче басма) // Мирас. 2003. № 4 (137). Б. 81–105; № 5 (138). Б. 123–139.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: тугыз томда. Т. 7: тарихи хезмәтләр (1911–1927) / томны төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче С.Х. Алишев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 218 б.

*Кубарева Н.П.* Романтизм // Основы литературоведения: учеб. пособие для филол. ф-тов пед. ун-тов / под общ. ред. В.П. Мещерякова. М.: Московский Лицей, 2000.

*Мусин Ф.М.* Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүнең торышы һәм бурычлары // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002.

*Обломиевский Д.Д.* Французский романтизм: очерки. М.: ОГИЗ: Гослит-издат, 1947.

*Руссо Ж.-Ж.* Избранные сочинения: в 3 т. Т. I: Об искусстве и литературе. Поэзия. Драматургия. Философская сказка. Педагогический роман / сост. и автор вступ. ст. И.Е. Верцман; худ. Е. Коган. М.: ГИХЛ, 1961.

*Руссо Ж.-Ж.* Педагогические сочинения: в 2 т. / под ред. Г.Н. Джибладзе; сост. А. Н. Джуринский. М.: Педагогика, 1981. Т. I.

Татар халык иҗаты: бәетләр / томны төзүчеләр: Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 156 б.

*Халит Г.* Чынлык һәм гүзәллек гармониясе: (Г. Ибраһимовның эстетик карашлары үсешен күзәтү тәҗрибәсеннән) // Казан утлары. 1977. № 3. 132 б.

***Минһаҗева Рәзилә Әбүзәр кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Яр Чаллы педагогия көллияте укытучысы*
*kamiloi@mail.ru*

УДК 821.512.145-95

***Д.М. Абдуллина***

# СУФИЯН ПОВАРИСОВНЫҢ ИҖАТ ХӘЗИНӘСЕ ҺӘМ Г. ИБРАҺИМОВ МИРАСЫН ӨЙРӘНҮДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

В статье рассматривается научное и художественное творчество знаменитого ученого, педагога, именитого писателя Суфияна Поварисова. Особое внимание уделяется его историко-биографической трилогии «Заря пророка», посвященной жизни и многогранной деятельности Галимджана Ибрагимова.

**Ключевые слова:** Суфиян Поварисов, Галимджан Ибрагимов, историко-биографическая трилогия «Заря пророка».

«Бәхет…» Күренекле галим, мәртәбәле педагог, танылган язучы Шәмсетдин улы Суфиян ага Поварисов 1953 елда язган тәүге шигырен әнә шулай атый. Очраклылыкмы бу, язмыш юравымы, «бәхет – хезмәттә» дип раслаган әлеге юллар аны иҗат бакчасыннан бәхеткә илтүче сукмак башы була. Сабыр гына, хезмәтеннән ямь табып, бәхетен тоеп яшәгән бу олы затны бәхет һәм хезмәт бөтен гомере буена ике иңендәге ике фәрештәдәй озатып бара.

Татар, рус, башкорт телләрендә басылган 50 дән артык исемдәге китап, 200 дән артык фәнни хезмәтләрнең авторы, 300 ләп диплом хезмәтенә һәм дистәгә якын кандидатлык диссертациясенә җитәкчелек иткән, сугышта күрсәткән батырлыклары өчен 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, ике дистәгә якын медаль һәм бик күп рәхмәт хатлары, Башкортстан һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Башкортстанның халык язучысы дәрәҗәләренә ия булган Суфиян аганы фәрештәләре саклаган, бәхет һәм хезмәт юлдаш иткән дими, ни дисең.

Дөрес, бу беренче карашка гына шулай гади бәхет эше кебек күренә. Әлеге уңышларга ирешү, халык ышанычын һәм хөрмәтен яулау өчен утлар-сулар кичәргә, тормышның ачысын-төчесен күп татырга, хезмәтнең ачы тирен шактый йотарга туры килә әле аңа.

Суфиян ага Поварисов 1924 елның 29 августында Башкортстанның Илеш районы Тыпый авылында дөньяга килә. Аның әтисе 1925 елда үз куллары белән булдырган ике катлы йортын, шаулап торган җимеш бакчасын, сөекле тормыш иптәшен һәм алты баласын ятим итеп, якты дөнья белән бәхилләшә. Тәүге адымнарын атлаганда ата кулына тотыну мөмкинлеге булмаган Суфиянга һәр нәрсәне үз тырышлыгы белән яуларга туры килә. Дүртенче сыйныфны тәмамлауга укуын ташлый, «мең төрле кылыч киртәләр үтеп, 1939 елда җиденчене тәмамладым», дип яза ул соңрак бу хакта. Мәктәптә укыган елларында төннәрен, туганнары белән

ярыша-ярыша, өч калыпка салып чабаталар үрә. Җиденче сыйныфны тәмамлауга колхозда эшли, паспорт алуга Свердловск, Салехард тирәләрендә кырыгар градус салкында шпаллар сала, 18 яше тулуга Бөек Ватан сугышына алына. Курск дугасыннан Дрезден шәһәренә чаклы сузылган яуда Украина, Польша, Венгрия, Чехословакия, Германия җирләрен фашизм коллыгыннан азат итүдә катнаша. 1947 елда гына солдат хезмәтен тәмамлап кайта ул. Ут эченнннән исән чыгарга, ач үлемне әйләнеп узарга әтисенең изге рухы, әнисенең бәхет, гомер сорап ялварган догалары ярдәм итә күрәсең.

Армиядән соң Үзбәкстанның Нәманган өлкәсендә мәктәптә хәрби хезмәт өйрәтә, үзе дә «бик яхшы» билгеләренә генә кечкенә мәктәпне тәмамлый. Аннары 1951–1955 елларда Казан педагогия институтының тарих-филология факультетында укып, дәрәҗәле диплом иясе була.

Белгечлек буенча хезмәт юлын ул Татарстан автономияле республикасы Актаныш районының Бурсык мәктәбендә директор буларак башлый, ике елдан Башкортстанга кайтып, «Кызыл таң» газетасына хәбәрче булып урнаша. 1960 елдан Башкорт дәүләт университетының филология факультетында эшли башлый. Фән дөньясына ул шулай килеп керә. 1966 елда кандидатлык, 1990 елда докторлык диссертацияләре яклый, 1993 елдан профессор, БДУның кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау советы әгъзасы булып тора.

Башкорт, татар язучыларының тел-стиль үзенчәлекләре буенча яңадан-яңа фәнни хезмәтләр язу, студентлар һәм яшьләрнең фәнни һәм иҗади эшләренә юнәлеш бирү, җитәкчелек итү, мәгариф өлкәсенә кагылышлы педагогика, тәрбия, мәдәният мәсьәләләрен колачлап язылган мәкаләләр һәм ярдәмлекләр, үзенең эшен дәвам итәрлек 50 гә якын шәкерт тәрбияләү – боларның һәммәсен ул җаваплылык тоеп, яратып башкара. Шуңа күрә нәтиҗәсе дә күңел канәгатьлеге кичерерлек, аның укучылары югары, махсус һәм урта белем бирүче уку йортларында остазларының эшен лаеклы дәвам итәләр.

Суфиян ага галимлекне халыкка хезмәт итү, ил алдындагы бурычын түләү буларак кабул итә, әмма рухи ашкынудан җанын ярып чыккан әдәби иҗатка омтылу аны гомере буе ташламый. «Язу эшенә мин бик соң керештем. 1953 елда, ягъни 29 яшемдә, “Кызыл таң”да “Бәхет” дигән беренче шигырем басылды. Тукай 27 яшендә зур шагыйрь булган. Шигырь бөртекләп җыйган алтын белән бер. “Алтмыш яшемдә дә мин Тукай булмам” дип курыктым. Икенчедән, тормыш шулкадәр күп күрсәтте, алар һич тә шигырь кысаларына гына сыймый. Эпик киңлекне чагылдыра торган башка жанрлар кирәк», – дип ярым җитди һәм ярым шаяру белән аңлата ул үзенең иҗат эшенә алдан ук зур максатлар куеп, киң масштабта алынуын. Әйе, күп кенә шигырьләр, поэмалар, хикәяләр, повестьлар,

драма һәм комедияләр, романнар һәм халкыбызның бөек улы Галимҗан Ибраһимовның тәүге сулышыннан алып, гомеренең ахыргы минутларына кадәр гәүдәләндергән тарихи-биографик трилогия – «Пәйгамбәр таңы» («Пәйгамбәр таңы», 2004; «Күкнең җиденче каты», «Оҗмахка бер адым», 2006) – болар барысы да аның әдәбиятыбыз мирасын баетуга керткән өлеше. Суфиян ага Поварисов күләмле соңгы әсәре кысаларында гади яшәеш агымына кайнар лава ташкыныдай бәреп кергән инкыйлаб дулкыннары, аның белән килгән афәтләр һәм, гомумән, тарихның һич тә артка әйләнмәс тәгәрмәче астында калып изелгән кешелек кануннары, идеаллар, өметләр турында да сөйли. Трилогиянең үзәгендә илебездәге адәм язмышына бик тә аяусыз елларга килеп үрелгән бәхет һәм борчулар, уңыш-уңышсызлыклар, шатлык һәм үкенечләр белән тулы булган Г. Ибраһимовның гомер юлы.

Иң элек, кечкенә Галимҗан, авыруы аркасында, үз вакытында алдынгылардан саналган «Хөсәения» мәдрәсәсенә кабул ителми кала, дәрәҗәсе күпкә түбән булган Вәли мулла карамагында белем алырга тиеш була. Андагы тәртипләр белән килешмичә, башта Вәли мулла мәдрәсәсеннән, аннан Уфадагы «Галия» мәдрәсәсеннән куыла, Казан университетына керү теләге белән, авыру килеш Миасс шахталарында эшли, әмма «Галия»дә мөгалимлек итү шатлыгы, беренче хикәяләре, тәүге фәнни хезмәтләре басылу аңа канатлар куя. Революцион эшкә җигелеп, үз заманының даһилары дип санаган Ленин, Сталин кебек шәхесләр белән иңгә-иң торып алар фәрманына хезмәт итә. Шәхси тормышындыгы мәхәббәт фаҗигаләре, ата-ана күңеленә салган сагышларыннан кичергән күңел газаплары, империалистик сугыш, гражданнар сугышы, ачлык фаҗигасе, ил, халык язмышы кыл өстендә торганда гомум халык бәхете, милләт язмышы өчен үз-үзен аямый хезмәт итү, һәм… «халык дошманы» дигән кара тамга, фаҗигале үлем.

Әйе, автор үзенең әсәрен башкача тәмамлый алмый, тарих аны акка кара белән шулай язып куйган. Тик Суфиян Поварисов пәйгамбәрлек югарылыгына күтәргән героеның үлемен дә гади генә түгел, өмет яктылыгындагы вәхшилек чагылышы итеп бирә.

Галимҗан Ибраһимовның тормышын һәм күпкырлы иҗади эшчәнлеген, халкыбызның бөек улы, фаҗигале язмышлы шәхес икәнлеге турында язылган хезмәтләр күп. Трилогиядә дә ул халык бәхете өчен көрәшүче, милләт каһарманы, үз артыннан башкаларны ияртә алган, кәгъбәсенең дөреслегенә иманы камил булган, намуслы, сабыр, пәйгамбәрләр югарылыгындагы зат. Пәйгамбәрләр үлемсез була, аларның үлеме җисми үлем генә. Алар тырышлыгы белән кешеләр күңеленә иңдерелгән иман мәңгелек. Суфиян Поварисов «Пәйгамбәр таңы» трилогиясе белән, бәлки, шул фикерне дәлиллидер. Ничек кенә булмасын, ул тормышның реаль агымына, тарихи дөреслеккә һич хилафлык

китермичә искиткеч төгәллек, дәлилләнгән фактлар җирлегендә алып бара. Шул ук вакытта дәверләр җиле тигезләгән эзләрне дә эчке рухи тоемлавы белән тергезеп, күптән булган вакыйгаларга җан өреп, укучының йөрәгенә үткәреп тасвирлый. Укучыга гадилек һәм илаһилыкны берләштергән Галимҗан Ибраһим образын үзенчә тәкъдим итә.

Г. Ибраһимов шәхесе һәм иҗаты язучы өчен, күрәсең, төрле яклап үрнәк булып торган. Ул аның әсәрләрен кайтып-кайтып, төрле яклап өйрәнә. Шулай итеп ул әлеге олуг язучы иҗатын өйрәнүгә генә дә барлыгы 70 табаклы 58 хезмәт багышлаган. Шулар арасында «Г. Ибраһимов стиленең үзенчәлеге һәм аны мәктәптә өйрәнү» (1974), «Г. Ибраһимов прозасының теле һәм стиле» (1978) китаплары һәм язучы прозасын лексик яктан, фразеологик берәмлекләргә мөнәсәбәтле өйрәнүгә багышланган хезмәтләре аны әдәби иҗатны тирәнтен тоемлап, аңлап бәяләүче галим итеп күрсәтте. Аның һәр сүзнең мәгънә йөгең, тексттагы кулланылышын һәм анда нинди вазифа башкаруын гына түгел, ә бу сүзне язганда әсәрне иҗат итүченең рухи халәтен, бөтен хис-кичерешләрен аңлап эш итүе сизелеп тора.

Г. Ибраһимов шәхесен һәм иҗатын өйрәнү һәм халыкка җиткерү өлкәсендә куйган хезмәтләрен исәпкә алып, Башкортстан Республикасы Авыргазы район хакимияте аны Г. Ибраһимов исемендәге премия белән бүләкли.

Суфиян аганың әсәрләре кибет киштәләрендә онытылган китаплар исемлеген тулыландыручылар түгел, аларның һәркайсы үз укучысын, үз тамашачысын тапкан әсәрләр. Аның геройлары төрле, әсәрләрендәге вакыйгалар да, вакыт чикләре дә киң, күләмле, ләкин аларның һәммәсен берләштереп торыучы бер үзенчәлек бар: алар халыкның йөрәгеннән чыккан, шуның өчен йөрәгенә үтеп керә. Аларда – яшәү фәлсәфәсе, тормыш яме, хезмәт тәме һәм җаннарны җылытырлык, иң каты күңелләрне эретерлек хисләр. Һәр вакыйга, һәр мизгел искиткеч матур тел белән бәян ителгән.

«Яратам мин сине, тормыш» дип атый ул үзенең язмышы белән тыгыз бәйләнешле повестьларының берсен. Чыннан да, аның әсәрләренең һәммәсенә тормышны яратып, иҗатыннан тәм табып яшәү рухы сеңгән.

Язучы буларак та ул бер кеше гомере дә җитмәслек зур хезмәт башкарган, шуның өстенә галимлек, педагоглык хезмәте. Әмма Суфиян ага турында сөйләгәндә аның кешелеклелеген, ихласлыгын, чиста күңеллелеген, башкалар күңеленә якты бер нур булып иңә алу сәләтен дә искәртмичә мөмкин түгел. Танышлыклары булганнар аны һәрвакыт яратып, матур истәлекләр аша күңелләрендә яңарталар. Актанышлыларга ул мәктәп янында зур җимеш бакчасы бүләк иткән, танго биергә өйрәткән, кайдадыр иҗат түгәрәкләре оештырган, режиссер да, артист та булган, үзе язган спектакльләрдә дә еш кына төп рольләрне уйнаган (үзешчәннәр арасында әлбәттә).

Ир-егеткә тиешленең һәммәсен үтәгән Суфиян ага: нигез корган, балалар үстергән, агач утырткан, тиешле чакта илне дошманнан саклаган, тыныч тормышта намусына тап төшерми халыкка хезмәт иткән. Шуңа күрә аны һәркайда хөрмәт итәләр, хезмәтләренә югары бәя бирәләр. Театр сәхнәләрендә әсәрләре куела, матбугатта алар турында фикер алышалар, шунысы әһәмиятле: аның иҗаты, әсәрләре белән олы галимнәр дә, шәкертләре дә, укытучылар да гади укучы да бердәй кызыксына. Ул бүген дә фән әһелләре өчен олпат галим, укучы йөрәген яулаган язучы булып халык күңелендә яши.

***Абдуллина Диләрия Марат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының татар телен һәм әдәбиятын укытуның бүгенге проблемалары бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145'367

*Л.Г. Хәбибуллина*

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕ ТЕЛЕНДӘ АНЫКЛАУЛЫ МӨНӘСӘБӘТ БИРЕЛЕШЕ

В данной статье проводится анализ структурно-семантической организации пояснительных конструкций в языке художественных произведений классика татарской литературы Г. Ибрагимова.

**Ключевые слова:** пояснительное отношение, поясняемый компонент, поясняющий компонент, язык произведений Г. Ибрагимова.

Галимҗан Ибраһимов – танылган тел белгече, җәмәгать эшлеклесе, татар әдәбияты классигы. Аның әсәрләре теленә нәзакәтлелек, структур төгәллек, образлылык хас. Әлеге мәкалә Г. Ибраһимов әсәрләре телендә аныклаулы мөнәсәбәтнең бирелешен өйрәнүгә багышлана.

Аныклаулы мөнәсәбәт аныкланучы һәм аныклаучы компонентлардан торган мәгънәви-синтаксик конструкция тәшкил итә. Аныклаулы мөнәсәбәтнең структур-семантик үзенчәлеге шунда: беренче компонентта аныклауга мохтаҗ сүз була, икенче компонент беренчесенең эчтәлеген аныклый, тулыландыра, конкретлаштыра. Беренче өлешнең гомуми мәгънәсе дә, аерым бер кисәге дә аныклана ала. Аныклаулы мөнәсәбәтнең нигезендә логик-фикерләү процесслары ята.

Аныклаулы конструкция компонентлары бер үк объектны белдерә. «Әмма сигнификатив яктан караганда, объектның атамалары төрле, беренчесе, сөйләүче күзләгеннән караганда, тыңлаучы өчен теге яки бу мөнәсәбәттә билгесез була һәм икенчесе, сөйләүче фикеренчә, тыңлаучыга билгеле булган, аңлаешлы атама белән тиңләштерелә. Бу аныклаулы конструкцияләрнең гомуми грамматик мәгънәсен беренче атаманы икенчесе белән, югарыда әйтелгән максатта, тәңгәлләштерү буларак ачыкларга мөмкинлек бирә» [Чуглов, 2012, б. 30].

Аныклаулы конструкцияләр тәңгәллек логик мөнәсәбәте белдерүче аныкланучы һәм аныклаучы компонентлардан тора. Бу компонентлар үзара түбәндәге логик мөнәсәбәтләрдә була ала:

1) тигезлек (тәңгәллек, эквивалентлык). Бу очракта, кагыйдә буларак, аныкланмыш һәм аныклагычның мәгънә күләме бер дәрәҗәдә була. Мәсәлән: ***Кемдер, егетләрдән берсе,*** *гармун тартып җибәрде...* («Кызыл чәчәкләр»);

2) өстәмә мәгълүмат. Бу очракта бер төшенчәнең мәгънә күләме икенчесенекеннән киңрәк була. Мәсәлән: *Кимпернең башына бу фаҗигаләр сыймады, ул адәмнәр өчен дөньяда тик* ***бер генә кайгы – хаксыз рәвештә улының сөргенгә җибәрелеп, салым өчен актык атының сатылу кайгысын*** *гына белә иде* («Казакъ кызы»);

3) мәгънә киселеше. Әлеге мөнәсәбәт тәңгәл булмаган синонимнар өчен характерлы. Бу очракта бер төшенчәнең күләме икенчесенең күләменә өлешчә генә керә. Мәсәлән: *Бераз* ***еракта, басу киртәсе буендарак,*** *атлар йөреп тора* («Алмачуар»).

Аныклаулы конструкцияләрдә сөйләүче позициясе мөһим роль уйный. Аныклаулы мөнәсәбәт коммуникатив яктан билгеләнгән була, сөйләүче уе белән формалаша. Җөмләгә, билгеле бер коммуникатив-прагматик максат белән, аыкланучы компоненттан киңрәк, конкретрак, детальләштерелгән мәгълүмат кертелә. Аныклаулы конструкция компонентларына грамматик параллелизм хас.

Гадәттә, аныклаулы конструкцияләрнең икенче компонентында беренче компонент иясен тулыландыручы яки беренче компонентта белдерелгән күренеш семантикасын аныклаучы мәгълүматлар була. Мәсәлән: *Урыннан кузгалуга,* ***без өч ат: мин, Күк бия, тагы бер җирән чабышкы,*** *бер-беребезгә бәреләязып, янәшә оча идек* («Алмачуар»). ***Без, тормышның төбендәгеләр,*** *сездән җавап көтәбез!* («Көтүчеләр»). *Мәетнең сул ягы буйлап, ишектән түргәчә ике рәт булып,* ***дин әһле – дәверчеләр, фидиячеләр*** *сафланганнар* («Казакъ кызы»). *Бикъярдан Хәерниса белән* ***теге ике бала – кечкенә кыз Фәгыйлә белән малай Миңлегалим*** *килгәннәр иде* («Татар хатыны нилэр күрми»).

Галимҗан Ибраһимов, еш кына, җөмләгә аныклагычны аныкланмышны ситуатив яктан, ягъни пространство һәм вакыт ягыннан конкретлаштыру өчен кертә. Мәсәлән: ***Көннәрнең берендә, Тынычбай атаның елы тулганда,*** *бата кыйлырга дип, илнең өлкәннәре җыелган зур бер кымыз мәҗлесендә, күп уен-көлкедән соң заманның авыраюыннан, дошманның җәфасыннан зарланып әңгәмә ачылды* («Казакъ кызы»). *Кәрван-кәрван булып,* ***Зәңгәр Чишмәнең уртасыннан – байлар мәчете янынннан*** *басу капкасына чаклы тезелгән арбалар безне алып китәргә әзер торалар* («Кызыл чәчәкләр»). *Ә* ***бездә, адәмнәрнең хәятында,*** *алай түгел* («Уты сүнгән җәһәннәм»). *Бу чатта миңа* ***өй ягына – уңга*** *китәргә тиеш иде* («Кызыл чәчәкләр»).

Аныклаучы конструкция компонентлары үзара *ягъни*, *гомумән*, *бер сүз белән*, *башкача әйткәндә*, *икенче төрле әйткәндә*, *башкача*, *мәсәлән*, *шул исәптән/шул җөмләдән*, *хәтта*, *бигрәк тә*, *аеруча*, *аерым алганда* теркәгеч сүзләре ярдәмендә бәйләнә ала.

*Мәсәлән*, *аеруча*, *шул исәптән* сүзләре ярдәмендә кертелгән аныклаулы конструкцияләрдә нәрсәнедер өстәү семантикасы була. Бу очракта аныклагыч аныкланмышны тулы күләмдә күрсәтми, ә җөмләнең гомуми эчтәлегендә билгеле бер өлеш ролен генә уйный. Мәсәлән: *Кошкортны бик сөючән иде,* ***аеруча*** *карлыгач белән күгәрченнәрне бик кадерли иде* («Тирән тамырлар»).

Әсәрләренең телен тикшерү күрсәткәнчә, Галимҗан Ибраһимов теркәгечле аныклаулы конструкцияләр арасында *бигрәк тә* ярдәмендә бәйләнгәннәрен еш

куллана. *Бигрәк тә* теркәгеч сүзе аныклаучы компонентның аеруча мөһим мисал буларак кулланылуын аңлата. Бу очракта аныклагычның мәгънә күләме аныкланмышныкыннан таррак була. Мәсәлән: *Шулай итеп, җәйнең озын көне безгә,* ***бигрәк тә*** *миңа, бер дә тоелмый, бәйрәм кеби күңелле үтеп китте* («Яз башы»). *Ул үз гомерендә чит дошман илләрдән,* ***бигрәк тә*** *казакъ җәйләвенә утырган кукаллардан, көтү-көтү малларны ничек урлап, куып алып киткәнен, югалган асыл малларны караклардан ничек табып алганын көлке һәм куркыныч итеп сөйләде* («Казакъ кызы»). *Сарсымбайның бу хактагы сүзен һәммәсе,* ***бигрәк тә*** *Карлыгач, бәйрәм шатлыгы белән каршы алдылар* («Казакъ кызы»).

Моннан тыш, аныклаулы конструкциядә компонентлар позициясе мөһим грамматик мәгънәгә ия. Мондый конструкцияләрдә сүз тәртибе катгый билгеле һәм иярүче кисәкнең ияртүче кисәктән соң килүе белән характерлы.

Аныклаулы мөнәсәбәтнең логик нигезен тәңгәллек тәшкил итә. Әмма барлык конструкцияләрдә дә аныкланучы һәм аныклаучы компонент эчтәлегенең тулы тәңгәллеге күзәтелми. Аныклагычның эчтәлеге аныкланмышныкыннан киңрәк тә, таррак та булырга мөмкин. Аныклаучы компонент аныкланучы компонентның мәгънәсен ача. Бу, кагыйдә буларак, сөйләүченең коммуникатив ихтыяҗыннан туа. Аныклаулы мөнәсәбәт текст коммуникативлыгының тиешле дәрәҗәсен тәэмин итә, эчтәлекне аңларга ярдәм итүдән тыш, яңа мәгълүмат та өсти.

**Әдәбият**

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974–1986.

*Чуглов В.И.* Осложненное предложение: полупредикативные и пояснительные конструкции в современном русском литературном языке (структурно-семантический аспект): автореф. дис. … д-ра филол. наук. Ярославль, 2012. 45 с.

***Хәбибуллина Лениза Газинур кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 75.041.5

***Д.И. Әхмәтова***

# СЫНЛЫ СӘНГАТЬТӘ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ОБРАЗЫ

В изобразительном искусстве Татарстана немного деятелей культуры, образы которых с завидным постоянством осваивались художниками и скульпторами. Одним из таких героев является писатель, общественный и политический деятель первой трети XX века Галимджан Ибрагимов (1887–1938). Образ Г. Ибрагимова имеет свои, как хронологические, так и иконологические особенности. Романтический облик молодого писателя, оставшийся на фотографиях 1910-х гг., не нашел своего отражения в живописи. Оказался довлеющим официальный образ, где в облике сохраняются горьковские черты пролетарского писателя; именно таким чувствовал себя, очевидно, сам писатель и каким видело его общество. Какие-то другие краски, более романтические, стали проявляться лишь в поздние советские годы, когда его образ начал мифологизироваться, однако впоследствии сама фигура писателя практически совсем исчезла из сферы изобразительного искусства.

**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, Павел Петрович Беньков, образ писателя в изобразительном искусстве.

Татарстан сынлы сәнгатендә рәссамнар һәм скульпторлар тарафыннан өйрәнеп гәүдәләндерелгән әдәбият һәм мәдәният эшлеклеләре образлары аз түгел. Шундый мәшһүр шәхесләрнең берсе – XX гасырда яшәп иҗат иткән язучы, җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче Галимҗан Ибраһимов (1887–1938). Әлбәттә, бу өлкәдә иң популяр саналганы – Татарстан сәнгатенең символына әверелгәне Габдулла Тукай, шулай ук Муса Җәлил. Г. Ибраһимов образы исә билгеле бер торышта һәм төрле күренешләрдә тасвирлануы белән үзенчәлекле. Әмма аның 1910 еллардагы – яшь язучы вакытындагы фотолары сынлы сәнгатьтә чагылыш тапмый. Инкыйлабка кадәр Г. Ибраһимовта рус язучысы Максим Горькийның тышкы кыяфәтенә ошарга тырышу күзәтелә. XX гасыр башыннан ук аның җилкәсенә салган кара япмадан («крылатка»), киң кырлы йомшак эшләпәдән, кулына кәкре башлы таяк тоткан хәлендәге образы киң таралган була. Аның Горькийча халыкчан бу стилен яшь язучылар да үзләштерә. Ә менә сынлы сәнгать әсәрләрендә Галимҗан Ибраһимов киемендәге бу атрибутлары белән түгел, ә киеме буенча да, үз-үзен тоту манерасы белән дә чын «пролетар» язучыга әйләнеп барган кыяфәтендә гәүдәләндерелә һәм шул рәвеше белән мәңгеләшеп кала.

Г. Ибраһимовның иконографиясенә «тон» биргән, иң беренче эшләнгән һәм әдәбиятларга кертелгән портреты Павел Петрович Беньков (1879–1949) тарафыннан иҗат ителгән дип әйтә алабыз. Рәссам Петербург Сәнгать академиясендә Д. Кардовскийдан

дәресләр ала. Аның укытучылары Г. Залеман, Я. Циоглинский, Б. Кустодиев, И. Репин – барысы да күренекле сәнгать осталары. Монда шуны да искә төшереп узу урынлы булыр, 1919 елда П. Беньков чигенүче Колчак гаскәрләре белән аклар кулындагы Себергә китә, анда Иркутск һәм Омск театрларында декоратор булып эшли. Колчак армиясе тармар ителгәннән соң кабат Казанга кайта. Г. Ибраһимов та 1919 елда колчаклылар белән «китә», әмма аларның тылында билгеле бер эшләр башкара. Бу хакта П. Беньков белгән иде микән, әллә белеп тә ул хакта сөйләшүне кирәк тапмады микән?..

П. Беньков портретлар эшләү остасы буларак зур танылу яулый, моны аның Г. Ибраһимов образын җанлы итеп мәңгеләштерүе раслый. Рәссамның 1926 елда иҗат иткән эше язучы образын шуннан соңгы гәүдәләндерүчеләр өчен үрнәк булып тора. Г. Ибраһимов портреты әлеге рәссам өчен характерлы булып саналган импрессионистик манерада эшләнсә дә, аның колориты бик тыйнак. Автор анда бөтен игътибарын язучының йөз чагылышына бирә: ул җитди кыяфәттә, үткен, сынаулы карашын тамашачыларга төбәгән. Сурәттәге башка барлык детальләр (хәтта куллары да) эскиз рәвешендә генә ясалган. Сәнгати яктан югары дәрәҗәдә эшләнгән бу хезмәт язучының характерын бик төгәл чагылдыра. Бу хакта күренекле шәркыятьче һәм ислам белгече Л. Климович болай яза: «…На меня в середине двадцатых годов, …не раз его видевшего, слушавшего, лично знакомого с ним, – неизгладимое впечатление произвели его волевой характер, серьезность, строгость и одновременно общительность, не говоря уже о широком кругозоре. Его образ тех лет правдиво отображен на портрете, исполненном П.П. Беньковым». П. Беньков портретындагы Г. Ибраһимов образы язучының шул еллардагы фотографияләре белән бик тә охшаш, чөнки рәссам аның психологик халәтен төгәл билгели һәм аны гомумиләштереп гәүдәләндерә алган. П. Беньков тарафыннан үз героеның шәхесен тирәнтеп аңлап иҗат ителгән образга, сәнгати эшләнеше ягыннан, әлегә тиңнәр юк.

Язучының П. Беньков гәүдәләндергән образын алга таба файдалануның үзенчәлекләре дә бар. Әйтик, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә сакланган фотокүчермәдә язучының сурәте башкачарак, ул П. Беньков оригиналыннан аерылып тора. Күренекле язучының җитдирәк чалымлы бу портреты, күрәсең, рәсми учреждениеләр өчен махсус шомартыбрак эшләнгәндер. Ни дисәң дә, 1920–1930 елларда, шулай ук язучы реабилитацияләнгән 1955 елдан соң Г. Ибраһимов җәмәгатьчелек каршында югары дәрәҗәләр били, күренекле язучы булып таныла. Әмма П. Беньков портреты күчермәләрендә Г. Ибраһимов образы җиңелләштерелгән, йөзендәге җитдилеге югалган рәвеш ала.

П. Беньков портретын график формада эшләгән Федор Семенович Быков (1885–1966) иҗаты оригиналга якынрак тора. Строгановлар сәнгать-сәнәгать училищесының рәсем классын тәмамлагач, 1906–1911 елларда Ф. Быков Казандагы Харитонов, Ключников, Перов типографияләрендә, «Гасыр» һәм «Мәгариф» нәшриятларында эшли. «Хуҗа Насретдин маҗаралары»на иллюстрацияләр ясый («Өмид» басмаханәсе, 1913 ел) [Вагапова, 2015, с. 161]. 1911 елдан ул Мәскәүдә Ступин һәм Сытин нәшриятларында рәссам-гравер булып эшли. 1925–1929 елларда Ф. Быков яңадан Казанда: «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә – рәссам-гравер һәм Казан сәнгать-театр училищесында (элекке Казан сәнгать мәктәбе) – гравюра укытучысы. Ф. Быков Алатырь (Улатар) сәнгать-гравюра мәктәбен (хәзер Чабаксар сәнгать училищесы) оештыручы (1934), аның беренче директоры була, шунда ук дәресләр дә алып бара [Вагапова, 2010, с. 81–86]. Нәшриятларда һәм редакцияләрдә эшләгәндә ул күп кенә мәдәният эшлеклеләренең график портретларын да иҗат итә. Казанда чакта Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов сурәтләрен мәңгеләштерә (1922), алар Чабаксарда Чуваш дәүләт сәнгать музее тупламасында саклана.

Г. Ибраһимов портреты П. Беньков тарафыннан натурадан эшләнгән, киң танылу яулаган портретны хәтерләтә. 1929 елда Г. Ибраһимов Ялтада дәваланган чак булганга күрә, Ф. Быков үзенә йөкләнгән заказны үтәгәндә П. Беньков портретын гына күз алдында тота. Г. Тукай портретын эшләгәндәге кебек, язучының фотографияләреннән файдаланмый. Ф. Быков иҗат иткән график портрет киң кулланылыш ала, әмма, Г. Ибраһимов кулга алынганнан соң, озак вакытлар беркайда да басылмый. Җепшеклек чоры башлангач кына почта конвертларында күренә башлый. 1967, 1968 елларда, мәсәлән, Ф. Быков эшләгән портрет белән «Галимҗан Ибраһимов. Татар әдәбияты классигы. 1887–1938» дип язылган конвертлар файдалануга чыгарыла.

ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һә сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә язучының гаять сәнгатьле итеп эшләнгән рәсеме бар, кызганычка каршы аның тасвирламасы язылмаган. Анда Г. Ибраһимов табигать фонында бирелгән. Рәсем бу өлкәдә билгеле бер дәрәҗәдә тәҗрибәсе булган рәссам тарафыннан, хәтерендә сакланган күзаллауга нигезләнеп иҗат ителгән. Ул – үзенчәлекле халыкчан картина. Сурәт, беренче чиратта, үзенең романтик композициясе белән җәлеп итә. Анда язучы образы идиллия жанрында гәүдәләндерелгән: сихри матурлыктагы пейзаж фонында Г. Ибраһимов ачык төстәге костюмнан, галстуктан; бер кулында эшләпәсе, икенчесендә китап. Авторның композициясе аяк киемен күрсәтүгә корылмаган. Бу сурәт, алда әйтеп үтелгән рәсмилектән аермалы буларак, язучы образын гомум халык тирәлегендә, аның аерылгысыз

вәкиле итеп чагылдыруы белән үзенчәлекле. Бер яктан, язучы рәсми киемнән һәм эшләпәдән булса, икенче яктан, ул романтик рухтагы табигать күренешләре – калкулыклар, сулыклар (күлме, әллә елгамы), ташлар һәм җәйге бай үсемлекләр дөньясы киңлегендә сурәтләнгән. Мондый композиция И. Айвазовскийның «Пушкин на берегу моря» (Верещагин исемендәге сәнгать музее, Николаев, Украина) дигән мәгълүм картинасын (1887) хәтерләтә. Анда да бит шагыйрь диңгезнең кыялы ярында бик рәсми кыяфәттә (костюмнан, жилеттан, кулында эшләпә) сурәтләнгән. Диңгез тынычсызлана, дулкынлана, ә А. Пушкин, салып, таш өстенә җәйгән костюмына утырган хәлдә кешелек дөньясының кампа-каршылыгын (гади костюм, поэзияне гәүдәләндергән табигать көче) символлаштыра кебек. Г. Ибраһимовка багышланган «халыкчан картина»да шуңа охшаш композициягә нигезләп иҗат ителгән. Монда картинаның кайда, кайчан ясалуы, аның сәнгати чишелеше түгел, ә авторның язучыга җылы мөнәсәбәтен чагылдыра алуы мөһим.

Г. Ибраһимов образын романтикларча чагылдыруның тагын бер варианты Валерий Скобеевның (1938) «Мулланур Вахитов белән Галимҗан Ибраһимов Ленин янында» (1978, ТР дәүләт Сынлы сәнгать музее) картинасында кабатлана. Бу эш ТАССР Мәдәният министрлыгы заказы белән башкарылган булган. Автор сүзләренчә, картина: «отца советского государства и общественных лидеров татарского народа, рассказать о становлении татарской национальной автономии, изобразить роль татар в становлении российской государственности» [Скобеев, с. 48–49] кебек сәяси күренешләр турында сөйләргә тиеш була. В.И. Ленин татар милли лидерлары белән 1918 елда очраша. Юлбашчының Кремльдәге кабинетын рәссам натурадан ясый. Ә Г. Ибраһимов образы өстендә эшләве турында ул болай яза: «Мне было легко писать Галимджана Ибрагимова, потому что я видел немало его фотографий в различных ракурсах. В его облике мне хотелось передать решимость, с которой он отстаивал право татар и башкир на национальное самоопределение. Это можно заметить по чуть согнутой, напряженной руке, сжатой в кулак, и волевой светотени на лице. При этом он все же показан как человек творческий и одухотворенный – сразу видно, что это не военный и не чиновник» [Скобеев, с. 48–49].

Бу картинаның язмышы катлаулырак килеп чыга: Г. Ибраһимовның тууына 100 ел тулуга багышланган юбилей күргәзмәсендә (1987) ул үзәк урынны били, аннан югала. Башта картина ТР дәүләт Сынлы сәнгать музееның Лениногорск филиалына барып эләгә һәм анда озак вакытлар төрелгән хәлдә ята, һәм аны табып алып, ТР Дәүләт Советында һәм Казан Кремлендә оештырылган рәсми күргәзмәләргә куялар. Хәзер бу картина ТР дәүләт Сынлы сәнгать музеенда саклана.

Г. Ибраһимов образын гәүдәләндергән әлеге эшләр белән

кыскача танышканнан соң, аларның рәсми, романтик һәм халыкчанлык (хәтта фольклор герое сыман) юнәлешләрендә иҗат ителүе аңлашыла. Шуны билгеләп үтәргә кирәк, аның рәсми образы булып, барыбер, М. Горький сыйфатлары чагылдырылган пролетар язучы кыяфәтендәге портреты кабул ителә, язучы үзе дә хис иткәнчә, татар халкы да аны шул рәвештә күз алдына китерә. Ә инде аның романтикларчарак рухтагы вариантлары Совет чорының соңгы елларында гына киң тарала, чөнки бу вакытта аның образы мификлаша башлый һәм тора-бара язучы фигурасы сынлы сәнгать сферасыннан бөтенләй төшеп кала.

**Әдәбият**

*Ваганова Ф.Г.* Становление искусства татарской рукописной и печатной книги XVII – начала XX в.: стилистика и символика: дис. ... канд. искусствоведения. Казань, 2015. С. 161.

*Ваганова Ф.Г.* Роль Федора Быкова в становлении книжной графики Татарстана. // 115-летие Казанской художественной школы: сборник материалов Межрегиональной научно-теоретической конференции (октябрь, 2010). Казань: Слово, 2010. С. 81–86.

*Скобеев В.* 20 минут в кабинете вождя // Татарстан. 2007. № 3. С. 48–49.

***Әхмәтова Динә Ирек кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 902(47)

*А.Г. Ситдиков, И.Р. Кәримов*

# ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ А.Х. ХАЛИКОВ ИСЕМЕНДӘГЕ АРХЕОЛОГИЯ ИНСТИТУТЫНЫҢ 2016 ЕЛДАГЫ ФӘННИ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨП НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА

Статья посвящена подведению кратких итогов научно-исследовательской и научно-организационной работы Института археологии им. А.Х. Халикова АН РТ за 2016 год.

**Ключевые слова:** Институт археологии им. А.Х. Халикова, археология Поволжья и Урала, археология Золотой Орды.

А.Х. Халиков исемендәге Археология институтының 2016 елдагы фәнни-тикшеренү һәм фәнни-оештыру эшчәнлеге Институтның Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Президиумы тарафыннан расланган 2020 елга кадәрге үсеш стратегиясенең башлангыч этабын тәшкил итте. Аның кысаларында тормышка ашырыла торган инновацион характердагы комплекслы дисциплинаара тикшеренүләр Россиядә һәм чит илләрдә тарихи-археологик тикшеренүләргә карата куелган яңа таләпләргә җавап бирә. Алар Идел – Урал регионы, аның белән чиктәш һәм тагын да киңрәк территорияләрнең, аерым алганда Евразия киңлекләренең, киң вакыт аралыгында, ягъни таш гасырдан башлап Яңа чорга кадәрге тарихи-мәдәни үсешенең тулы һәм объектив картинасын тудырырга мөмкинлек бирә.

2016 елда Институт хезмәткәрләре эшчәнлегенең фәнни нәтиҗәлелеге мөһим дәрәҗәдә артты, алар тарафыннан башкарыла торган тикшеренүләрне милли стандартлардан халыкара стандартларга күчерүнең тотрыклы тенденциясе барлыкка килде. Басылып чыккан хезмәтләр санының ике тапкырга диярлек артуы моны ачык раслый. Институт хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәләре 19 монографиядә һәм 217 фәнни мәкаләдә чагылыш тапты.

Шул ук вакытта Институт тарафыннан оештырылган конференцияләр саны да артты. Үткәрелгән фәнни чаралар, тикшеренү эшчәнлеге нәтиҗәләрен апробацияләү өчен мөһим дискуссия мәйданчыкларын тәэмин итү белән бергә, А.Х. Халиков исемендәге Археология институтының 2016–2020 елларга үсеш стратегиясен тормышка ашыру этаплары да булып торалар. Фәнни һәм иҗтимагый әһәмияткә ия вакыйгалардан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе эгидасы астында үткәрелгән Россия һәм БДБ илләре ислам археологиясе конгрессын, «Евразия киңлекләрендә шәһәр һәм дала культуралары диалогы. Алтын Урданың тарихи географиясе»

VII халыкара конференциясен, «Ананьино дөньясы: мәдәни киңлек, бәйләнешләр, традицияләр һәм новацияләр», «I Старостин укулары: Урта Идел буе һәм Кама алдының б.э.ның I меңьеллыгының беренче яртысы һәм уртасына караган төп һәйкәлләре» халыкара катнашлыктагы гомумроссия конференцияләрен, Палеоэкологик методларны археологиядә куллану буенча халыкара фәнни-гамәли семинарны атап үтәргә мөмкин. Үткән елда Институт тарафыннан барлыгы 16 фәнни конференция оештырылды. Болар – 8 халыкара, 5 халыкара катнашлыктагы гомумроссия һәм 3 гомумроссия дәрәҗәсендәге чаралар.

2016 елда бөтен структур берәмлекләр катнашында Институтның фәнни стратегиясен тормышка ашыруның төп максатын тәшкил иткән 7 томлык «Идел – Урал регионы археологиясе»н төзү эше башланды. Әлеге уникаль күп томлык академик басма археология мәгълүматларын тагын да киңрәк күзалларга һәм аларны Идел – Урал регионы халыкларының борынгы заманнардан башлап Яңа чорның башлангыч этабына кадәрге тарихын комплексы рәвештә реконструкцияләү өчен нигез итеп алырга мөмкинлек бирәчәк. Бүгенге көндә басманың структурасы билгеләнде, аның нәшрият советы оештырылды, монографиянең авторлары – РФАнең академик институтлары һәм региональ үзәкләре, Мәскәү, Кырым Республикасы, Самара, Уфа, Пермь, Ижевск, Чабаксар, Йошкар-Ола, Пенза, Астрахань, Саратов, Сыктывкар, Алабуга музейлары һәм югары уку йортларының хезмәткәрләре материал әзерләү эшен башлады. Басманы әзерләүдә 100 дән артык галим һәм белгеч катнаша, аны эшләүгә авторлар һәм экспертлар сыйфатында чит илләрдәге фәнни-тикшеренү үзәкләренең белгечләре дә җәлеп ителәчәк.

2016 елда Институтның фәнни-тикшеренү эшчәнлеге 4 фундаменталь юнәлеш буенча алып барылды.

**1 нче юнәлеш. Идел – Урал регионы археологик культураларының күчүчәнлеге һәм дәвамчанлыгы.** Бу юнәлеш кысаларында башлангыч тимер чоры Идел-Кама шәһәрлекләрен өйрәнү буенча үткәрелгән дисциплинаара тикшеренүләр нәтиҗәсендә аларның табигый тирәлеге торгызылды, саклану корылмаларының төзелеш тарихы өйрәнелде, борынгы кешеләрнең әйләнә-тирә ландшафтка йогынтысының дәрәҗәсе билгеләнде һәм шул ук вакытта башлангыч тимер чоры – башлангыч урта гасырлар чоры саклану корылмаларын комплеклы өйрәнү методикасын камилләштерү эше дәвам ителде. Регионда таш һәм башлангыч металл чорында яшәгән кабиләләр эшчәнлегенең палеоэкологик шартларын һәм төп юнәлешләрен палеогеография һәм таш коралларны функциональ-трасологик анализ методлары комплексын кулланып өйрәнү эше дәвам ителде. Тикшеренүчеләр тарафыннан Идел – Урал регионында башлангыч тимер гасырыннан Халыкларның бөек

күчеш чорына һәм аннан соң башлангыч урта гасырларга күчеш этабында яшәгән халыкларның матди культурасы һәм күмү йолалары үзенчәлекләре ачыкланды. Идел – Кама буендагы халыкларның бөек күчеш чорына караган торак һәм күмү һәйкәлләрен өйрәнү барышында мәгълүматларны кыр шартларында теркәү һәм тарихи вакыйгаларны торгызуның заманча методларын кулланып үткәрелгән комплекслы археологик һәм палеографик тикшеренүләр борынгы археология өлкәсендәге дисциплинаара тикшеренүләрне яңа баскычка күтәрде.

Аерым алганда, урта гасырларда Урта Идел буенда яшәгән шәһәр халкының антропологик составы турында яңа мәгълүматлар алынды. Борынгы ДНКның морфологик анализы нигезендә урта гасыр шәһәр җәмгыятенең кайбер генетик чыганаклары билгеләнде. Фәнни кулланылышка Таулы Алтайдагы Кимәк каганлыгы территориясеннән күчеп килгән кайбер этник төркемнәрнең антропологик составын билгели торган краниологик материаллар кертелде. Урта Идел буенда яшәгән борынгы кешеләр арасында таралган авыруларның уникаль статистикасы әзерләнде, кеше һәм хайван ДНКсы патогеннарының коллекциясе төзелде. Төрле хронологик этапларга, урынчылыкларга һәм мәдәниятләргә караган археологик һәйкәлләрдән 500 дән артык скелетка инвентаризация ясалды. Болгар шәһәрлегендә алып барылган казу эшләрендә табылган скелетлардагы механик травмаларны һәм патологик үзгәрешләрне өйрәнү өлкәсендә архебиологик лаборатория белән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Суд-медицина бюросы хезмәткәрләре арасында хезмәттәшлекне координацияләү эше дәвам ителде. Казан федераль университеты биологлары һәм генетиклары белән бергә Идел буендагы борынгы халыкларның килеп чыгышын һәм генетик бәйләнешләрен өйрәнү, борынгы авыруларны ачыклау, аларның таралыш дәрәҗәсен һәм юлларын билгеләү эшләре алып барылды.

**2 нче юнәлеш. Идел – Урал регионы халыклары Евразиянең урта гасыр мәдәниятләре системасында. Бөек ефәк юлы.** Бу юнәлеш кысаларында Идел Болгары, Алтын Урда, Казан ханлыгында төрки-татар мәдәниятенең барлыкка килүе һәм эволюциясенең фундаменталь проблемаларын өйрәнү өлкәсендә мөһим нәтиҗәләргә ирешелде. Алар барысы да үзара бәйләнештә каралды һәм бу Идел буе халыкларының киң вакыт аралыгында – Урта гасырлардан башлап Яңа чорга кадәр – этник, социаль һәм мәдәни яктан үсешен өйрәнү белән бәйле күпкырлы мәсьәләләрне чишүнең яңа юлларын билгеләргә мөмкинлек бирде. Әлеге проблемаларны хәл итүдә актив рәвештә Евразия киңлекләре урта гасыр археологиясе конгрессы, Болгар форумы, «Идел-Алтай» форумы кебек Координацион фәнни үзәкләр институты нигезендә оештырылган һәм Дунайдан алып Ерак Көнчыгышка кадәрге киңлекләрдә

эшләүче белгечләрне берләштергән уртак тикшеренү төркемнәре катнашты.

Мөселман археологиясе проблемаларын тикшерү кысаларында Казанда Татарстан Фәннәр академиясе эгидасы астында илдә беренче тапкыр Россия һәм БДБ илләре мөселман археологиясе конгрессы үткәрелде. Фәнни әйләнешкә урта гасыр шәһәр культурасы, культ архитектурасы, традицион хуҗалык, күмү һәм искә алу йолалары, Евразия мөселман халыкларының этнографик үзенчәлекләре буенча күп кенә уникаль материаллар кертелде.

Гомумроссия масштабындагы фәнни вакыйгалардан Ялта шәһәрендә үткән «Евразия киңлекләрендә шәһәр һәм дала культуралары диалогы. Алтын Урданың тарихи географиясе» VII халыкара конференциясен атарга мөмкин. Анда киң планда Евразиянең урта гасырлар тарихында Алтын Урданың ролен һәм урынын өйрәнү белән бәйле күпсанлы мәсьәләләр каралды. Шуның белән бергә Җучи Олысы археологик һәйкәлләре өлкәсендә алып барылган күпьеллык тикшеренүләрнең нәтиҗәләре гомумиләштерелде, фәнни әйләнешкә дала күчмә халыклары субкультурасының Алтын Урдадагы социаль-икътисади процессларга йогынтысын күрсәтә торган материаллар кертелде. Бу Идел – Урал регионы, чиктәш өлкәләр һәм гомумән Евразиянең урта гасыр археологиясенең теоретик һәм практик нигезен сизелерлек дәрәҗәдә актуаль мәгълүмат белән тулыландырырга мөмкинлек бирде.

**3 нче юнәлеш. Татарстан археологиясе: саклау, өйрәнелү тарихы һәм музейлаштыру.** Бу юнәлеш кысаларында 2016 елда Институтның археологик һәм фәнни фондын оештыру эше дәвам итте. А.Х. Халиков исем. Археология институтының музей коллекциясе Татарстан Республикасы һәм гомумән Идел – Урал регионы археологик объектларында алып барылган эзләнүләр нәтиҗәсендә табылган һәм башка профильле музейларның фондларында урын алмаган яңа ***8000*** фәнни, мәдәни-тарихи һәм музей әһәмиятенә ия булган предметлар белән баетылды. Беренче тапкыр Россия Федерациясе музей фондының дәүләт өлешенә Татарстан Республикасы милке саналган һәм юридик яктан Татарстан Фәннәр академиясе карамагына беркетелгән ***2000*** нән артык археология һәм нумизматика музей экспонаты кертелде. Гомумән алганда, Археология институтының музей тупланмасын ***11187*** археология һәм нумизматика предметы тәшкил итә. ТР Археология музееның археологик коллекцияләрен системалаштыру буенча алып барылган эшчәнлек нәтиҗәсендә артефактларның тулы фәнни тасвирламасын үз эченә алган ***29*** коллекцион исемлеккә кертелгән ***5000*** нән артык музей предметы эшкәртелде.

Татарстан Республикасы археологик һәйкәлләреннән тупланган коллекцияләрне камераль һәм фәнни-техник эшкәртү буенча алып барылган масштаблы эш ТР музейларына һәм музей-тыюлыкларына ***95000*** гә

якын предметны тапшырырга мөмкинлек бирде. Археология институтының музей фәнни-документаль фонды якынча ***3000*** саклау берәмлеген тәшкил итә. Археология музеена караган төп коллекцияләрнең ***300*** дән артык уникаль һәм аеруча әһәмиятле археологик предметлары Татарстан музей һәм музей-тыюлыклары күргәзмәләрендә һәм экспозицияләрендә тәкъдим ителде. Музей предметлары һәм коллекцияләре Институт тарафыннан алып барылган Идел – Кама регионы тарихи-мәдәни мирасын популярлаштыру һәм туган як тарихы буенча уку-укыту программалары төзү эшенең мөһим бер өлеше булып тора.

**4 нче юнәлеш. Археометрия.** Институтта җирне дистанцион зондлаштыру, геофизика методларын, шулай ук архебиология, химия, физика, математика, мәгълүмати технологияләр белән бәйле методикаларны җәлеп итеп, объектларны ачыклау һәм өйрәнү өлкәсендә заманча технологияләр киң кулланыла. Бу – мәдәни мирас объектларыннан алына торган мәгълүматның сыйфатын һәм диапозонын сизелерлек дәрәҗәдә арттыруга ярдәм итә. 2016 елда Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы, Зөя, ГИАХМЗ, Иске Казан музей-тыюлыгы, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы һәм Татарстан Республикасы археология музееннан металл, агач, тире, тукыма, керамикадан ясалган ***5000*** нән артык предмет эшкәртелде. Дисциплинаара тикшеренүләр нәтиҗәсендә Институт галимнәре тарафыннан катлаулы составка ия күп катламлы тәңкәләрне урта гасыр акча сугучылары кулланган югары пробалы көмеш авырлыгына якынайтуның Россия һәм чит ил белгечләрендә зур кызыксыну уяткан уникаль технологиясе эшләнде. Фәнни һәм эксперименталь эшләр Россия ФА ФТИ, ГосНИИР, Левен шәһәре Католик университеты (Бельгия), Бабэш-Боляй шәһәре университеты (Румыния), Казан федераль университеты, А.Н. Туполев исем. КМТТУ, КХТИ белән тыгыз элемтәдә алып барылды.

Институт эшчәнлегенең актуаль юнәлеше – «Татарстанны археологик өйрәнү» геомәгълүмати система төзү. Аның кысаларында 2016 елда Татарстан Республикасын археологик яктан өйрәнүнең идарә ителә торган мәгълүмат базасы – Татарстан Республикасы тарихи-мәдәни мирас объектларының бердәм дәүләт реестры эшләнде. Геомәгълүмати технологияләрне куллану 1:50 000 масштабында геомәгълүмат базасын булдырырга мөмкинлек бирде. Ул гомумгеографик һәм Татарстан Республикасының алты районындагы археологик мирас объектлары турындагы информацияне үз эченә ала. Шулай ук һәйкәл территориясе Куйбышев сусаклагычы астында калганчы һәм су басканнан соң андагы каберлекләрнең урнашу урыннарына анализ ясалды, аның өч үлчәмле моделе төзелде, барлык күмелү урыннары яңадан торгызылды, артефактлар казу эшләре отчетларының мәгълүматлары буенча урнаштырылды.

Институтның күп аспектлы фәнни-тикшеренү эшчәнлегенең мөһим юнәлешләреннән берсе – «Поволжская археология» («Идел буе археологиясе») журналын чыгару. Ул – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе системасындагы гуманитар профильдәге басмалардан ВАКның рецензияләнә торган басмалар исемлегенә кертелгән бердәнбер журнал. 2016 елда аның Идел – Урал регионы, тулаем алганда Россия һәм чит илләрнең атаклы галимнәрен үз эченә алган авторлар даирәсе киңәйде. Журнал битләрендә Евразиянең борынгы истәлекләрен өйрәнү өлкәсендә археология фәне үсешенең хәзерге тенденцияләрен чагылдырган иң алдынгы тикшеренүләрнең нәтиҗәләре чагылыш таба. Үткән елда аның ***4*** саны дөнья күрде. Аларда гомуми күләме ***95,6*** басма табакны тәшкил иткән ***59*** мәкалә басылды. Шулардан ***43*** мәкалә Институт хезмәткәрләре тарафыннан язылды.

2016 елда ТР ФАнең А.Х. Халиков исем. Археология институты белән Ш. Мәрҗани исем. Тарих институтының уртак фәнни-нәшрият проекты саналган «Алтын Урда нумизматикасы» еллык басмасын чыгару эше дәвам итәлде. Әлеге басмада Җучи Олысында икътисади мөнәсәбәтләрнең барлыкка килүе һәм үсешенең күпсанлы аспектлары чагылыш таба. Үткән елда аның битләрендә гомуми күләме ***20*** басма табакны тәшкил иткән ***17*** мәкалә дөнья күрде. Аларның авторлары – Россия һәм чит илләрдәге эре фәнни үзәкләрнең белгечләре.

Шулай ук «Зөя утрау-шәһәрен һәм Бөек Болгарны яңадан торгызу» дәүләт программасы кысаларында тормышка ашырыла торган археологик тикшеренүләр дәвам итәлде. Нәтиҗәдә әлеге тарихи территорияләрнең үсеш этаплары, аларның социаль-икътисади, рухи-мәдәни тормышы, кешеләренең көнкүреше турында яңа мәгълүматлар алынды. Алынган мәгълүматлар халыкара һәм гомумроссия дәрәҗәсендә оештырылган ***6*** конференциядә апробация үттеләр. Тормышка ашырылган чаралар тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану, уникаль һәйкәлләрне һәм тарихи территорияләрне Россия һәм халыкара туризм программаларына кертүнең тулы системасын барлыкка китерү буенча алып барылган эшнең мөһим өлешен тәшкил итәләр.

Институт тарафыннан Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау буенча дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасыннан читтә – Саратов, Төмән, Астрахань, Ульяновск, Рязань, Түбән Новгород өлкәләрендә, Ставрополь краенда һәм Кырым Республикасында 2014–2016 елларда алып барылган тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен гомумиләштерү фәнни эшчәнлекнең мөһим этабы булып тора. Әлеге эзләнүләр нәтиҗәсендә фәнни әйләнешкә Евразия мәдәниятен өйрәнү контекстында татар халкы һәм аның борынгы бабалары тарихы буенча кыйммәтле мәгълүматлар кертелде.

Институт хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасында хуҗалык максатларында

үзләштерү каралган җир участокларына тарихи-мәдәни экспертиза үткәрү белән бәйле ихтыяҗны канәгатьләндерү буенча җитди эш алып барыла. 2016 елда республиканың бюджетын оештыра торган нефть табу һәм нефть эшкәртү тармакларына караган һәм үз эченә «Татнефть», «ТАИФ», «Транснефть-Прикамье» объектларын да алган проектлар археологик экспертизалар белән тәэмин ителде. Археологик эзләнүләр, гомумән алганда, ***155*** объектта һәм ***31,6*** кв. км. мәйданда алып барылды.

Институтның Россия һәм халыкара фәнни даирәләр интеграциясенә ярдәм иткән мөһим факторларның берсе – эшнең яңа заманча фәнни-оештыру формаларын булдыру. Әлеге эшчәнлекнең нәтиҗәле үрнәге буларак КФУ белән бергә оештырылган «Археометрия» өстенлек үзәге һәм «Дөнья мәдәни мирасы» фәнни һәм уку-укыту ресурс үзәге эшчәнлеге кысаларында Казан федераль университеты белән актив хезмәттәшлекне атап үтәргә мөмкин. Моннан тыш А.Х. Халиков исем. Археология институты һәм Казан федераль университеты бергә даими рәвештә үткәрә торган «Дисциплинаара гуманитар тикшеренүләр системасында археология» семинарының эше дәвам итте. Анда модераторлар һәм чыгыш ясаучылар буларак дисциплинаара гуманитар тикшеренүләрне тормышка ашыру өлкәсендә зур тәҗрибәгә ия булган Россия һәм чит илләрнең атаклы галимнәре катнашты.

Институтның дөньякүләм мәгариф даирәсенә интеграция стратегиясен тормышка ашыру, заманча уку-укыту һәм халыкара академик алмашу программаларын эшләү А.Х. Халиков исем. Археология институты тарафыннан Казан федераль университеты белән бергә Болгар шәһәрендә үткәрелә торган Халыкара кыр археологиясе мәктәбе эшчәнлегендә чагылыш тапты. Анда дөньяның ***7*** иленнән яшь галимнәр катнашты. Укытучылар буларак Россия һәм чит илләрдәге дәрәҗәле фәнни үзәкләрнең әйдәп баручы белгечләре чакырылды.

А.Х. Халиков исем. Археология институтында алып барыла торган фәнни тикшеренүләр киң регионара һәм халыкара хезмәттәшлек нигезендә тормышка ашырыла. Институтның Дәүләт заданиесен һәм «ТР ФА Археология институтының 2016–2020 елларга үсеш стратегиясе»н тормышка ашырудагы партнерлары булып Россия һәм чит илләрнең әйдәп баручы фәнни үзәкләре тора. 2016 елда Институт тарафыннан Сент-Клауд дәүләт университеты (Миннесота, АКШ), Макс Планк институты (Германия), Азәрбайҗан Милли фәннәр академиясенең Археология һәм этнография институты, Көньяк Казакъстан өлкәсе мәдәният идарәсенең Көньяк Казакъстан өлкәсе тарих һәм туган як музее, Казакъстан Республикасы «Азрет Султан» дәүләт тарихи-мәдәни музей-тыюлыгы, А.В. Щусев исемендәге архитектура дәүләт фәнни-тикшеренү музее, Россия Фәннәр академиясе Урал бүлегенең Тарих һәм археология

институты, Россия Фәннәр академиясенең Калмык гуманитар тикшеренүләр институты, Удмурт дәүләт университеты, Мари дәүләт университеты, Пермь дәүләт гуманитар-педагогика университеты, П.В. Алабин исемендәге Самара өлкәсе тарих һәм туган як музее кебек Россия һәм чит илләрдәге тикшеренү үзәкләре белән фәнни хезмәттәшлек турында 12 яңа килешү төзелде.

А.Х. Халиков исем. Археология институты аспирантурасында **9** кеше белем ала. Бүгенге көндә 1–4 уку елы аспирантлары тарафыннан индивидуаль эш планнары тулысынча үтәлде, алар аттестацияләнеп, киләсе уку елына күчерелделәр. Аспирантларның диссертация темалары Институтның фәнни-тикшеренү эшчәнлегенең гомуми юнәлешләренә тулысынча туры килә.

А.Х. Халиков исем. Археология институты галимнәре һәм белгечләренең күпкырлы фәнни-тикшеренү эшчәнлеге, үзенең югары фәнни нәтиҗәлелегеннән тыш, Татарстан Республикасының Идел – Урал регионы һәм, гомумән, Евразия мәдәниятенең үткәнен өйрәнүдә Институтның әйдәүче лидер буларак танылуына ярдәм итә. Шуның белән бергә Институт ил һәм дөньякүләм масштабта алып барылган әлеге юнәлештәге тикшеренүләрнең төп координаторларының берсе булып санала.

***Ситдиков Айрат Габит улы,***
*тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасы*
*Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы, ТР ФА А.Х. Халиков исемендәге*
*Археология институты директоры*
*sitdikov_a@mail.ru*

***Кәримов Илдар Рим улы,***
*тарих фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА А.Х. Халиков исемендәге Археология институты*
*гыйльми сәркатибе*
*ildar.karimov@list.ru*

УДК 929

***Ф.Й. Йосыпов***

# В.В. РАДЛОВ – РОССИЯНЕҢ КҮРЕНЕКЛЕ ТЮРКОЛОГЫ

*(В.В. Радловның тууына 180 ел тулу уңаеннан)*

В статье рассматривается научно-исследовательская деятельность всемирно известного тюрколога Василия Васильевича Радлова, который в течение своей шестидесятилетней научной деятельности охватил практически все области тюркологии: диалектографию и диалектологию, лексикографию и лексикологию, сравнительную и историческую фонетику и грамматику тюркских языков, текстологию и издание тюркской письменности на руническом, уйгурском, арабском алфавитах, тюркский фольклор, этнографию, историю, археологию.

**Ключевые слова:** В.В. Радлов, тюркология, диалектология татарского языка, памятники древнетюркской письменности.

Дөньякүләм танылган тюрколог Василий Васильевич Радловның киң колачлы фәнни-тикшеренү эшчәнлеге XIX гасырның 60 нчы елларында башлана. Н.Ф. Катанов, И.Н. Березин, О.Н. Бётлингк, Н.И. Ашмарин һ.б. кебек галимнәрнең һәркайсы рус тюркологиясе барлыкка килүгә һәм аны үстерүгә зур өлеш кертсәләр дә, алар фәнни эшчәнлек алып барган дәвер дөнья тюркологиясе тарихына барыбер Радлов чоры булып теркәлгән.

В.В. Радловның 60 ел дәвамында алып барган фәнни эшчәнлеге тюркологиянең барлык өлкәләрен: диалектография һәм диалектологияне, лексикография һәм лексикологияне, төрки телләрнең чагыштырма һәм тарихи фонетика һәм грамматикасын, рун, уйгур һәм гарәп алфавитларындагы төрки текстологиясен нәшер итүне, төрки фольклорны, этнографияне, тарихны, археологияне – барысын да колачлый [Кононов, с. 9].

Тюркологик әдәбиятта В.В. Радловның иҗади мирасын өйрәнүгә күпсанлы фәнни мәкаләләр һәм биографик очерклар багышланган, алар галимнең киңкырлы эшчәнлеге, аның тормышы һәм фәнни хезмәтләре хакында теге яки бу дәрәҗәдә күзалларга ярдәм итәләр. Шул ук вакытта, ни гаҗәп, төрки телләр буенча мәшһүр шәхесне без әле бөтенләй диярлек белмибез икән.

В.В. Радлов 1837 елда Берлинда туа. Гимназияне тәмамлагач, 1854 елда Берлин университетының фәлсәфә факультетына укырга керә. Башта ул теология белән мавыга, әмма озак та үтми, чагыштырма-тарихи тел белеме белән кызыксына башлый.

Ул вакытта Галледа чагыштырма тел белеме, фонетика өлкәсенең күренекле галиме, фәнни этимологиягә нигез салучы Август Потт лекцияләр укый торган була. Яшь студент Радлов, ике дә уйлап тормыйча, шунда китә, һәм ике семестр дәвамында әлеге галимнең лекцияләрен тыңлый.

Алар Радловның алдагы фәнни эзләнүләре өчен гаять файдалы булалар. Берлинга әйләнеп кайткач, ул филология белән шөгыльләнүен тагын да киңәйтеп җибәрә. Берлин университетының данлыклы географы һәм тарихчысы Карл Риттер лекцияләре дә аның үзе сайлаган өлкәдәге фәнни карашлары формалашуда зур роль уйный. Шулай да аның фәнни мавыгуларын тирәнәйтүдә һәм үзен ориенталистикага багышларга этәргеч бирүдә В. Шоттның йогынтысы көчле була. Радлов аның ярдәмендә монгол, татар, маньчжур, кытай һ.б. телләрен өйрәнә, урал-алтай телләре буенча өр-яңа теорияләр белән кораллана, аларның проблемаларына үтеп керә. Шотт дәресләрендә Радлов ориенталист булырга омтылса, К. Риттер концепцияләре аңа тарихи һәм этнографик карашларының формалашуына ярдәм итә.

Россиянең Азия өлешендәге халыклар белән кызыксыну Радловта студент елларында – чагыштырма тел белеме өлкәсендәге тикшеренүләргә омтыла башлагач ук барлыкка килгән була. Студент чагында ук инде ул О. Бётлингкның классик югарылыктагы бер хезмәтен – якут теле грамматикасын өйрәнә. Ул китап Радловта тирән тәэсир калдыра.

Әкренләп, Радловта төрки халыкларның телен, тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү белән шөгыльләнергә дигән ныклы карар барлыкка килә. Әмма моның өчен Россиягә күчеп китәргә кирәк була. 1854 елда Петербург университетында көнчыгыш факультеты оеша. О. Бётлингк та шунда эшли. Нәкъ менә шунда Көнчыгышны өйрәнү буенча фәнни экспедицияләр оештыруга әзерлек башлана.

1858 елның җәендә Шоттның рекомендация хаты белән Радлов Петербургка килә һәм телләр буенча ныклы, тирән белем алу өчен көнчыгыш факультетына укырга керергә җыена, әмма аннан соң ул, бу уеннан кире кайтып, Азия музее китапханәсендә үзе сайлаган юнәлеш буенча мөстәкыйль шөгыльләнә башлый. Ул төрки телдә сөйләшүчеләр белән турыдан-туры аралашу мөмкинлекләрен эзли. Нәкъ менә шушы максат белән ул Ф.Б. Шмитд җитәкчелегендәге Рус географик җәмгыяте экспедициясендә катнашырга омтыла, һәм тунгус халыкларын өйрәнү өчен Амур краена китмәкче була. Тик, барыбер, Радловны, ниндидер сәбәпләр аркасында, ул экспедициягә алмыйлар.

Шул чорда Россиянең Берлиндагы элеккеге илчесе П.К. Мейендорф Радловка Барнаулдагы тау училищесында немец һәм латин телләрен укытырга тәкъдим итә. Бу аңа Алтай телләрен алар белән турыдан-туры аралашып өйрәнергә менә дигән мөмкинлек була. 1859 елның 11 маенда Радлов Россия гражданлыгын кабул итә һәм аңа тугрылыкка ант бирә, шушы көннән башлап, *Фридрих Вильгельм Radloff* Василий Васильевич Радлов булып китә. 1859 елның 14 маеннан ул Барнаулга эшкә җибәрелә. Бер үк вакытта ул җәйге ялларында Алтай буйлап экспедицияләрдә йөрү мөмкинлегенә ия була. Бу максатларын

тормышка ашыру өчен биш ел дәвамында аңа хөкүмәт субсидиясе билгеләнә. Ул бу тәкъдимне икеләнүсез кабул итә һәм гимназия укытучысы исемен алу өчен тиешле имтиханнар тапшырып, Барнаулга юнәлә.

1845 елда оешкан Рус географик җәмгыяте экспедицияләре Россиянең Азия өлешендәге беренче этнографик карта төзү белән шөгыльләнә, В.В. Радлов Барнаулга килгәнче, Көньяк Себернең бу киңлекләре беркем тарафыннан да өйрәнелмәгән була.

Радлов, Алтайга килүгә үк, үзе өчен җирле төрки халыкларның телләрен өйрәнүне, аларның фольклор үрнәкләрен җыюны, җирле халыкның көнкүреше белән танышуны, крайдагы тарихи һәйкәлләрне барлауны үз эченә алган лингвистик һәм этнографик бурычлар планын билгеләп куя. Ул бу яклардагы төрки халыкларның җанлы сөйләмен үзләштерүне максат итә, һәм тиздән җирле губернатор ярдәме белән алтай телләрен бик яхшы белүче Яков Тонжан белән таныша. Радлов төрки телләрне, аларның фольклорын, тарихын җентекләп өйрәнә башлый. Көндезләрен ул Тау училищесында дәресләр бирә, ә кичләрен информантлар белән шөгыльләнә. 1860/61 ел кышында ул җирле халыкларның сөйләм телен үзләштерүгә ирешә. Һәм җәйге фәнни сәяхәтләре вакытында кешеләр белән алар телендә аралаша башлый.

Алтайга беренче сәяхәтен Радлов 1860 елда ук ясый, анда ул үзенең әле генә Берлиннан килгән яшь хатынын һәм алтайлы Яков Тонжанны да ала.

Аннан соңгы елларда инде Радлов алтайлыларны гына түгел, ә алар белән күрше территорияләрдә яшәүче Көньяк Себер, Урта һәм Үзәк Азиянең төрки телле халыкларын өйрәнүгә дә зур игътибар бирә.

Үз сәяхәтләренең фәнни нәтиҗәләрен ул Алтайда чагында ук бастырып чыгара башлый. 1861–1863 елларда, мәсәлән, аның немец телендә «Алтайдан хатлар»ы, 1863–1864 елларда кыргызлар (казакълар. – *Ф.Й.*) турындагы язмалары нәшер ителә. Озак та үтми, В.В. Радловның шулай ук немец телендә «Путешествие через Алтай к Телецкому озеру и Абакану» (1865), «Долина Тли в Центральной Азии и ее жители», «Этнографический обзор тюркских племен Сибири и Монголии» (1883) дигән хезмәтләре дөнья күрә.

В.В. Радлов, этнографик бурычлардан тыш, төрки халыкларның ыруглык составын ачыклауга зур игътибар бирә, Кастрен кебек үк, ул да, теге яки бу халыкның ыруглык составын өйрәнү аның төп чыгышын ачыклауда әһәмиятле чыганак булып тора, дип исәпли [Вайнштейн…, 1972, с. 22].

В.В. Радлов тарафыннан уздырылган бу тикшеренүләр нәтиҗәсендә Себердә һәм Монголиядә яшәүче төрки кабиләләрнең этник составына багышланган гаҗәеп бай белешмә басылып чыга. В.В. Радловның бу хезмәте, күләме белән әллә ни зур булмаса да, тюркология һәм этнография фәнендә төрки халыкларның

этногенезы буенча гадәттән тыш мөһим нәтиҗәләргә ия булып тора. Анда, Себердәге тофалардан башлап, Урта Азиядәге үзбәкләрне эченә алган төрки халыкларның күп кенә төркемнәре буенча яңа мәгълүматлар китерелә.

Бараба, Тара, Төмән һәм Тобол татарлары хакында В.В. Радлов бу төркемнәр барысы да Алтай телеутларының якын кардәшләре, фәкать аларның телләре генә Урта Азия төркиләре йогынтысында кайбер үзгәрешләр кичергән, дип исәпли. «Татары, которые проживают на среднем Иртыше и его притоках Таре, Тоболе, Ишиме, представляют смешанный народ из сибирских татар с пришельцами из Средней Азии и Восточной России. В соответствии с их происхождением, их язык представляет комплекс особенностей и наречий… Все эти этнические группы – близкие родственники алтайских телеутов» [Вайнштейн…, 1972, с. 22; Радлов, с. 232].

Алтайда яшәгән ун ел дәверендә В.В. Радлов алтайлылар, телеутлар, шор, коман (кыпчак), тывалы, казакъ, кыргызлар, Абакан татарлары (хакаслар), Көнбатыш Себер татарлары, кытайлар янына ел саен сәяхәт кыла. Болардан тыш, 1866 елдан башлап, ул үзенең фәнни тикшеренү нәтиҗәләрен нәшер итеп бара. Шул ук елда аның мәшһүр «Образцы народной литературы тюркских племен» хезмәтенең беренче томы, 1868 елда – икенче, 1878 елда өченче томы дөнья күрә. В.В. Радлов гомеренең күп елларын Россиядәге бараба, төмән һәм тобол татарларының, казакъ, кыргыз, уйгур, кырым татарлары һәм башка төрки кавемнәрнең халык поэзиясе үрнәкләрен туплауга багышлый. Аның «Из Сибири» («Aus Sibirien») һәм «Образцы народной литературы тюркских племен» дигән фундаменталь хезмәтләре бүген дә төрки халыклар фольклорын өйрәнү өчен ышанычлы нигез булып торалар.

«Образцы народной литературы тюркских племен…» басмасының дүрт томы В.В. Радловның фәнни эшчәнлегендәге Алтай чоры ахырында басылып чыга. Бу хезмәттә төрки фольклорның төзелешен һәм жанрлар үзенчәлеген яңабаштан торгызырга мөмкинлек бирә торган материаллар урын алган.

«Образцы…» басмасының IV томында әйтеп үтелгән татар төркемнәренең яшәгән урынында турыдан-туры язып алынган 121 халык авыз иҗаты үрнәкләре бирелә. Бүгенге классификация буенча анда 41 әкият, 29 җыр һәм бәетләр (алар 680 шигъри юлны тәшкил итә), 23 риваять һәм шәҗәрә, төрки фольклорның ул чордагы уникаль жанры булып исәпләнгән 16 дастан һәм аларның инде юкка чыгып бара торган үрнәкләренең кайбер өзекләре китерелә. Аларда Себер татарлары арасында таралган дастаннар һәм аларга якын торган лиро-эпос-бәетләр билгеләп үтелә [Әхмәтова-Урманче, с. 17]. В.В. Радлов шулай ук күп кенә төрки халыкларның бишеге булган Бараба далаларында яшәүче чичәннәр авызыннан төрки теллеләрнең күбесе

өчен уртак саналган «Идегәй» дастанын язып ала. Әлеге дастан XIV гасыр ахыры – XV гасыр башында Алтын Урдадагы тарихи шәхесләр: Идегәй, Аксак Тимер, Туктамыш һ.б. турында билгеле дәрәҗәдә күзаллау мөмкинлеге тудыра. Күп кенә төрки халыклар аңа «Ак күбек», «Межек Алып», «Йертөшлек» кебек борынгы төрки эпосларның уникаль үрнәкләрен бастырып чыгарганы өчен чиксез рәхмәтләрен белдерәләр. Шулай ук «Кузы Көрпәч һәм Баян Сылу», «Камбәр», «Таһир-Зөһрә», «Бүз егет» әсәрләрен дә гомумтөрки җәүһәрләр дип атарга була. Себер татарларының халык авыз иҗаты үрнәкләреннән саналган бу әсәрләр башка төрки халыкларда (аерым алганда, алтайлыларда, якутларда, нугайларда, хакасларда) да бар. Шунлыктан без аларны гомумтөрки мирас итеп санарга тиешбез.

Себер татарлары халык авыз иҗаты әсәрләре арасында җырлар аерым урын алып тора. 29 җырдан 10 сы («Атулы батыр», «Кучум», «Сәет», «Ак бога», «Әбел Касым» һ.б.) – тарихи, 8 е – мәхәббәт, шулай ук көнкүреш җырлары (соңгыларының 5 сен Радлов бәетләр дип атый). Лирик җырларда аерым кызларга, яшь хатыннарга, башка ырудан яки халыктан (мәсәлән, иштәктән) булган хатын-кызларга мәхәббәт бәян ителә. В.В. Радлов үз текстында да бу жанрны Себер татарларындагыча «йыр» дип атый.

1967–1974 елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фольклорчылары В.В. Радлов эзләре буйлап махсус экспедицияләр оештырдылар. Бараба далаларындагы В.В. Радлов елга һәм күл исемнәре белән атап узган күп авыллар сакланып калмаган [Әхмәтова-Урманче, б. 206]. Кызганычка каршы, халык арасында, татар фольклорчыларының йөз елдан соң В.В. Радлов маршруты буенча уздырылган экспедиция материаллары күрсәткәнчә, шәрекъчы галим тарафыннан язып алынган бер генә әсәр дә (хәтта аерым вариантлары да) сакланмаган. Табылган аерым өзекләр дә В.В. Радлов теркәгән вариантларга тәңгәл түгел. Шуңа күрә дә күренекле татар фольклорчысы Ф.В. Әхмәтова-Урманче билгеләп үткәнчә, «Образцы…» басмасының IV томында урын алган фольклор үрнәкләре Себер татарларының көнкүрешен, телен, мәдәниятен өйрәнү өчен дә кыйммәтле чыганак булып торалар [Ахметова-Урманче, с. 205].

В.В. Радловның «Образцы…» хезмәте, кайбер төгәлсезлекләр булуына да карамастан, узган йөзьеллыкта гына түгел, әле безнең көннәрдә дә төрки телләрне һәм төрки халыклар фольклорын өйрәнү өчен ышанычлы чыганак булып тора.

«Образцы…» үзләренең язуларына яңа гына ия булган төрки телләрне өйрәнүдә дә зур әһәмияткә ия, чөнки алар лингвистик тикшеренүләрне диахроник планда алып бару өчен куллану мөмкинлеген бирә.

В.В. Радлов, тел һәм фольклор өлкәсендәге тикшеренүләреннән тыш, Алтайда, Бараба һәм кыргыз далаларында, Минусинск

иңкүлегендә, Урта Азиянең төрле төбәкләрендә археологик эзләнү эшләре дә алып бара. 1863–1869 елларда аның катнашында 150 курган тикшерелә.

В.В. Радлов Алтай белән Көнбатыш Себер халыклары фольклоры һәм тарихы белән, диалектология, лексикография, чагыштырма һәм тарихи фонетика, төрки телләр грамматикасы, этнография һәм археология белән тирән кызыксынучы тюрколог булып нәкъ менә Алтай чорында формалаша.

Алтайда яшәгән елларының азагында тупланган материалларын өйрәнеп, гомумиләштерү чоры башлана. Алтайда узган елларда җыйган мирасын билгеле бер системага сала, өйрәнә һәм бастырып чыгара башлый.

1871 елда В.В. Радлов Барнаул белән бәйле язмышының киләчәген хәл итү, шулай ук алга таба фәнни экспедицияләрен дәвам итү буенча килешүләрне озынайту максаты белән Санкт-Петербургка юл тота.

Юл уңаенда Казанга туктый һәм, көтмәгәндә, күренекле шәрекъ белгече һәм чукындырылган татарлар өчен ачылган рус мәктәпләре инспекторы, Духовная академия профессоры Н.И. Ильминский белән очраша. Ул Радловка татар, башкорт һәм кыргыз мөселман мәктәпләре инспекторы вазифасын тәкъдим итә. В.В. Радлов Казанда үзенең фәнни эзләнүләрен дәвам итәчәгенә, Казан татарлары һәм Идел буендагы башка халыкларының телләре һәм көнкүреш үзенчәлекләре белән якыннанрак танышуына өмет итеп, моңа риза була.

1872 елның кышында В.В. Радлов рәсми рәвештә Казан уку-укыту округына кергән татар, башкорт һәм кыргыз мәктәпләре инспекторы итеп билгеләнә.

Моңа кадәр татарлар өчен рус мәктәпләре булмый әле. В.В. Радлов Санкт-Петербургта да, Казанда да әлеге өлкәдә хөкүмәтнең гаҗәеп битарафлыгы белән очраша. Мөселман халкы моңа үзе дә каршы чыга: алар мәктәптә балаларны православиегә өндәүләреннән куркалар. В.В. Радлов, беренче чиратта, татар-мөселман балаларын укыту эшен үз кулларына алырлык педагоглар кирәклеген аңлый. Уфа шәһәрендәге беренче шундый мәктәп Казан уку-укыту округы өчен педагоглар әзерләргә тиеш була; икенче мәктәп Симферополь шәһәрендә – Одесса уку-укыту округының кырым татарлары яшәгән төбәктә оештырыла. Бераз соңрак, 1876 елда андый мәктәп Казанда да эшли башлый [Биккенин, 2006]. Мондый дүртьеллык мәктәпләр гимназияләр дәрәҗәсендәге уку йортлары булып саналалар. Әлеге белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар гимназияләрнең чираттагы сыйныфына имтихансыз кабул ителәләр. Аны тәмамлаучылар башлангыч татар көллиятләрендә, ким дигәндә, алты ел укытырга тиеш булалар.

В.В. Радлов кадрлар әзерләү эшен укытучылар коллективы туплаудан башлый. Җирле халык ышанычын казану өчен татар укытучылары булдыру кирәк була. Бу эшкә Габдел Каюмов, Шиһаб Әхмәров, Ибраһим Тереговлар алына.

В.В. Радлов Татар укытучылар мәктәбенең беренче инспекторы итеп татар теле укытучысы Гали Мәхмүдовны билгели, үзе уку-укыту бүлеген җитәкли. Татар укытучылар мәктәбендә эшләргә В.В. Радлов Казан шәһәрендәге шул заманның барлык интеллектуаль көчләрен диярлек җәлеп итә.

Күренекле татар тарихчысы, дин эшлеклесе Ш. Мәрҗани, мәсәлән, ислам буенча дәресләр алып бара, танылган мәгърифәтче Каюм Насыйров укыту методикасына өйрәтә һәм студентларның педагогик практикасын җитәкли. Болардан тыш, мәктәптә Казан университеты галимнәре П.Ф. Ломоносов, Л.М. Любимов, П.В. Траубенберг, С.А. Волберг, Д.Н. Адо, М.Г. Лексин, В.А. Богородицкий, М.А. Васильев, А.Н. Анастасиев һәм башкалар эшли.

Мәктәп татар яшьләрен тагын шуның белән җәлеп итә: анда укучылар хәрби хезмәт буенча өстенлекләрдән файдаланалар.

В.В. Радлов «европачыл белемнәр»гә ирешү өчен укытуның Көнбатыш методикасыннан файдалана.

Мөселман мәктәпләре өчен махсус дәреслекләр, программалар булмавы уку-укыту эшендә зур кыенлык тудыра. Болар белән бәйле рәвештә, В.В. Радлов 1872 елдан 1879 елга кадәр Казанда мөселман мәктәпләре өчен заман таләпләренә җавап бирә торган өч дәреслек әзерләп бастыра.

«Белек» («Знание») – кече яшьтәге мәктәп балалары өчен төзелгән беренче дәреслек, 1872 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыга. Ул 6 бүлектән тора: үгет-нәсыйхәтләр бирүче хикәяләр, үсемлекләр, хайваннар һәм минераллар турындагы хикәяләр, мәсәлләр (гыйбрәтле хикәяләр), табигать белеме, астрономия, география, рус әдәбияты буенча мәкаләләр. Соңгы бүлектә Ольга, Олег, Ярослав, Владимир Мономах турындагы, Мәскәүгә нигез салыну, Явыз Иван, Борис Годунов, Минин һәм Пожарский, Иван Сусанин, Петр I һәм Екатерина II хакындагы хикәяләр урын ала. Бу дәреслекнең максаты мәктәп балаларын укырга, язарга һәм әдәби телдә дөрес итеп сөйләшергә өйрәтү була. Моннан тыш, дини-әхлакый тәрбия бирү дә күздә тотыла. Күп кенә уңай яклары булуга карамастан, христианлык йогынтысыннан куркып, татар мәдрәсәләрендә бу дәреслекне файдаланудан баш тарталар. Күренекле татар шагыйре Габдулла Тукай үзенең «Мәктәпләрдә милли әдәбият дәресләре» (Казан, 1910) басмасын әзерләгәндә В.В. Радловның милли мәктәпләр өчен дәреслек төзүдәге уңай тәҗрибәсен киң файдалана. Шагыйрь, нәкъ менә В.В. Радлов үрнәгенә ияреп, үзенең дәреслегенә татар халкының күренекле шәхесләре, Казан ханлыгы тарихы, Явыз Иван, соңгы патшабикә Сөембикә һ.б. турындагы язмаларны кертә.

В.В. Радловның икенче китабы – «Хисаблык» – арифметика курсын тәшкил итә, өченчесе – «Грамматика русского языка, составленная для татар Восточной России» дип атала һәм ул 1873 елда Казан университеты

типографиясендә нәшер ителә. Әлеге дәреслекләрнең сыйфаты һәм үзенчәлекләре турында Н. Ильминский түбәндәгеләрне яза: «книги ... написаны на татарском языке, чисто народном, лишь с незначительной прибавкой некоторых арабских слов, сделавшихся уже общеизвестными для всех магометан благодаря широко распространенной в народе магометанской грамотности, и притом с правильною орфографией, а не по местному народному произношению; алфавит открыл этим книгам доступ во все магометанские селения не только ближайших к Казани губерний, но и отдаленных местностей Сибири; им предстоит обширный круг читателей» [Хусаинов, с. 29].

В.В. Радлов, дәреслекләр эшләү белән беррәттән, мөселманнар игътибарын җәлеп итү өчен, укытучылар мәктәбенә дини характер бирергә омтыла. Анда укырга керүчеләр ислам дине буенча имтихан тотарга тиеш булалар. Бу хакта Халык мәгарифе министрлыгы болай дип белдерә: «вступительные экзамены по богословию временная мера и что правительство никакого значения не придает мусульманскому знанию».

Казан Татар укытучылары мәктәбе үзенең 1876 дан башлап 1917 елга кадәр 41 еллык эш дәверендә 600 дән артык рус теле укытучысы әзерли. Аны тәмамлаучылар Казан губернасының һәм, соңрак, Татарстан автономияле республикасының халык хуҗалыгы тармакларында уңышлы хезмәт итәләр. Алар арасында танылган профессорлар Мозаффар Мөштәри, Гыйлем Камай, Фатих Мөхәммәдъяров, күренекле тел белгечләре Мөхетдин Корбангалиев, Мөхәммәтхан Фазлуллин, Гыйбадулла Алпаров, татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакый, беренче татар пролетар язучысы Гафур Коләхмәтов, журналист Хөсәен Ямашев, татар пролетар «Урал» газетасын оештыручы Галимҗан Сәйфетдинов, композитор Мансур Мозаффаров, дипломат Кәрим Хәкимов һ.б.ны күрсәтергә мөмкин.

В.В. Радлов, мәктәпләргә кадрлар әзерләүдән тыш, татар халкы тарихында беренче булып, хатын-кызлар өчен уку йорты ачарга омтылып карый, әмма зур кыенлыклар белән очраша: укытучы да, мәктәп бинасы табу да мөмкин булмый. Фәкать 4 елдан соң гына Радлов үз өендә мәктәп ачарга ризалашкан укытучыга тап була. Анда ярлы гаиләдән 7 укучы йөри. Әмма министрлык алар өчен генә чыгымнар тотуны кирәк тапмый һәм, шулай итеп, татарлар арасында хатын-кызларга дөньяви белем бирү тәҗрибәсе уңышсызлыкка дучар була. Шулай да В.В. Радлов эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар мәгарифе үсешендә мөһим адым ясала: хатын-кызларга белем бирү буенча беренче адымнар ясала.

«Образцы...» басмасының IV томы Радлов Казанга күчкәч (1872 елда) дөнья күрә, әмма, бу хезмәтнең калган томнары, ул Барнаулда чакта ук эшләнеп бетсә дә, 1882 елга кадәр (әйтеп үтелгән дәреслекләрне искә алмаганда) татарлар өчен башка бер генә басма да дөнья күрми.

В.В. Радлов ике ел дәвамында фәлсәфә фәненең яңа юнәлеше булган позитивизм белән шөгыльләнә. Казанда яшәгән елларында Идел буе төрки халыкларының телләрен өйрәнә, Казан университеты каршындагы Табигать сөючеләр, антропология һәм этнография җәмгыятьләре эшчәнлегендә катнаша.

Казанда В.В. Радлов гомуми лингвистика белән мавыга. Алтайда туплаган материаллары галимне төрки телләр үсеше закончалыкларын эзләү юлына этәрә. Нәкъ менә шул елларда Казан университетында И.А. Бодуэн де Куртенэ дәресләр бирә һәм тел белгечләренең теоретик түгәрәген җитәкли. Казан лингвистика мәктәбенә нигез салган әлеге түгәрәк эшчәнлегендә В.В. Радлов иң актив катнашучыларның берсе була, бу аның киләчәктәге фәнни эшчәнлендә зур роль уйный. 1883 елда И.А. Бодуэн де Куртенэ Дерпт университетына (Тарту) күчкәннән соң, Казан лингвистика түгәрәген Н.В. Крушевский, В.А. Богородицкийлар белән бергә В.В. Радлов та җитәкли. И.А. Бодуэн де Куртенэ һәм Казан лингвистика мәктәбенең В.В. Радловка йогынтысы бик зур була. Мәгълүм булганча, И.А. Бодуэн де Куртенэ һәм аның яшь грамматистлар даирәсе җанлы сөйләмне өйрәнүгә зур әһәмият бирәләр. И.А. Бодуэн де Куртенэ бу хакта болай дип яза: «Только лингвист, изучивши всесторонне живой язык, может позволять себе делать предположение об особенностях языков умерших. Изучение языков живых должно предшествовать исследованию языков исчезнувших» [Бодуэн де Куртенэ]. Әлбәттә, бу идеяләр В.В. Радловны да җәлеп итәләр.

В.В. Радловның элек җыйган материалларына нигезләп ясалган беренче гомумиләштерүләре нәкъ менә аның Казан чорына туры килә. Ул туплаган гаять бай фактик материал аңа төрки телләрнең фонетик һәм грамматик төзелеше буенча күзәтүләреннән синтетик гомумиләштерүләргә күчәргә мөмкинлек бирә. Лингвистик түгәрәкләр эшендә катнашу, шул түгәрәк әгъзаларының хезмәтләре һәм теоретик карашлары белән танышу, гомуми тел белеме мәсьәләләре белән мавыгуы, үзе туплаган бай лингвистик материалларга нигезләнү аңа гомуми нәтиҗәләргә килүне тизләтергә этәргеч бирә. Казан лингвистлары тәэсирендә В.В. Радлов «Фонетика северных тюркских наречий» дигән хезмәтен яза, аның I өлеше немец телендә Лейпцигта басылып чыга, ә бер елдан II өлеше дә дөнья күрә. В.В. Радлов үзенең бу эшен танылган филолог О. Бётлингк хезмәтләренең дәвамы дип карый. В.В. Радловның күп кенә замандашлары бу хезмәтне шул чорның иң әһәмиятле ачышларының берсе итеп бәялиләр. Бу китап хакында авторның замандашы Л. Штернберг болай дип яза: «Труд этот первый и единственный пока в науке опыт статистики и динамики тюркской фонетики... вызвал самые сочувственные отзывы таких авторитетов, как Мейшер, Габленц, Техмер, Бодуэн де Куртенэ...» [Штернберг, 1910, с. 19].

В.В. Радлов «О языке куманов…» хезмәтен дә Казанда яшәгәндә яза. Анда «Коман мәҗмугасы» («Codex Cumanicus») язма истәлеге буенча кыпчак теле фонетикасының төп мәсьәләләре күтәрелә. Бу хезмәт галимнең төрки халыкларның борынгы язма истәлекләрен тикшереп өйрәнүдә беренче адымы була. Алга таба әлеге истәлекләрнең телен өйрәнү аның фәнни эшчәнлегендә төп мәсьәләләрнең берсе булып тора.

В.В. Радловның Казан чоры хезмәтләренең соңгысы булып «Из Сибири» («Aus Subirien») санала. Анда галим Көньяк Себер, Көнчыгыш Казакъстан, Алтай һ.б. төбәкләргә сәяхәте вакытында археология, тарих һәм этнография буенча туплаган материалларына кыскача йомгак ясый. «Из Сибири» һәм башка хезмәтләрендә В.В. Радлов Көньяк Себердәге төрки телле халыкларның этногенетик процессларына шактый зур урын бирә. Аерым алганда, бу хезмәттә Көнбатыш Себер татарлары турындагы материаллар бөтен тулылыгы белән китерелә, әмма, кызганычка каршы, биредә Россиянең Европа өлешендәге һәм Кырымдагы татар төркемнәре бүлеге төшереп калдырылган. Казан татарлары, башкортлар, аларның саны һәм урнашулары хакындагы белешмәләр шулай ук хезмәттә урын алмаган [Вайнштейн..., 1972, с. 22–23]. Радловның ике томлы бу хезмәте («Aus Sibirien») 1884 елда немец телендә Германиядә дөнья күрә.

1884 елның ахырында Н.И. Ильминский (1870 елдан Император Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы) Император Фәннәр академиясенә академик булып сайлану өчен чакыру ала, әмма шәхси сәбәпләре аркасында бу мөмкинлектән баш тарта һәм үзе урынына В.В. Радловны тәкъдим итә. Кайберәүләр Ильминскийның бу адымының бер сәбәбе итеп Казанда Радловның йогынтысы көчәюеннән курку дип саныйлар. Академия Ильминскийның бу тәкъдиме белән килешә [Решетов, с. 95–101], һәм 1884 елның 7 ноябрендә В.В. Радлов Император Фәннәр академиясенең Тарих һәм Азия халыклары бүлегенә академик булып сайлана.

Петербургта да Радлов төрки халыклар телләрен һәм мәдәниятләрен өйрәнү буенча эшләвен дәвам итә, тюркологиянең төрле өлкәләре буенча 50 ләп хезмәт бастырып чыгара, фәнни экспедицияләр белән җитәкчелек итүен дәвам итә. 1886 елда ул кырым татарлары телен өйрәнү максаты белән Кырымда була. 1887 елда Литва белән Волыньда булып, караимнар телен өйрәнә. Шул ук вакытта Радлов Алтайда җыйган бай лингвистик һәм фольклор материалларын системага салу эшен дәвам итә, монда ул төрки телләрнең чагыштырма фонетикасына һәм грамматикасына, лексикологиягә, диалектологиягә, шулай ук төрки язма истәлекләрен өйрәнү һәм бастырып чыгаруга аерым игътибар бирә.

В.В. Радловның «К истории тюркской системы гласных», «Якутский язык в его отношении к другим тюркским языкам» дигән хезмәтләре дә аның Петербург чорына карый.

В.В. Радлов Петербургта вакытының бик күп өлешен төрки телләр сүзлеге төзү эшенә багышлый. «Опыт словаря...» хезмәтендә ул хакта үзе болай дип яза: «Приступив в 1859 году к исследованию тюркских наречий собственного Алтая, я с самого начала стал собирать не только произведения народного творчества, но и по возможности объемистый лексический материал, который позднее был дополнен материалами, извлеченными из различных тюркских словарей. Так возник знаменитый «Опыт словаря тюркских наречий» (СПб., 1893–1911).

Ул «Опыт словаря...» хезмәтенә дә, төрки телләрне тарихи-чагыштырма тикшеренүләрнең бер өлеше итеп карый. Автор аны сүзлекнең текстларын һәм чагыштырма грамматиканы эченә алган өч кисәк итеп эшләргә омтыла. Шуларның өченче кисәге – тарихи-чагыштырма грамматика өлеше тәмамланмый кала. Шулай да анда В.В. Радловның морфология, фонетика өлкәсендәге карашлары мөмкин кадәр киң чагылыш таба.

Ул бу телләр буенча тупланган материалларны, кайда гына яшәвенә карамастан, даими тулыландыра бара. Соңрак бу материал кыргыз, казакъ, хакас һәм уйгур телләре лексикасы белән баетыла. Анда ул кырыктан артык төрки тел, аларның шивәләреннән, борынгы язма истәлекләрдән файдалана.

Радлов әлеге сүзлекне бастыруга әзерләнә башлый. Аның кульъязма хәлендәге баштагы өлешенә академик А. Шифнер берникадәр төзәтмәләр кертә. Аннан аңа Н. Ильминский, Алтай миссионерлары тарафыннан җыелган һәм И. Гиганов сүзлегеннән алынган яңа сүзләр өстәлә. Нәтиҗәдә сүзлеккә Идел буе төрки халыклары телләре, А. Троянскийның «Словарь российско-татарский», «Алтайская грамматика», Г. Вамбериның «Джагатайские этюды», Л. Будаговның «Сравнительный словарь», Ценкерның «Турецко-арабско-персидский словарь» хезмәтләреннән алынган төрки сүзләр кертелә. «Опыт словаря тюркских наречий», өч мәртәбә редакцияләнгәннән соң, 1888 елда гына дөнья күрә, ә аның соңгы – дүртенче томы 1911 елда басылып чыга.

В.В. Радловның бу хезмәтенә аның замандашлары Н. Катанов, А. Самойлович һәм башкалар югары бәя бирәләр. Хәзерге милли сүзлекләрнең күбесе күренекле тюркологның әлеге сүзлегенә нигезләнеп төзелә. Сүзлек төрки лексиканың үсеш үзенчәлекләрен өйрәнү өчен кыйммәтле материал булып тора. Нәкъ менә шуның өчен дә ул 1963 елда СССРда кабат нәшер ителә.

1889 елда Рус географик җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы Н. Ядринцев Орхон елгасы үзәнендә серле язмалар төшерелгән зур кабер ташлары таба.

1890 елда финнәр, рус галиме эзләре буйлап, Монголиягә археологик экспедиция оештыра. Ә 1891 елда бу тиңдәшсез истәлекләргә Россия Фәннәр академиясе В.В. Радлов җитәкчелегендәге рус галимнәре барып

җитә. Рус һәм фин экспедицияләре алып кайткан материаллар дөнья галимнәренә әлеге серле ташъязмаларны уку өчен шартлар тудыра. Шушы ук елдан башлап, В.В. Радлов редакцияләвендә «Атлас древностей Монголии» чыгарыла башлый.Анда күп сандагы орхон һәм енисей язмаларының тасвирламалары һәм күчермәләре бирелә. Озак та үтми рун алфавиты тамгаларының тасвирламалары һәм аңлатмалары, Күлтәгингә куелган һәйкәл-таштагы язманың транскрипциясе һәм тәрҗемәсе бирелгән «Древнетюркские надписи Монголии» дигән хезмәтнең бер-бер артлы өч чыгарылышы дөнья күрә. Басмаларның комментарийләрендә В.В. Радлов аерым сүзләр һәм фразаларны уку һәм тәрҗемә итүнең мөмкин булган вариантларын да тәкъдим итә.

В.В. Радлов енисей һәм орхон алфавитлары арасында шактый аермалар булуына басым ясый һәм, шуннан чыгып, Хануй елгасы белән Тану-Ола тау сырты арасындагы территориядә рун язмалары очрамавын истә тотып, әйтелгән алфавитларның бер-берсенә бәйсез рәвештә параллель яшәүләре хакындагы нәтиҗәгә килә [Щербак, с. 56–57]. Күлтәгиннең һәйкәл-ташындагы язманы укуга В.В. Радлов белән данияле галим В. Томсен алына. Радлов серле язмадагы 11 тамганы ачыклый, ә В. Томсен бөтен алфавитка ачкыч таба. Бу 1893 елның 26 ноябрендә була. Алфавит басылып, бер ай узгач, бөек тюрколог, сынап карау максаты белән, Күлтәгин һәйкәл-ташы язмасының тулы тәрҗемәсен эшли, 1894 елда Күлтәгиннең бертуганы Могилан кабер ташындагы язманың тәрҗемәсе басылып чыга. «Древнетюркские надписи Монголии» хезмәтенең өченче басмасын әзерләүдә галимгә П. Мелиоранский белән В. Бартольд ярдәм итә. Биш ел дәвамында В.В. Радлов әлеге хезмәтнең тагын өч чыгарылышын (Илтерес каган белән аның хатыны Илбиге-хатынга багышланган язмаларын) бастыруга ирешә.

Шулай итеп, Орхон-Енисей язма һәйкәлләре турындагы басмалар XX гасырда Даниядә, Төркиядә, Финляндиядә, Германиядә, Монголиядә, Польшада дөнья күрә. Ә безнең илдә алар 1952 елда С.Е. Малов тырышлыгы белән кабатлап бастырылып чыгарыла.

В.В. Радлов фәнни иҗатында борынгы төрки рун язулы истәлекләр лингвистик тикшерүдә мөһим өлкәне урап алып торалар. Басманың «Die alttürkischen Inschriflen Mongolei» дигән бүлеге диалект аерымлыклары проблемаларына да багышлана. В.В. Радлов борынгы төрки диалектларның үсеш һәм үзгәреш мәсьәләсенә аерым туктала. Ул аны төрки телләрнең катнаш характерда булуына сәбәп булган дип исәпли. Шуннан чыгып, борынгы төрки телләр һәм диалектларның классификациясен тәкъдим итә.

Рун язуларын тикшерenүләр нәтиҗәсендә алынган мәгълүматларны В.В. Радлов сузык авазларга багышланган мәкаләләрендә дә куллана, ә рун язмалары лексикасын 1888 елдан басылып килгән «Опыт словаря тюркских наречий» хезмәтендә дә куллана. Төрки

телләрнең фонетикасын һәм грамматикасын чагыштырма-тарихи планда өйрәнү мөмкинлеген киңәйтү максатыннан, В.В. Радлов рун һәйкәлләре тәрҗемә ителгәннән соң, аларның нәтиҗәсен – фонетика, морфология, синтаксисның кыскача тасвирламаларын «Die alttürkischen Inschriften der Mongolei/Neue Folge» (СПб., 1897) китабында урнаштыра [Кононов, 1971, с. 11].

Галимнең рун һәм уйгур язма һәйкәлләренә багышланган «Einleitende Gedanken zur Untersuchung der alttürkischen Dialekte» (1911) – «Вводные мысли к изучению древне-тюркских диалектов» хезмәте төрки халыклар тарихындагы күп кенә катлаулы проблемаларны аңлауда зур әһәмияткә ия. «Die alttürkischen Dialekte» («Древнетюркские диалекты») (1911) мәкаләсендә рун һәм уйгур язулы кайбер һәйкәлләрнең кыскача тасвирламалары ачыклана. Шуннан чыгып, борынгы төрки диалектларның (телләрнең) классификациясен булдыруга омтылыш ясала [Кононов, 1971, с. 11].

Әйтергә кирәк, тюркологиядә Радловка кадәр дә уңышлы эзләнүчеләр аз булмый, аеруча төрки телләр буенча. В.В. Радлов хезмәтләрендә исә тюркологиянең барлык өлкәләре яңа баскычка күтәрелә; төрки телләр хәзинәсе яңа фактик материаллар белән баетыла, гомумтөрки сүзлек төзүгә юл ачыла; күп кенә җанлы төрки телләрнең язма һәйкәлләренең байлыгын чагыштырма-тарихи эзләнүләрдә киң куллану өчен җирлек тудырыла [Кононов, 1971, с. 11].

В.В. Радлов уйгуристикага да нигез салучы буларак билгеле. Казанда эшләгән вакытында ук ул уйгур язма һәйкәлләреннән Йосыф Баласагуниның «Котадгу белег» әсәре белән таныша. 1889 елда В.В. Радлов «Ярлыки Тохтамыша и Тимура-Кутлуга» мәкаләсен бастыра. 1890 елда «Котадгу белег»не, 1891 елда аның икенче басмасын нәшер итә. 1900, 1910 елларда «Котадгу белег»нең Каир кулъязмасын басмага әзерли. 1899 елда Д. Клеменцның экспедиция материалларыннан ике юридик документны һәм буддага бәйле ике фрагментны нәшер итә. 1910 елда В.В. Радлов будда сутрасы «Дедмастведстик»ның уйгур версиясен, кытай версиясендәге «Лотос истинного закона» сутрасының 25 бүлеген уйгурча тәрҗемәдә басмага әзерли. 1913 елдан «Золотой блеск» («Алтун ярук») сутрасының аерым бүлекләре нәшер ителә башлый. 1904 елда В.В. Радлов 128 фрагменттан торган «Памятники уйгурского языка» хезмәтен тәмамлый, әмма аны С. Малов фәкать 1928 елда гына бастырып чыгаруга ирешә [Насилов, с. 64–101].

В.В. Радловның уйгуристика өлкәсендәге хезмәтләре, аерым җитешсезлекләре булуга карамастан, бүгенге тюркология өчен нигез хезмәтләр булып тора.

1894 елның 16 мартында В.В. Радлов Антропология һәм этнография музее директоры булып сайлана. Музейлар эшен өйрәнү максаты белән ул Көнбатышка юл тота. Стокгольм, Берлин, Копенгаген, Гамбург, Кёльн музейларында була.

Командировкадан әйләнеп кайткач, В.В. Радлов музейдагы коллекцияләрне тәртипкә китерә, музейның мәйданын киңәйтүгә керешә. Музей алдына Россия мәдәниятен генә түгел, ә дөньякүләм, гомумкешелек мәдәнияттен дә колачлау бурычы куела. В.В. Радлов җитәкләгән чорда андагы коллекция тагын да тулылана төшә, «Сборник музея антропологии и этнографии» басмасы нәшер ителә башлый. 1902 елда ул музей каршында китапханә оештыруга алына, аңа үзенең күп кенә китапларын бүләк итә. 1903 елдан В.В. Радлов Халыкара комитет каршында эшләүче Урта һәм Көнчыгыш Азияне өйрәнү буенча рус комитетын җитәкли.

В.В. Радлов Император рус географик җәмгыяте, Рус ориенталистлары җәмгыяте, Император Көнчыгыш белеме җәмгыяте эшчәнлекләрендә актив катнаша, Себерне өйрәнү җәмгыяте идарәсе белән җитәкчелек итә.

Чит илләрдәге фәнни ассоциацияләр, җәмгыятьләр, университетлар үзләрендә В.В. Радловның почетлы әгъза булуын зур горурлык итеп саныйлар. Ул илебезнең һәм чит илләрнең күп төрле бүләкләренә лаек була. 1912 елда Россиянең фәнни җәмәгатьчелеге күренекле галимгә 75 яшь тулуны зурлап билгеләп үтә.

В.В. Радлов 1918 елның 12 маенда вафат була һәм С.-Петербургтагы Смоленск зиратының лютераннар күмелә торган өлешенә җирләнә. Некрологта: В.В. Радловның үлеме Россия фәне өчен иң зур югалту булды дип язылган.

**Әдәбият**

*Ахметова-Урманче Ф.В.* По следам В.В. Радлова // Фәнни эзләнүләр юлында. Казан: Фикер, 2000.

*Әхмәтова-Урманче Ф. В.* Татар эпосы. Дастаннар. Казан: Раннур, 2004. 430 б.

*Биккенин Р.* Мухаммед-Сафа Биккенин и Василий Васильевич Радлов: из истории первого в Казанской губернии татарского начального училища // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2006. № 1.

*Бодуэн де Куртенэ И.А.* Избранные труды по общему языкознанию. Т. II. М., 1963.

*Вайнштейн С.И.* В.В. Радлов и его труд «Из Сибири» // Радлов В.В. Из Сибири. М., 1989.

*Вайнштейн С.И., Кляшторный С.Г.* В.В. Радлов и историко-этнографическое изучение тюркских народов // Тюркологический сборник 1971. М.: Наука, 1972. С. 22–23.

*Горохов В.М.* Реакционная школьная политика царизма в отношении татар в Поволжье. Казань, 1941.

*Кононов А.Н.* В.В. Радлов и отечественная тюркология // Тюркологический сборник 1971. М.: Наука, 1972. С. 7–15.

*Михайлова С.М.* Казанский университет в духовной культуре народов востока России. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1991.

*Насилов Д.М.* В.В. Радлов и изучение древнеуйгурских памятников // Тюркологический сборник 1971. М.: Наука, 1972. С. 64–101.

*Радлов В.В*. Этнографический обзор турецких племен Сибири и Монголии. Иркутск, 1929. С. 232.

*Решетов А.М.* Академик В.В. Радлов, востоковед и музеевед (основные этапы деятельности) // Радловские чтения – 2002. Материалы годичной сессии. СПб., 2002. С. 95–101.

*Сайфулина Ф. С.* История формирования и развития татарской литературы Тюменского региона. Тюмень: Вектор Бук, 2007.

*Самойлович А.Н.* Радлов как турколог // Революция и национальности. 1937. № 2. С. 79–81.

*Сельченко М.С.* В.В. Радлов и изучение тюркского фольклора // Тюркологический сборник 1971. М.: Наука, 1972. С. 16–19.

*Тенишев Э.Р.* В.В. Радлов — фонетист и грамматист // Тюркологический сборник 1971. М.: Наука, 1972. С. 32–43.

*Тугушева Л.Ю.* В.В. Радлов — лексикограф и лексиколог // Тюркологический сборник 1971. М.: Наука, 1972. С. 44–48.

*Хусаинов К.* В.В. Радлов и казахский язык. Алма-Ата, 1981.

*Штернберг Л.* Из жизни и деятельности В.В. Радлова // Живая старина. СПб., 1909. Т. XVIII. Вып. II—III. С. 15.

*Штернберг Л.* Из жизни и деятельности В.В. Радлова. СПб., 1910.

*Щербак А.М.* В.В. Радлов и изучение памятников рунической письменности // Тюркологический сборник 1971. М.: Наука, 1972. С. 54–63.

*Эфиров А.Ф.* Нерусские школы Поволжья, Приуралья и Сибири. М., 1948.

***Йосыпов Фәрит Йосыф улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор*

УДК 811.512.145:372.8

*Н.В. Максимов*

# ТАТАР ТЕЛЕН ЧИТ ТЕЛ БУЛАРАК УКЫТУ МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА

В статье рассматривается технология обучения татарскому языку как неродному. Обосновывается целесообразность обучения на синтаксической основе. Выделение синтагматической модели речи в качестве основы обучения неродной речи позволяет акцентировать внимание обучаемого на алгоритме построения словосочетаний и предложений. Опора на алгоритмы помогает обучаемому варьировать стабильными синтаксическими конструкциями в процессе создания текста-основы и выстраивания диалога.

**Ключевые слова:** татарский язык, синтаксическая основа обучения, модели речи, алгоритм построения словосочетаний и предложений.

Утыз елга якын Татарстан мәктәпләрендә алып барылган эш тәҗрибәсе шуны күрсәтте: ана телен белмәгән – татар, татар телен чит тел буларак өйрәнүче рус баласын татарча сөйләргә һәм сөйләшергә өйрәтә алмадык. Өйрәтә алмавыбызның сәбәпләре берничә. Беренчесе – рус телле укучылар өчен әзерләнгән «Татар теле» дәреслекләренең, нигездә, тел фәненә караган кагыйдәләр җыентыгын сыйныфлап өйрәтүгә нигезләнеп төзелүе; икенчесе – шул контингентка караган укучылар белән эшләүче татар теле укытучыларының эшенә максатчан ярдәм итәрлек фәнни-методик әдәбиятның хәзергә кадәр булмавы; өченчесе – бу юнәлештә алып барылган эшнең баштан ук – үткән гасырның 90 нчы елларыннан ук максаты ачык билгеләнмәү, эчтәлек һәм форма ягы туры килмәү. Ягъни укыту программасында укытучыдан укучыларын татарча сөйләшергә өйрәтү таләп ителә – укучының белеме исә тел белеменең фонетика, орфоэпия, орфография, сүз ясалышы, лексика, морфология һәм синтаксис өлешләренә, пунктуациягә караган кагыйдәләрне белү дәрәҗәсен тикшерү юлы белән бәяләнә; сөйли һәм сөйләшә белү дәрәҗәсе бөтенләй бәяләнми диярлек.

Баланы чит телдә (шул исәптән, ана телендә дә) сөйләшергә, аралашырга өйрәтү процессы сөйләм калыпларына нигезләнеп оештырылганда гына көтелгән нәтиҗәләләргә ирешеп була.

Телгә өйрәткәндә, көтелгән нәтиҗә ул – өйрәнүченең (баламы, укучымы, студентмы, олы кешеме – барыбер) өйрәнгән телендә ситуатив теманың эчтәлеген үз сүзләре белән сөйләү (*монолог – хикәя* оештыру) сәләте; башкалар белән урамда, кибеттә, мәктәптә, институтта, эштә һ.б. урыннарда кем белән дә булса, иркен аралашу – сорау бирү, сорау бирсәләр – җавап бирү (*диалогта* актив катнашу) мөмкинлеге.

Сөйләм калыпларына туплланган темаларның барысын берләштереп, «Үзебез турында сөйләшү» дип атап булыр иде.

Үзебез турында, ягъни үзем, якыннарым, туганнарым, танышларым, дусларым, күршеләрем турында, аларга мөнәсәбәттә сөйләү һәм сөйләшү.

Сөйләм калыбы һәр халыкта, гадәттә, гасырлар дәвамында бабадан һәм әбидән – атага һәм анага, алардан – балаларына, буыннар аша табигый рәвештә бирелгән сөйләм кагыйдәләренә таянып, билгеле бер тема (темалар) кысасында көндәлек тормышта, мәсәлән, кая да булса баруга яки кайтуга; кайсы да булса эшне кайда, кем белән, ничек, ни өчен башкаруга мөнәсәбәттә сөйләү һәм кара-каршы сөйләшү өчен, диалог формасына яраклаштырып төзелә. Шул сәбәпле сөйләмдә кулланылган сүзләрнең саны күп була алмый, ягъни тема кысаларында, нигездә, бер үк сүзләр, эчтәлеге һәм формасы ягыннан сорау сүзләргә яраклаштырылып, төрле грамматик формаларда кулланыла. Сөйләм калыбында бер үк сүзләрне төрле формаларда кабатлап, охшаш мәгънәле сүзтезмәләрне, җөмләләрне әйтеп һәм язып кабатлый-кабатлый, бала үзенә үзе сорау биреп – чит телдә уйларга, үзендә туган яки бирелгән проблемалы сорауга карата яшьтәшләренең – икенче һәм (икенче зат ярдәмендә) өченче затның фикерен ишетеп яки язганны укып аңларга өйрәнә, ягъни *монолог – хикәя* төзү һәм уртак сөйләмдә – *диалогта* актив катнашу күнекмәләре ала.

Сөйләүче (I зат – *мин*) үз сөйләмендә бер яки ике, яки икедән артык хәбәр җиткерергә мөмкин. Фикере җыйнак һәм мәгънә ягыннан тулы булсын дисә, ул, минималь күләмдәге таныш сорау сүзләрне, таныш яки өйрәнелгән яңа сүзләрне кулланып, сөйләмендә бер (яки берничә) гади җөмлә формасыннан – кушма яки катлаулы, катлаулы җөмлә формасыннан кушма яки гади җөмлә формасына җиңел күчә белергә тиеш.

Сөйләм калыпларына нигезләнеп, телгә өйрәтү технологиясе – икенче бер телдә сөйләшергә өйрәтү практикасында яңа күренеш. Традицион дәрес кысаларында, эшне оештыру барышында, укытучы алдына өч төрле – фәнни, гамәли, тәрбияви максат куела. Сөйләм калыпларын кулланып дәрес уздырганда, укытучы, нигездә, ике төрле максатны гына куллана: кагыйдәләр өйрәтми генә, укучыга сөйләү һәм сөйләшүне оетыру серләрен аңлата; сөйләмдә катнашучыларны сүз мәгънәсе һәм җанлы сөйләм аша тәрбияли.

**Игътибар**! Түбәндә 1 нче сыйныфта укучы рус телле балалар белән эшләүче укытучылар өчен «Сөйләм калыпларына нигезләнеп, татар теленә өйрәтү технологиясе»н кулланып төзелгән бер үрнәк дәрес эшкәртмәсе бирелә.

**Тема.** ***Кем нишли?***

***Көтелгән нәтиҗәләр***

*Предмет буенча УУГ: кем? кайда? кем белән? нишли? нишләми?* сорауларына җавап биргән грамматик формаларны аңлату, сөйләмне яңа лексик һәм грамматик формалар белән баету.

*Танып-белү УУГ*: тыңлап аңлау, аңлап сөйләү һәм сөйләшү, текстны аңлау һәм эчтәлеген аңлата белү.

*Коммуникатив УУГ:* кирәкле лексик һәм грамматик материалга нигезләнеп, тема буенча монологик һәм диалогик сөйләмне үстерү.

*Регулятив УУГ:* дәреснең темасын һәм максатын аныклау, укытучының һәм укучыларның уртак эшчәнлеген оештыру.

*Шәхси УУГ:* үзеңне өйдә, урамда, мәктәптә, дәрестә, тәнәфестә дөрес тоту кагыйдәләрен белү һәм үтәү, бер-береңә дусларча мөнәсәбәттә булу.

**Дәреснең төре.** Яңа лексик һәм грамматик материалны бирү дәресе.

**Эшне оештыру.** Укытучы сүзе, әңгәмә, фронталь тикшерү, үзең генә һәм парлап эшләү.

***Дәреснең планы.***

**I. Оештыру.**

1. Исәнләшү.

2. Укучыларны дәрескә әзерләү.

**II. Актуальләштерү.**

1. Узган дәрестә үтелгәннәрне искә төшерү.

**III. Яңа материалны аңлату.**

1. **Кем? кайда? кем белән? нишли?** сорауларына җавап биргән грамматик формаларны аңлату.

**IV. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.** *(**Белем** ул – укучы исендә калдырырга, хәтерендә тотарга, алдагы дәресләрдә яңа материалны үзләштерү өчен нигез итеп файдаланырга тиешле мәгълүматлар тупланмасы; **күнекмә** ул – белем һәм тәҗрибәгә нигезләнеп, мөстәкыйль рәвештә сөйли һәм сөйләшә башлау.)*

1. Телдән сөйләмне яңа лексик һәм грамматик формалар белән баету.

2. Укучыларның *кемнең* (I, II, III затларның) *кая, кем белән баруы* турында сөйләве һәм сөйләшүе.

**V. Өй эше бирү.**

1. Өйдәгеләргә, ягъни әтиең белән әниеңә, әбиең белән бабаңа, апаң белән абыеңа, сеңлең белән энеңә үзең укыган класста *кемнең кая, кем белән баруы һәм кайтуы* турында сөйләргә әзерләнергә.

**VI . Йомгаклау.**

***Дәреснең барышы.***

**I. Укытучы.** Укучылар, хәлегез ничек?!

**Укучылар.** Рәхмәт! Яхшы! Сезнең хәлегез ничек?!

**Укытучы.** Минем дә хәлем бик яхшы, укучылар. Рәхмәт! Утырыгыз.

**II. Укытучы.** Укучылар, әйдәгез әле, үткән дәресләрдә өйрәнгән сүзләрне, сүзтезмәләрне, сорау һәм җавап җөмләләрне искә төшерик.

**1 нче этап**

| Кайсы? | Нәрсә? | Нинди? | |
|---|---|---|---|
| Бу<br>Бусы<br><br>Монысы<br><br>Теге<br>Тегесе | алма<br>груша<br>чия<br><br>карандаш<br>ручка<br><br><br><br><br><br><br>дәфтәр | кызыл<br>сары<br>зур<br>зуррак<br>кечкенә<br>кечкенәрәк<br>яшел<br>тәмле<br>тәмлерәк<br><br>шакмаклы<br>юллы<br>калын<br>юка | -мы?<br>-мыни?!<br><br><br>-ме<br>мени?!<br><br><br>түгел |

1 нче этапта һәр укучы, таблицага карап, ике сүздән торган җыйнак җөмләләр, өч сүздән торган җәенке җөмләләр, теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдән текст – үз монологын төзи. Без аны **башлангыч текст** дип атыйк. Мисал өчен:

***Бу алма. Алма кызыл. Бу алма кызыл. Бу алма кызыл, ә бу алма сары.***

2 нче этапта укучылар, парларга бүленеп, башлангыч текстны сорау = җавап + сорау формуласына туры китереп, диалог төзи. Диалог төзегәндә, сорау бирүченең дә, җавап бирүченең дә сөйләмендә *кереш* һәм *эндәш* сүзләр, сорау һәм билгесезлекне белдерүче кушымчалар кулланылырга тиеш.

**2 нче этап**

| **Кайсы?** | **Нәрсә?** | **Нинди?** | |
|---|---|---|---|
| Бу | алма | кызыл | -мы? |
| Монысы | груша | сары | -мыни?! |
| Тегесе | чия | зур | -дыр |
| | | зуррак | -тыр |
| миндәге | каран- | кечкенә | -ме |
| синдәге | даш | кечкенә- | мени?! |
| | ручка | рәк | -дер |
| Миша, | | яшел | -тер |
| әйт әле | | тәмле | |
| | | тәмлерәк | |
| Маша, | дәфтәр | шакмак- | |
| син | | лы | |
| беләсең- | | юллы | |
| ме? | | калын | |
| | | юка | |

Мисал өчен, Марат белән Гүзәлнең диалогы, башлангыч текстка нигезләнеп, түбәндәгечә оеша:

*– Гүзәл, әйт әле, бу нәрсә?*

*– Марат, бу алма. Марат, ә бу алма, синеңчә, нинди?*

*– Бу алмамы, Гүзәл? Бу алма, минемчә, кызыл. Гүзәл, синеңчә, бу алма тәмлеме?*

*– Марат, минемчә, бу алма бик тәмледер.*

**III.** Укучылар без, өч дәрестә – бүгенге һәм алдагы ике дәрестә сезнең белән 3 этаптан торган яңа сөйләм калыбын төзербез. Шуны исегездә калдырыгыз: һәр сөйләм калыбы өч этаптан тора. Беренче этапта сез – **мин** монологын сөйләргә, 2 нче этапта – сөйләшүче затлар – **мин** һәм **син** арасында булган диалогны; 3 нче этапта I һәм II затларның III зат (затлар яки предметлар) турында диалогын оештырырга өйрәнерсез. Шулай итеп, без сезнең белән, әкренләп, татарча сөйләргә һәм сөйләшергә өйрәнербез.

Әйдәгез, башта бүгенге дәрескә караган теманың сөйләм калыбын төзеп карыйк. Моның өчен мин сезгә дүрт сорау сүз язылган таблица күрсәтәм. Аннары без, бергәләшеп, вертикаль баганаларда язылган һәр *сорау сүзгә* берничә *җавап сүз* табып язарбыз.

Беренче баганага без сөйләмдә катнашучы затларны язабыз. Алар һәрвакыт **кем**? соравына җавап бирә: I зат – **мин**, II зат – **син**, III зат – **ул** (Марат яки Гүзәл) булсын.

*Нишлим? нишләмим? нишлисең? нишләмисең? нишли? нишләми?* кебек сорау сүзләргә җавап сүзләр буларак, без бу очракта барлык һәм юклык формасындагы *юнәлешле хәрәкәтне белдерүче* антоним мәгънәле парлар булган сүзләрне алабыз.

**1 нче этап**

| **Кем?**<br>*кто?* | **Кайдан?**<br>*откуда?* | **Кая?**<br>*куда?* | **Кем белән?**<br>*с кем?* | **Нишли?**<br>*что (не) делает?* |
|---|---|---|---|---|
| **1**<br>**Мин** | өйдән<br>мәктәптән<br>парктан<br>бакчадан | мәктәпкә<br>өйгә<br>паркка<br>бакчага | әнием<br>әтием<br>бабай<br>әбием<br>апам<br>абыем<br>энем<br>сеңелем<br>дустым<br>**белән** | барам<br>бармыйм<br><br>кайтам<br>кайтмыйм |

**2 нче этап**

| **Кем?** | **Кайдан?** | **Кая?** | **Кем белән?** | **Нишли?** |
|---|---|---|---|---|
| **2**<br>**Син** | өйдән<br>мәктәптән<br>парктан<br>бакчадан | мәктәпкә<br>өйгә<br>паркка<br>бакчага | әниең<br>әтиең<br>бабаң<br>әбиең<br>апаң<br>абыең<br>энең<br>сеңелең<br>дустың<br><br>**белән** | барасың?<br>барасыңмы?<br><br>бармыйсыңмы?<br><br>кайтасың?<br>кайтасыңмы?<br><br>кайтмыйсыңмы?<br><br>бар, барма<br><br>кайт, кайтма |

**3 нче этап**

| **Кем?** | **Кая?** | **Кайдан?** | **Кем белән?** | **Нишли?** |
|---|---|---|---|---|
| **3**<br>**Ул**<br><br>Марат<br>Гүзәл<br><br>**Кемдер** | өйдән<br>мәктәптән<br><br>парктан<br>бакчадан | мәктәпкә<br>өйгә<br><br>паркка<br>бакчага | әнисе<br>әтисе<br>бабасы<br>әбисе<br>апасы<br>абыйсы<br>энесе<br>сеңлесе<br>дусты<br><br>**белән** | бара?<br>барамы?<br>бармыймы?<br><br>кайта?<br>кайтамы?<br>кайтмыймы?<br><br>барсын<br>бармасын<br><br>кайтсын<br>кайтмасын |

**IV.** 1. **1 нче этапта** укучылар, сөйләм калыбында бирелгән лексик һәм грамматик материалга нигезләнеп, I зат – **мин** исеменнән үзе төзегән монолог – хикәясен (*башлангыч текстны*) сөйли. Сөйләмендә *һәм, тагын, ләкин, яки, я* кебек теркәгечләрне; *белән, кадәр, соң* кебек бәйлекләрне; *әлбәттә, дөрес, чынлап та, билгеле* кебек модаль сүзләрне куллана.

2. **2 нче этапта** I һәм II зат арасында, башлангыч текстка нигезләнеп, кара-каршы сөйләшү – диалог оештырыла.

Бу очракта сорау бирүче – I, җавап бирүче II зат вазифасын башкара. Сөйләшү барышында, таблицадагы сорау сүзләрдән, сорау кушымчаларыннан файдаланып, кереш сүзләрне – *гафу ит, рәхмәт, әйт әле, мәсәлән, минемчә, синеңчә, мин шулай уйлыйм, син ничек уйлыйсың* һ. б. ш. сүзләрне һәм җөмләләрне кулланып, сөйләмдә катнашучы затлар сорау һәм җавап җөмләләр төзи.

Мондый сөйләшү барышында, укучының белем дәрәҗәсе генә түгел, шәхес буларак мөмкинлекләре дә – ***кемнең кем булуы*** (кто есть кто!) да ачыклана, ягъни кемдә лидерлык сыйфатлары көчлерәк икәнен дә күзәтеп була.

3. **3 нче этапта** I һәм II зат арасында, башлангыч текстка нигезләнеп, III зат турында кара-каршы сөйләшү – *диалог* оештырыла.

**V. Укучыларга, ни өчен шундый билге куелганын аңлатып, билгеләр куела.** Өйдә эшләр өчен эш бирелә.

**Өй эше.** Кереш һәм эндәш сүзләр белән тулыландырып, *үзеңнең кая, кем белән баруың һәм кайтуың турында* монолог – хикәя төзеп сөйләргә әзерләнергә.

**Укытучылар игътибарына бер сүз.**

Беренче сыйныфта укучы рус баласын дәрестә яздырырга; өй эше итеп, язып эшләү өчен күнегү бирергә кирәк түгел. Укытучының төп максаты – башта баланы сөйли һәм сөйләшергә өйрәтү. Язарга өйрәтүне, әкренләп, икенче һәм өченче сыйныфтан башларга мөмкин. Сөйләшә белгән баланы язарга өйрәтү укытучы өчен авыр эш булмый: дөрес сөйләшә белгән бала дөрес язарга тиз ияләшә ул.

Үзенә генә чит телдә яза башлау бу яшьтәге бала өчен әле бик катлаулы эш. Язу барышында ул үзе өйрәнә башлаган чит телдә шул телгә генә хас булган лексика, орфография, морфология һәм синтаксис өлкәсенә караган кагыйдәләргә нигезләнергә тиеш була. Бала бу чорда әле боларны фәнни нигездә үзләштерергә, практикада кулланырга әзер түгел.

Икенче сыйныфтан башлап, укучыларны, сорау сүзләргә нигезләнеп, сүз төркемнәрен билгеләргә һәм, кайсы сүз төркеменә караган сүзләрнең җөмләдә кайсы кисәк булып килүен табырга мөмкин.

***Максимов Николай Валентинович,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының татар теле һәм татар телен укыту методикасы кафедрасы доценты*

УДК 372.881.111.1:398.91

***А.С. Чугунов***

# ИНГЛИЗ ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ИНГЛИЗ ҺӘМ ТАТАР МӘКАЛЬЛӘРЕН КУЛЛАНУ

В статье подчеркивается значение произведений малых жанров устного народного творчества при изучении иностранного языка на примере использования татарских пословиц на уроках английского языка в средней школе.

**Ключевые слова:** малые жанры устного народного творчества, татарские пословицы, английские пословицы, урок английского языка в средней школе.

Чит тел укытканда халык иҗаты әсәрләрен, бигрәк тә мәкаль-әйтемнәрне куллануның әһәмияте берничә фактор белән бәйле. Мәкальләр, кагыйдә буларак, җиңел истә кала торган шигъри яңгырашка ия әсәрләр. Алар аерым сүзләрне, гыйбарәләрне истә калдырырга ярдәм итәләр, чит телне өйрәнү процессы кызыклырак һәм җиңелрәк кабул ителә. Чит тел дәресләрендә мәкальләр куллану шул телдә сөйләшүче халыклар турында күбрәк мәгълүматлы булырга, башка халыкларның менталитетын аңларга ярдәм итә. Чит телдәге мәкаль-әйтемнәрнең туган телдәге эквивалентларын табу укучыларда эзләнү эшенә дә кызыксыну уята. Аерым сүзләр кергән яки охшаш эчтәлекле мәкаль-әйтемнәрнең туган телдәге аналогларын эзләү процессы туган телгә дә мәхәббәт тәрбияли. Әлбәттә, теләсә кайсы телдәге мәкаль-әйтемнәрнең зур тәрбияви әһәмияткә ия булуы һәркемгә мәгълүм.

Мәкаль-әйтемнәр фольклордагы тәмамланган фикерне белдерә торган иң кечкенә күләмле жанр санала. Бу жанрның мәгънәсе һәм роле тормышта яки сөйләмдә билгеле бер ситуация белән бәйле рәвештә генә ачыла. Мәкальләр бөтен халыкларда да бар. Алар бик борынгы жанр булып санала, шуңа күрә аларның кайчан килеп чыгуларын һәм формалашуларын белү мөмкин түгел.

Мәкальләр мәгънә ягыннан ике төрле була: туры мәгънәгә ия; читләтеп әйтелгән, күчерелмә мәгънәле мәкальләр. Туры мәгънәдәге мәкальләрдә киңәш бирелә, халык үзенең тәҗрибәсен тапшыра. Тормыштагы аерым күзәтүләргә нигезләнгән мәкальләр дә туры мәгънәле мәкальләргә карый. Мәсәлән:

*Like father, like son.* (Әтисе нинди, улы шундый).

*Better late than never* (Соң булса да, уң булсын).

Читләтеп әйтелгән мәкальләрдә тормыштагы күренешкә киная белән, башка әйбер белән чагыштыру рәвешендә бәя бирелә. Мәсәлән:

*Little strokes fell great oaks* (Тамчы таш яра).

*Which way the wind blows* (Җил искән якка авышу).

Татар һәм инглиз мәкальләрен чагыштырып өйрәнгәндә

ике халыкның мәкальләрендә шактый уртаклыклар барлыгы ачыклана. Татар һәм инглиз телләрендә мәгънәләре, кулланылу үзенчәлекләре, лексик составлары ягыннан охшаш мәкальләр шактый очрый. Бу охшашлыкны мәкальләрнең бер халыктан икенчесенә күчүе белән аңлату шактый катлаулы. Чөнки инглиз һәм татар халкы янәшә яшәмәгән, шуңа күрә бу әсәрләрнең бер халыктан икенчесенә күчүен ачыклау, кагыйдә буларак, мөмкин түгел. Аз сандагы мәкальләр рус теле аша татар теленә керергә мөмкин. Күпчелек әсәрләрнең охшашлыгын халыкларның тарихындагы, дөньяга карашындагы, тормыш-көнкүрешендәге охшашлыклар аша да аңлатырга мөмкин. Төрле халыкларны бер үк рухи кыйммәтләр дә берләштерә ала. Мәкальләрдә халык тормышының бөтен ягы да чагыла. Алар аша бәя бирелмәгән өлкә юктыр. Мәкальләрдә тормыштагы һәр вакыйга, тормыш күренешләре хакында мәгълүмат саклана. Мәсәлән, ике халыкның да эшкә, белем алуга, ата-анага, әхлакый кыйммәтләргә карашлары якын. Бу якынлык, вакыйгаларга бер үк мөнәсәбәт, уртак карашлар охшаш мәкальләр барлыкка килүгә сәбәп була ала.

Кагыйдә буларак, инглиз мәкальләре дә, татар мәкальләре дә күчерелмә яки күп мәгънәле, шуңа күрә аларны еш кына аңлау һәм чагыштыру, икенче телдәге эквивалентларын табу да кыен. Шуңа күрә инглиз һәм татар мәкальләрен чагыштырганда бер мәгънәнең булса да туры килүе төп таләп итеп алына. Еш кына бер үк фикер төрле образлар аша ачыла. Тормыш-көнкүрешкә, яшәү рәвешенә бәйле рәвештә формалашкан образлар төрлелеге абсолют эквивалентларның аз булуына китерә.

Мәсәлән, инглиз телендә: «The glass is always greener on the other side of the fence» дигән мәкаль бар. Тәрҗемәсе – «Койманың теге ягында үлән яшелрәк» бу мәкальнең татарча варианты түбәндәгечә яңгырый: «Күрше тавыгы күркә булып күренә».

Инглиз һәм татар мәкальләрен чагыштыру нәтиҗәсендә түбәндәге охшашлык төрләре ачыкланды:

1. Мәгънәләре, кулланылу ягыннан һәм лексик составлары ягыннан тулысынча туры килә торган мәкальләр.

*The apple never falls far from the tree.* – Алма агачыннан ерак төшми.

2. Мәгънәләре, кулланылу ягыннан охшаш, лексик составы буенча аерылган мәкальләр.

*Birds of a feather flock together.* – Балыкчы балыкчыны ерактан таный.

*Don't count your chickens before they are hatched.* – Чебешләрне көз көне санайлар (Русчасы: цыплят осенью считают).

Инглиз һәм татар мәкальләре арасында бер үк образлар кулланып төзелгән, мәгънәләре башка әсәрләр дә очрый. Мәсәлән, инглиз телендәге *«You can lead a horse to water, but you can't make it drink»* дигән мәкаль «Атны су янына китереп була, көчләп эчереп булмый» дип тәрҗемә ителә. Татар телендә ат турында

мәкальләр күп. Мәсәлән «Ат су янында сызгырмасаң да эчәдер, ләкин сызгырсаң, күңеллерәк эчәдер». Татар телендә аналоглары булмаган мәкальләр дә бар.

Мәкаль-әйтемнәрнең туган телдәге эквивалентларын эзләү укучыларда сүзлек белән эшләү һәм тәрҗемә итү күнекмәләрен ныгыта, чит тел дәресләрен укучылар өчен кызыклырак итәргә булыша. Шул ук вакытта туган телгә мәхәббәт тәрбияләүнең бер чарасы да булып тора. Укучылар ике телдәге мәкальләрне яратып чагыштыралар.

Дәрестә мәкальләр куллануның тагын бер әһәмияте бар. Хәзерге вакытта балалар аз сөйләшә. Мәкаль-әйтемнәрне өйрәнү аларның тел байлыгын арттыра. Телләрен бай, образлы итә. Әлбәттә, мәкальләр аша тапшырылган киңәш, ата-бабалар тәҗрибәсе, тәрбия ысуллары яшь кешегә уңай тәэсир ясый.

**Инглиз теле дәресләрендә кулланыла торган инглиз мәкальләре һәм аларның татар телендәге эквивалентлары:**

*A bird in the hand is worth two in the bush.* – Кулдагы чыпчык һавадагы торнадан артык.

*A chief cook and bottle-waster.* – Кулыннан килмәгән эш юк.

*A fool may ask more questions in an hour than a wise man can answer in seven years.* – Бер җүләрнең соравына ун акыллы җавап бирә алмый.

*A good workman is known by his chips.* – Булыр кеше эшеннән билгеле.

*A tree is known by it is fruit.* – Агач җимеше белән, адәм эше белән.

*Absence makes the heart grow fonder.* – Ерактагы кояш яктырак.

*All is not gold that glitters.* – Һәр ялтыраган алтын түгел.

*An apple a day keeps the doctor away.* – Көнгә бер алма ашаган кешегә табиб кирәкми.

*As busy as a bee.* – Кырмыска (умарта корты ) кебек эшчән.

*Barking dogs seldom bite.* – Өргән эт тешләми.

*Beat the air.* – Юкны бушка алыштыру.

*Beauty is in the eyes of the beholder.* – Матур – матур түгел, яраткан матур.

*Beauty is only skin-deep.* – Киемеңә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар.

*Before you choose a friend eat a bushel of salt with him.* – Кешене белер өчен аның белән бер пот тоз ашарга кирәк.

*Between friends all is common.* – Бары – бергә, югы – уртак.

*Bird in the hand is worth two in the bush.* – Һавадагы торнага ышанып кулдагы чыпчыкны ычкындыру.

*Birds of a feather flock together.* – Балыкчы балыкчыны ерактан күрә.

*Born with a silver spoon in your mouth.* – Бәхете белән туган; Алтын кашык белән туу.

*Bowed heads don't get chopped off.* – Иелгән башны кылыч кисми.

*Boys will be boys.* – Малай малай инде.

*Business before pleasure.* – Эш беткәч, уйнарга ярый.

*Constant dropping wears away a stone.* – Тамчы таш тишә.

*Cut your coat according to your cloth.* – Аягыңны юрганыңа карап суз.

*Dance to smb's pipe.* – Кеше кубызына бию.

*Discretion is the better part of valour.* – Алла саклананны саклый.

*Don't count your chickens before they are hatched.* – Чебешләрне көз көне саныйлар.

*Don't teach your grandmother to suck eggs.* – Йомырка тавыкны өйрәтми.

*Don't judge a book by its cover.* – Кеше карбыз түгел, ярып карап булмый.

*East or west home is best.* – Кунакны макта, өйдә тор.

*Easy come, easy go.* – Ничек килсә, шулай китте.

*Every bullet has its billet.* – Язмыштан узмыш юк.

*Every dog has its day.* – Безнең урамда да бәйрәм булыр.

*Every man has his faults.* – Кимчелексез кеше булмый.

*Fine feathers birds.* – Агач күрке – яфрак, адәм күрке – чүпрәк.

*Fine words butter no parsnips.* – Сандугачны җыр белән сыйламыйлар.

*First catch your hare, then cook him.* – Тумаган тайга атлану.

*First think, then speak.* – Башта уйла, аннары сөйлә.

*Fish begins to stink at the head.* – Балык башыннан бозыла.

*Go wherever you wish; Go away and do not come back; Beat it!* – Дүрт ягың кыйбла!

*Great talkers are little doers.* – Аз сөйләгән күп эшләр.

*Half a loaf is better than no bread.* – Балык булмаганда кысла да балык.

*He that is afraid of wounds, must not come near a battle.* – Бүредән курыккан – урманга бармый.

*He that shoots often, at last shall hit the mark.* – Тырышкан табар, ташка кадак кагар.

*He who does not work, neither shall he eat.* – Кем эшләми, шул ашамый.

*If you wish to know what a man is, place him in authority.* – Кешене беләсең килсә, байлык биреп кара.

*Ignorance is bliss.* – Күп белсәң, тиз картаерсың.

*It is too late to lock the stable-door when the horse is stolen.* – Атны урлаткач абзарны бикләмиләр.

*It never rains but it pours.* – Бәла ялгыз йөрми.

*It's a small wor1d.* – Дөнья тар.

*Knowledge is power.* – Белеме бар – меңне егар.

*Let sleeping dogs lie.* – Йоклаган этне уятмыйлар.

*Like father, like son.* – Атасына карап улын коч, анасына карап кызын коч.

*Little wit in the mind makes much work for the feet.* – Эшләмәгән баш аякка ял бирмәс.

*Love is blind.* – Мәхәббәтнең күзе сукыр.

*Make hay while the sun shines.* – Тимерне кызуында сук.

*Marriages are made in heaven.* – Никах күктә укыла.

*Money doesn't grow on trees.* – Акча агачта үсми.

*Never put off tomorrow what you can do today.* – Бүгенге эшне иртәгәгә калдырма.

*Never swap horses crossing a stream.* – Атларны кичүдә алыштырмыйлар.

*No bees no honey, no work no money.* – Эшләмәгән ашамый.

*Once bitten, twice shy.* – Сөткә авызы пешкән, суны өреп эчкән.

*One cannot put back the clock.* – Терсәкне тешләп булмый.

*One man's meat is another man's poison.* – Мәчегә көлке – тычканга үлем.

*Out of the mouths of babes.* – Сабый авызы белән.

*Patience is power; with time and patience the mulberry leaf becomes silk.* – Тырышкан табар, ташка кадак кагар.

*Practice makes perfect.* – Шәкерт булмый, оста була алмассың.

*Pride goes before a fall.* – Тәкәбберлек атта китә, җәяү кайта; Эрелек артыннан хурлык иярә.

*Promise little, but do much.* – Аз сөйлә дә, күп эшлә.

*Rob Peter to pay Paul.* – Итәк кисеп, җиң ямау.

*Sceptics are never deceived.* – Татар тотып карамый ышанмый.

*Second thoughts are best.* – Җиде тапкыр үлчә, бер тапкыр кис.

*Seeing is believing.* – Йөз кат ишеткәнче, бер тапкыр күрү артык.

*Silence is golden.* – Дәшмәү – алтын.

*Still waters run deep.* – Тымызык күлдә корт уйный.

*Strike while the iron is hot.* – Тимерне кызуында сугарга кирәк.

*The absent are always in the wrong.* – Үзе юкның – күзе юк.

*The appetite comes with eating.* – Ашамый-ашамый, җитмеш белен ашаган.

*The chain is no stronger than its weakest link.* – Җеп нечкә җирдән өзелә.

*The early bird catches the warm.* – Иртә торган кошка ходай җим бирә; Иртә торган, эше уңган.

*The grass is greener on the other side.* – Күрше тавыгы күркә булып күренә.

*The race is got by running.* – Эш эшләми уңыш килми.

*The apple never falls far from the tree.* – Алма агачыннан ерак төшми.

*There' s no smoke without fire.* – Утсыз төтен булмый.

*They must hunger in winter that will not work summer.* – Җәй көне җырларсың, кыш көне еларсың.

*Time heals all wounds.* – Вакыт дәва.

*To be back at the bottom of the ladder.* – Ярык тагарак янында калу.

*To kill two birds with one stone.* – Бер атуда ике куян үтерү.

*To know everything is to know nothing.* – Бөтен нәрсәне белү – бернәрсә дә белмәү.

*Touch wood.* – Тьфу-тьфу!

*Train hard fight easy.* – Өйрәнүең минем өчен булса, белүең үзең өчен.

*Two heads are better than one.* – Бер акыл әйбәт, ике акыл яхшырак.

*Two heads are better than one.* – Бер баш яхшы, ике – яхшырак.

*Velvet paws hide sharp claws.* – Мәче белән уйнаган тырнавына түзсен.

*Virtue is its own reward.* – Күркәм холык – җан зиннәте.

*Walls have ears.* – Стеналарның да колагы бар.

*We must learn to forgive and forget.* – Яхшылык эшлә дә суга сал.

*Well begun is half done.* – Башланган эш – беткән эш.

*What goes around, comes around.* – Ни чәчсәң, шуны урырсың.

*What is worth doing at all is worth doing well.* – Көн үтсенгә эшләмә, булсынга эшлә.

*What the eye does not see the heart does not grieve over.* – Күз кайда булса, күңел шунда.

*When the cat is away, the mice will play.* – Мәче югында тычканга бәйрәм. Мәче булмаган җирдә тычканнар хуҗа.

*Where there is a will, there is a way.* – Теләк булса, беләк карышмый.

*Where there's muck there's brass.* – Акчаның исе юк.

*Where there's a will, there is a way.* – Теләк булса, җай табыла (Тәвәккәл таш яра).

*Worry gives a small thing a big shadow.* – Курыкканга куш, койрыгы белән биш.

*You never know what you can do till you try.* – Күз курка, кул эшли.

*You reap what you sow.* – Ни чәчсәң, шуны урырсың.

*Zeal is fit for wise men but is mostly found in fools.* – Акыллы уйлаганчы, тиле сугып ега.

*A fool and his money are soon parted.* – Акыл булса, мал табыла.

*A friend in need is a friend indeed.* – Дус бәла килгәндә беленә.

*A leopard cannot change its spots.* – Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый.

*What is bred in the bone will come out in the flesh.* – Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый.

*All that glitters is not gold.* – Һәр ялтыраган алтын түгел.

*Better late than never.* – Соң булса да, уң булсын.

*Many hands make light work.* – Күмәк тотынса, күлне күчерә.

*Peop1e in glass houses shou1dn't throw stones.* – Кешегә чокыр казыма.

*The apple never falls far from the tree.* – Алма агачыннан ерак төшми.

*The spirit is willing but the flesh is weak.* – Дәрт бар, дәрман юк.

*The truth will out.* – Без капчыкта ятмый.

**Әдәбият**


Английские и русские пословицы и поговорки / М.И. Дубровин. М.: Просвещение, 1993.

*Измайлов В.А.* Сборник английских загадок, пословиц, поговорок. М.: Феникс, 2007. С. 68.

Русско-татарский словарь / под ред. Э.М. Ахунзянова и др. М.: Русский язык, 1985.

Словарь употребительных английских пословиц / под ред. М.В. Буковской, С.И. Вяльцева и др. М.: Русский язык, 1985.

Татар халык мәкальләре: өч томда / төз. Н. Исәнбәт. Казан, 1959, 1963, 1967.

Сопоставительный анализ фразеологических единиц антропоцентрической направленности (на материале русского, английского, татарского и таджикского языков) / Л.Р. Сакаева. Набережные Челны: фКГУ, 2008. С. 173–175.



***Чугунов Александр Сергеевич,***

*Казан шәһәренең 68 номерлы татар-рус гомуми урта белем бирү мәктәбенең инглиз теле укытучысы*

УДК 591.5

*И.И. Рәхимов, Э.Ш. Шәмсевәлиева*

# ТАТАРСТАН ШӘҺӘРЛӘРЕ ШАРТЛАРЫНДА ЙОРТ ХАЙВАННАРЫ ҺӘМ ДОМЕСТИКАЦИЯ (КЫРГЫЙ ҖӘНЛЕКЛӘРНЕ ӨЙДӘ АСРАУ) ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Городская среда и антропогенные ландшафты являются основной средой обитания человека и его спутников домашник животных. Собаки, кошки обитающие в городах и селениях, являются частью жизненного пространства. Это не только квартиры, но и городские парки, улицы. Домашние животные неизбежно вступают в какие-либо отношения с дикими животными, многие из которых успешно освоили городскую среду.

**Ключевые слова:** домашние животные, биотические связи, бездомные животные, привыкание к человеку.

Дөньяда халык саны арта бара, шуңа бәйле рәвештә планетада антропоген факторларның роле дә үсә. Тере табигатькә антропоген йогынты аспектларының берсе – йорт хайваннары һәм табигый бергәлекләрдә яшәүчеләрнең үзара мөнәсәбәте. Өй шартларына ияләштерелгән этләр, песиләр һәм башка хайваннар бүгенге шәһәр кешесе көнкүрешенең аерылгысыз өлешен тәшкил итәләр һәм күп меңьеллар дәвамында аның иярчене ролен үтиләр. Әмма, кыргый җәнлекләрдән бөтенләй диярлек изоляцияләнгән булсалар да, алар белән бәйләнешләргә керәләр. Мондый очракта нейтрализм бик сирәк күренеш.

Әлеге тикшеренүнең максаты – йорт хайваннары белән табигый бергәлекләр фаунасының биотик бәйләнешләрен ачыклау, конкурентлык һәм башка үзара мөнәсәбәтләрнең (ерткычлык, комменсализм һ.б.ның) төп закончалыкларын билгеләү. Шуны истә тоту мөһим, кеше, үз мәнфәгатьләреннән чыгып, «кулга ияләштерелгән» хайваннарның биосферадагы хәлләрен үзгәртә, аларның элеккеге туклану чыганакларын өзә. Күп кенә йорт хайваннары, аларның борынгы бабалары билгеле бер климатик шартларда берничә буыннар дәвамында яшәгән булсалар да, төп хуҗалыкта яшәүдән аерылгач, озак вакытлар мөстәкыйль яши алмыйлар, чөнки аларның әлеге экосистемадагы экологик куышлыкка яраклашырга ярдәм итүче төп трофик элемтәләре югалган була.

Хәзер кешеләр табигатьтә һәм кешеләрнең хуҗалык эшчәнлегендә бер генә җәнлекне дә исәптән төшереп калдырырга ярамавына тәмам ышандылар, чөнки аларның һәр төре табигатьтә үз урынын били һәм биоценоз шартларында билгеле бер роль уйный. Антропоген йогынты тәэсирендә аерым төрләр генә түгел, ә тоташ биоценотик комплекслар үзгәреш кичерә [Шилов, 1998].

Тарих мисалларга бик бай. Көченеп китүчеләр һәрвакыт иямәштергән хайваннарын үзләре белән чит җирләргә алып китәләр. Кәҗәләр һәм дуңгызларны үзләренең туену чыганагы буларак алалар. Бер үк вакытта йорттагы бүтән җәнлекләрне дә (әйтик, этне, песине һ.б.ны) үзләреннән калдырмаска тырышалар. Аларның кайберләре яңа урында кыргыйга әйләнергә мәҗбүр булалар. Европалылар тарафыннан Төньяк Америкага алып килгән атларның язмышы шундый. Америка далаларында шулай кыргыйлашкан атлар – мустангларның гаять зур көтүләрен очратырга була. Кыргыйлашкан җәнлекләр гадәттә тиз үрчиләр һәм, кагыйдә буларак, табигатькә зур зыян китерәләр, чөнки алар үзләре өчен чит экосистемага кушылып китә алмыйлар, нәтиҗәдә биологик тигезләнешне бозалар.

Атлантик океандагы Изге Елена утравы европалылар тарафыннан ачылганчыга (1501 елга) кадәр куе урман белән капланган була. Аны кешеләр, кыргыйлашкан кәҗәләр һәм дуңгызлар юкка чыгара. Маскарен утрауларындагы дронт һәм Яңа Зеландиядәге моа да анда кешеләр килеп яши башлагач һәм алар алып килгән җәнлекләр кыргыйлашкач һәлак булып бетәләр [Новиков, 1979]. Галапагос уртауларындагы үзенчәлекле хайваннар дөньясына, очраклымы, әллә аңлапмы, кителгән кәҗәләр, дуңгызлар, этләр, мәчеләрдән зыян килә. Ул хайваннарның үрчүе әлеге утрауларның кайберләрендә эре җир ташбакалары, икенчеләрендә күптөрле кошлар өчен фаҗигагә әверелә [Гржимек, 1988].

Динго Австралия урманнарында һәм далаларында кыргый хәлдә яши. Кешеләр аңа йорт хайваннарының, аеруча сарыкларның дошманы итеп карыйлар, алар тарафыннан эзәрлекләнгән бу эт үзе дә кешеләрдән качарга тырыша. Динго үзе тукланган җәнлекләрнең бер генә төрен дә юкка чыгармый, әмма Австралиядәге букчалы эре ерткычларның – букчалы шайтан һәм букчалы бүреләрнең санына исәбенә йогынты ясый.

Саны ягыннан көннән-көн ишәя барган ташландык эшләр кыргыйлашкач бүгенге экосистемада нинди үзгәрешләр көтелгәнен әлегә беркем дә әйтә алмый. Хәер, ташландык хайваннар проблемасы һәрвакыт булган. Немец галиме, сәяхәтче, җәнлекләр дөньясы турындагы хезмәтләр авторы Альфред Брем (1829–1884) Европа урманнарында очрый торган, өйдән кыргыйлашкан мәчеләр турында, алар көчле һәм ерткычлар, дип яза. Бу автор Себер этләренең эштән буш вакытларында урманга китеп, кыргый җәнлекләр кебек, азык эзләү белән шөгыльләнүләре турында да яза. Ул этләр елга ярларында уылдык чәчкәннән соң хәлсезләнеп калган балыклар белән туклаланалар, тычкан, куян, йорт боланнарын тоталар, көтү булып йөргәндә, хәтта, кыргый боланнарны да эзәрлекләләр. Л.С. Сабанеев 1878 елда «Природа и охота» журналында, Европа киңлекләрендә яшәүче кыргый мәчеләр турында язганда, өйдән китеп кыргый-

лашкан ата мәчеләр хакында да искә ала.

Ә менә Икенче Бөтендөнья сугышы елларында безнең илдә кайбер кешеләр, ачлыктан, хуҗасыз этләрне һәм песиләрне ашарга мәҗбүр булдылар. Аннан соң бик күпләрнең йортта эт яки мәчене ашатып тотарга хәленнән дә килмәде. Узган гасырның соңгы дистә елларында, кешеләрнең матди мөмкинлекләре яхшыра башлагач кына, шәһәр фатирларында этләр, песиләр асрый башладылар. Әмма төрле сәбәпләр белән аларның бер өлеше урамда кала һәм алар, азык эзләп, чүплекләргә ияләшә. Бу мәсьәлә бүгенге көндә аеруча кискенләште.

XX йөзьеллыкның икенче яртысында Татарстан Республикасының урман һәм кырлар фаунасында кыргыйлашкан этләрнең барлыкка килүе зоологлар игътибары предметына әверелде. Күзәтүләрдән мәгълүм булганча, ач этләр (таксалардан башлап, овчаркаларга кадәр), көтүләргә берләшеп, урман-кырлардагы һәр тере җан иясен юкка чыгаралар. Мондый этләр бүреләрдән дә куркынычрак, чөнки алар сан ягыннан югары. Алар тычканнарны, куяннарны, байбакларны, бурсыкларны аулыйлар, хәтта пошиларны (кыр кәҗәләрен әйткән дә юк инде) куып тоталар [Горшков, Назарова, 2000].

Кайбер җирлекләрдә җәнлекләрнең күпләп үрчүе ике факторга – азык табу мөмкинлегенә һәм яшәү куркынычсызлыгына бәйле. Бүген исә кыргыйлашкан этләр өчен боларның икесе дә бар. Азык күп, ә аларга зыян салырга ерткычлар юк. Мөгаен, шуңа күрә соңгы вакытта аларның үз-үзләрен тотышы үзгәрде, алар курыкмый башладылар, йорт ишеге яннарында, урамнарны тоташтырган җир асты юлларында күпләп йөриләр. Кыргый этләрне аулап тоту көтүдә актив, хәрәкәтчән яшь этләр санын киметми. Җитмәсә, яшь этләр көтүе тавышлы һәм алар агрессив (кешеләргә карата да) [Ибрагимова, Рахимов, Галиев, 2000].

Шәһәрләрдәге һәр ишегалдында чүп баклары янында туклanучы ташландык этләрне очратып була. Алар яннарына килүче кешегә төрлечә карыйлар. Күпчелек очракта, койрыкларын кысып, тараланлар. Мондый этләрне шәһәр читендәге урманчыкларга якын торак пунктларда аеруча күп очратасың. Ә менә торак пункт урман һәм бер үк вакытта дача-бакча ширкәтләре белән чикләшкән урыннарда мондый этләр чын-чынлап афәткә әвереләләр. Моны Васильево (Татарстан) бистәсе читендә күзәтергә була. Дача сезоны ябылгач, ташландык этләр саны күпкә арта.

Мамадыш районының (ТР) Югары Сон авылы янындагы урманда берничә ел инде кыргыйлашкан этләр көтүе яши. Алар даими күзәтү астында. Этләр саны 6–8 арасында тирбәлә. Көндез алар урманда була. Төнлә авылга килеп, үләксә яки корбаннарын эзлиләр. Авыл халкы аларга төрлечә карый. Бервакыт авыру сыерны, үлеп киткәнче дип, авыл янындагы чокырда суялар. Ул сыердан калган бер генә нәрсә дә бозылырга өлгерми, аны кыргыйлашкан этләр

шул төндә үк ашап бетерәләр. Бу очракта этләр санитар ролен үтиләр. Икенче караганда, шул ук этләр кешеләрнең авыл тирәсендә үлән ашап йөргән сарыкларына ташланалар, хәтта абзарларга да һөҗүм итәләр. Алар, көтү булып һөҗүм иткәндә, яңа туган бозауны да өстерәп алып китә алалар. Кышын бу проблема тагын да кискенләшә. Терлекчелек фермаларының каравылчыларына бик уяу булырга, төн буе анда азык эзләп килгән этләрне куарга туры килә.

Бүреләр белән этләрнең гибридлашу күренеше фәнни яктан да, практик яктан да зур кызыксыну уята. Бүреләр этләрнең нәсел башы булуы һәркемгә мәгълүм, шуңа күрә аларның үзара кушылулары гаҗәп түгел, һәм катнаш токым алга таба үрчү сәләтен югалтмый. Венадагы зоологик бакчада яшәүче ана бүре, йорт эте белән кушылып, балалар таба [Брем, 1922]. Табигый шартларда һәм зоопаркларда туган бүре белән эт гибридлары зур кызыксыну тудыра, моңа Дәүләт Дарвин музее коллекцияләрендә мисаллар бар.

Бүре-эт гибридларына хас үзенчәлекләр шунда – бүре балалары гадәти булмаган төстәге тиреле булып туа. Алар еш кына кара яки җирән, ала, сирәк кенә ак төстә була [Павлов, 1990]. 70 нче еллар башына алынган мәгълүматларга караганда, гибрид бүреләр, шул исәптән кара тирелеләре туу чагыштырмача ешайган. Алтай краенда, Мордовия Республикасында, Актүбә, Новосибирск, Пенза, Оренбург, Волгоград, Саратов, Воронеж, Белгород өлкәләрендә гибрид бүреләр тууы хакында мәгълүматлар бар. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, гибрид бүреләр туу күренеше ул елларда урманнарда күчмә һәм кыргыйлашкан этләрнең артуы белән аңлатыла [Павлов, 1990].

Л.С. Рябов Воронеж өлкәсендә гибрид бүреләр иң күп үрчегән чорның XX гасырның 60 нчы елларына, бүреләрнең тоташ кырылып бетү чигенә җиткән вакытка туры килүен ачыклады. Бөтенләй юкка чыгу янаган депрессия чорында бүреләр этләргә карата дустанә мөнәсәбәт сиздерә башлыйлар һәм алар белән кушылырга омтылалар. Ә инде бүреләрнең шул җирлектә баш саны арткач, аларның гибридлашу процессы туктала. Гибрид үрчем тышкы яктан, этләргә түгел, күбрәк бүреләргә тартым була, тире-йоннары гадәти бүреләрнекеннән караңгырак төсе белән аерыла һәм аларның бу үзенчәлекләре этләр белән кушылганда өч, хәтта аннан да күбрәк буыннарга хәтле саклана. Гадәттә гибридларның беренче оясы кыргыйлык һәм усаллык ягыннан бүреләрдән аерылмый, алар өрмиләр, ә улыйлар. 1874 елда Л.П. Сабанеев болай дип яза: «Черные волки встречаются под Чистополем (РТ) и по настоящее время. Вероятно предположение, что за черных волков нередко принимались в России одичавшие собаки или же гибриды от собаки и волка» [Сабанеев, 1874].

1984 елда Казан әзерләп сату базасы Бөтенсоюз сунарчылык һәм җәнлек асраучылык фәнни-тикшеренү институтына

(ВНИИОЗ) биш данә кара төстәге, бераз тузгып торган йонлы, әмма танавы чал төстәге йон белән капланган тире җибәрә һәм аның гибрид җәнлекнекеме, әллә түгелме икәнлеген раслауларын үтенә. Чөнки бүре-этләр кеше өчен аеруча куркыныч [Попов, Лукин, 1988]. П.К. Горшков белдергәнчә, Алексеевка авылы тирәсендә билгеле бер вакыт дәвамында андый бүре-этләр очрый.

Яңа «экологик берәмлек» бергәлекләрнең яңа экологик куышлыклар белән тулыландырылуы хисабына барлыкка килә, бу – экосистемадагы үзгәрешләр белән бәйле күпкырлы процесс [Шилов, 1977]. Хәзерге вакытта фаунаның формалашуы процессын үзагымына куярга ярамый. Ташландык һәм кыргыйлашкан этләрне пространствода урнаштыруда, аларның таралу һәм үрчүләрендә кешенең катнашуы мәҗбүри таләп. Алга таба бу процессларны җайга салу өчен аларны максатчан өйрәнү өлкәсендә зур эшләр көтә. Югыйсә, кешелек табигатьтәге кыргый төрләрнең санын тагын да югалтырга мөмкин.

**Әдәбият**


*Брэм А.Э.* Жизнь животных: в 3-х т. М.: Терра, 1992. Т. 1: Млекопитающие. 524 с.; Т. 2. Птицы. 352 с.

*Горшков П.К., Назарова И.В.* Изменения в фауне млекопитающих республики Татарстан за последние 50 лет // Актуальные проблемы Республики Татарстан. Казань: Новое знание, 2000. С. 38.

*Гржимек Б.* Экологические очерки о природе и человеке. М.:Прогресс, 1988. 640 с.

*Ибрагимова К.К., Рахимов И.И., Галиева А.А.* К изучению бродячих собак в условиях большого города // Актуальные проблемы Республики Татарстан. Казань: Новое знание, 2000. С. 49.

*Новиков Г.А.* Основы общей экологии и охраны природы. Л.: Изд-во ЛГУ, 1979. 351 с.

*Павлов М.П.* Волк. М.: Агропромиздат, 1990. 349 с.

*Попов В.А., Лукин А.В.* Животный мир Татарии. Казань: Таткнигоиздат, 1988. 248 с.

*Сабанеев Л.П.* Позвоночные Среднего Урала и географическое распространение их в Пермской и Оренбургской губерниях. М., 1874. 204 с.

*Шилов И.А.* Экология. М.: Высшая школа, 1998. 512 с.

*Шилов И.А.* Эколого-физиологические основы популяционных отношений у животных. М.: Изд-во МГУ, 1977. 262 с.



***Рәхимов Илгизәр Ильяс улы,***
*биология фәннәре докторы, профессор,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының биоэкология,*
*гигиена һәм иҗтимагый сәламәтлек кафедрасы мөдире*

***Шәмсевәлиева Эльмира Шамил кызы,***
*биология фәннәре кандидаты*

УДК 579

*Л.Ф. Миңнуллина, Э.Р. Шәйдуллина*

# АНТИМИКРОБ МАТДӘЛӘРГӘ КАРШЫ ТОРУЧАНЛЫК: ТАРАЛУ СӘБӘПЛӘРЕ ҺӘМ МЕХАНИЗМНАРЫ

Устойчивость к антимикробным препаратам (АМП) представляет серьезную медицинскую и экономическую проблему. В первую очередь, это имеет большое значение для клинически значимых микроорганизмов. В статье приводится краткий обзор механизмов устойчивости и причин его распространения в глобальном масштабе. Внедрение АМП в терапию инфекционных заболеваний значительно увеличило скорость возникновения и распространения устойчивости у микроорганизмов. Проигрывание в «гонке вооружений» между резистентными микроорганизмами и человеком может привести к катастрофическим последствиям, откинув человечество назад во времени, когда даже самая банальная инфекция была практически неизлечимым заболеванием.

**Ключевые слова:** антимикробные препараты, механизмы антибиотикорезистентности, антибиотики.

1938 елдан кулланылышка кергән антимикроб матдәләр кешенең уртача гомер озынлыгын арттырып кына калмады, йогышлы авыруларга булган мөнәсәбәтне дә тамырдан үзгәртте. Бүгенге көндә арзан һәм нәтиҗәле антимикроб препаратлардан башка сәламәтлек саклау системасын хәтта күз алдына да китереп булмый. Әмма, антибиотикларны күпчелек инфекцияләрне дәвалауда куллана башлау, авыру кузгатучы микроорганизмнарда әлеге матдәләргә чыдамлылык (резистентлык) формалашу проблемасын да китереп чыгарды. Соңгы елларда исә бу күренеш пандемия төсен ала бара.

Бүгенге көндә чыдам штаммнар таралуның мөһим сәбәпләреннән берсе – антимикроб матдәләрне максатсыз куллану икәнлеге ачыкланды. 2015 елда Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы (БСО) үткәргән глобаль сораштыру мәгълүматларына караганда (12 илдән 9772 респондент катнашты), халыкның 64% ы (Россиядә 67%) антибиотиклар ярдәмендә грипп һәм салкын тиюне дәвалап булганлыгына ышана, ә 32% ы (Россиядә 26%) хәл яхшыру белән, дәвалау курсын тәмамламыйча, антибиотиклар куллануны туктатырга була дип саный икән [Обследование ВОЗ в странах ..., 2015].

Антибактериаль матдәләргә чыдамлылык медицина өчен генә түгел, бәлки икътисад өчен дә җитди проблема тудыра. Мультирезистент (берьюлы берничә антибиотикка чыдам булу) бактерияләр килеп чыгуга сәбәп тудырган авыруларны дәвалауга шактый күп вакыт сарыф ителә, ә бу, үз чиратында, хезмәт җитештерүчәнлеген киметә, дәвалау һәм диагностикага киткән чыгымнар күләмен арттыра. Соңгы мәгълүматларга кара-

ганда, антимикроб матдәләргә чыдамлылык Европада ел саен 2 049 442 авыру, 25000 үлем очрагының сәбәбе булып тора, һәм сәламәтлек саклауга өстәмә 1,5 млрд. € бүлеп бирүне таләп итә [The bacterial challenge: time to react, 2009]. АКШта исә мультирезистент бактерияләр барлыкка килүгә сәбәпче булган 2 млн. авыруга 23 000 үлем очрагы туры килә, ә сәламәтлек саклауга киткән өстәмә чыгымнар елына 20 млрд. $ тәшкил итә [Center for disease control and prevention, 2013]. Россиядә дә антимикроб матдәләргә резистентлык проблемасы, башка илләрдәге кебек үк, кискен тора. Әмма, чит илләрдән аермалы буларак, безнең илдә бактерияләрнең чыдамлылыгы таралуны күзәтү системасы җайга салынып бетмәгән әле.

Шулай итеп, амбулатор һәм госпиталь инфекцияләренең этиологик структурасын, аларны кузгатучы бактерияләрнең төрле антимикроб матдәләргә каршы торучанлыгын һәрдаим тикшереп тору актуаль бурычларның берсе санала. Бу – бактерияләр арасында еш кулланыла торган антибиотикларга резистентлык үсешен билгеләргә һәм төрле илләрдә кабул ителгән дәвалау стандартларын вакытында яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк [Возрастающая угроза развития..., 2013].

**Төп терминнар һәм антимикроб матдәләрнең кыскача тарихы.** Антимикроб матдәләр дип бактерияләр, вируслар, микроскопик гөмбәләр һәм паразитларга тәэсир итүче матдәләрне атыйлар. «Антибиотик» терминының төгәл мәгънәсен алсак, бу – микроорганизмнар табигый юл белән синтезлаучы антимикроб матдәләр дигәнне аңлата. Мәсәлән, *Penicillium* ыруы күгәрек гөмбәләре бүлеп чыгарган пенициллин шушы категориягә карый. Ә химик юл белән табылган синтетик матдәләр, дөреслектә, антибиотик түгелләр, гәрчә халык телендә күптәннән «антибиотик» сүзенең синонимына әверелгән булсалар да. Синтетик матдәләргә, мисал өчен, хинолоннар карый [Aminov *et al.*, 2014, Hamilton *et al.*, 2016].

Антибиотикларга резистентлык – һәрвакытта да яңадан барлыкка килгән билге түгел, күпчелек бактерияләр теге яисә бу антимикроб матдәләргә карата табигый чыдамлылыкка ия. Әйтик, *Escherichia coli* (эчәклек таякчыгы) кебек грам-тискәре бактерияләрнең күпчелегенә пенициллинга карата табигый чыдамлылык хас. Чыннан да, микроорганизмнар арасында антимикроб матдәләргә каршы торучанлык күренеше антибиотиклар ачылганчыга кадәр үк таралган була. Бактерияләр меңләгән еллар дәвамында башка микроорганизмнар бүлеп чыгарган антимикроб матдәләр тәэсирендә яшәгән, шунлыктан резистентлык геннарының күпчелеге «антибиотиклар эрасы»на кадәр үк барлыкка килгән. Әмма, антимикроб матдәләрне контрольсыз һәм хаҗәтсез куллану резистентлык таралу тизлеген шактый арттыра. Сәламәтлек саклау һәм авыл хуҗалыгы өлкәләрендә антибиотикларны дөрес кулланмау (дәваланып бетмичә, антибактериаль препаратларны куллануны туктату;

антибиотикларны терлек массасын арттыру максатында куллану) әлеге проблеманы катлауландыра. Китерелгән таблицада төрле антимикроб матдәләрнең төп сыйныфлары һәм аларга карата резистентлык формалашу турында мәгълүмат китерелгән.

Антибиотикларның кулланылышка керүе һәм аларга резистентлык формалашу [Lewis, 2013]

| Антибиотиклар сыйныфы (мисал) | Куллана башлау елы | Резистентлык турында беренче мәгълүмат (елы) |
|---|---|---|
| β-лактамнар (пенициллин) | 1938 | 1945 |
| Аминогликозидлар (стрептомицин) | 1946 | 1946 |
| Хлорамфениколлар (хлорамфеникол) | 1948 | 1950 |
| Макролидлар (эритромицин) | 1951 | 1955 |
| Тетрациклиннар (хлортетрациклин) | 1952 | 1950 |
| Рифампициннар (рифампицин) | 1958 | 1962 |
| Гликопептидлар (ванкомицин) | 1958 | 1960 |
| Хинолоннар (ципрофлоксацин) | 1968 | 1968 |
| Оксазолидиноннар (линезолид) | 2000 | 2001 |

**Антимикроб матдәләргә карата чыдамлылык механизмнары.** Антимикроб матдәләргә каршы торуда микроорганизмнар төрле механизмнар куллана ала, шуларның иң таралганнарына түбәндәгеләр керә:

1. Антимикроб матдәләрне таркатырга яисә структураларын үзгәртергә сәләтле ферментлар бүлеп чыгару (мисал өчен, β-лактамнар һәм аминогликозидларны «бозучы» ферментлар);

2. Мембрананың үткәрүчәнлеген үзгәртү ярдәмендә антимикроб матдәнең күзәнәк эченә үтеп керүен булдырмау (макролидларга карата кулланыла);

3. Антимикроб матдәләрне күзәнәк эченнән актив суыртып торучы эффлюкс-системалар булу (сульфаниламидларга карата кулланыла);

4. Антибиотик тәэсир итәргә тиешле кушылманың структурасын үзгәртү (сульфаниламидларга карата кулланыла);

5. Метаболизм юлларын үзгәртү ярдәмендә (метаболик шунт) антибиотиклар тәэсирен компенсацияләү.

Әлеге механизмнар барлыкка килүнең ике төп юлы бар: беренчесе – эволюция барышында билгеле бер геннарда эчке сәбәпләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән мутацияләр туплану, икенчесе – горизонталь күчеш (тугандаш булмаган организмнар арасында геннар алмашы) вакытында башка микроорганизмнардан кергән резистентлык геннарын үзләштерү. Антимикроб матдәләр эчке сәбәпләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән мутацияләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән штаммнарга карата селектив фактор ролен башкара, ягъни әлеге матдәгә сизгер бактерияләр популяциядән юкка чыга, ә «көндәшләреннән» котылган чыдамнары, башта азчылыкны тәш-

кил итсәләр дә, тиз арада үрчеп, тирәлектә тарала. Монда табигатьтәге күпчелек микроорганизм бергәлекләренең төрле төрләргә караучы бактерияләрдән торуын искә төшерү зарур. Димәк ки, төрле төргә караучы бактерияләр арасында геннар алмашы барлыгын истә тотып, билгеле бер антимикроб матдәгә чыдамлылык тиз арада төрле микроорганизмнар арасында таралырга мөмкин, дип әйтеп була.

**Антимикроб матдәләргә резистентлыкның киң таралу сәбәпләре.** Фармацевтик оешмаларның яңа антимикроб матдәләр эзләү һәм җитештерүгә кызыксынуы кимү – авыр дәвалана торган инфекцияләр саны артуга китергән факторларның берсе булып тора. Мисал өчен, 2004 елда 15 иң эре фармацевтик компаниядә клиник тикшерүләр стадиясендәге препаратларның 1,6% ын гына антибиотиклар тәшкил иткән [Shlaes, 2010]. Кагыйдә буларак, антибиотиклар белән дәвалау курсы озакка сузылмый (туберкулезны дәвалау кебек кайбер искәрмәләрне санамаганда), ә бу исә, хроник авырулар вакытында кулланылган препаратлар белән чагыштырганда, антибиотиклар җитештерүне отышсызрак итә. Моннан тыш, яңа җитештерелгән антимикроб препаратлар, гадәттә, резерв төркемгә күчерелә һәм аннан иске препаратлар тәэсир итми башлагач кына чыгарыла. Мондый сәясәт резистент микроорганизмнар таралу тизлеген тоткарласа да, фармацевтик компанияләр керткән беренчел инвестияләрнең нәтиҗәлелеген киметә [Fair, Tor, 2014].

Антимикроб матдәләргә чыдамлылык таралуның тагын бер сәбәбе булып антибиотикларны дөрес кулланмау тора. Монда табип белән киңәшмичә антибиотиклар куллану, кайбер препаратларның даруханәләрдә рецептсыз сатылуы һәм, шулай ук, антибиотиклар белән дәвалануны җиренә җиткереп башкармау керә. Мәсәлән, күпчелек пациентлар, җиңеллек сизү белән, дәвалану курсын ахырына җиткермичә, антибиотиклар куллануны туктата. Нәтиҗәдә авыру тудыручы микроорганизмнарның бер өлеше исән кала, ә антибактериаль матдәнең түбән концентрациясе эчке сәбәпләрдән барлыкка килгән мутацияләр ешлыгын арттыра, шулай итеп, башта әлеге матдәгә сизгер булган микроорганизмнар да ахырда аңа чыдамга «әверелә». Мәсәлән, фторхинолоннар бәвел юллары инфекцияләрен кузгатучы *E. coli* бактерияләрендә шундый мутацияләр ешлыгын арттыра [Hughes, Lindgren, 2003]. Һәм ниһаять, антибиотиклар куллану зарури булмаган пациентларны әйтелгән препаратлар белән дәвалау (ягъни табибларның, кирәкмәсә дә, антибиотиклар язып бирүе) да чыдамлылык таралу проблемасына үз өлешен кертә. Әйтик, АКШның авыруларны кисәтү һәм контрольда тоту үзәге (CDC) китергән мәгълүматларга караганда, АКШ табиблары язган рецептларның 1/3 өлеше үзләрен акламаган [Hamilton *et al.*, 2016].

Шулай итеп, микроорганизмнарның антимикроб матдәләргә чыдамлылыгы бөтендөнья сәламәтлек саклау системасы өчен

зур куркыныч тудыра. Мультирезистент авыру кузгатучы бактерияләр үлүчеләр санын һәм сәламәтлек саклауга тоткан чыгымнарны арттыра. Шунлыктан, фармацевтик компанияләрне яңа антимикроб матдәләр җитештерүгә юнәлтү һәм бу юнәлешне инвестицияләү һәрбер дәүләт өчен мөһим максатларның берсенә әверелергә тиеш. Моннан тыш, резистент штаммнарның таралуын даими күзәтеп тору, халык һәм медицина хезмәткәрләре арасында әлеге мәсьәләгә карата аңлату эшләре алып бару да мөһим. Глобализация процессы чыдам штаммнар таралуга киң мөмкинлекләр тудыра. Бары тик аек акыл һәм җентекләп уйланган план гына чыдам микроорганизмнар таралу куркынычын киметергә һәм резистентлыкның алга таба үсешен тоткарларга мөмкинлек бирәчәк.

**Әдәбият**


Возрастающая угроза развития антимикробной резистентности // Всемирная организация здравоохранения, 2013. 130 с.

Обследование ВОЗ в странах свидетельствует о широко распространенном непонимании общественностью устойчивости к антибиотикам // Всемирная Организация Здравоохранения. 2015. Режим доступа: http://www.who.int/mediacentre/news/releases/2015/antibiotic-resistance/ru/#content.

*Aminov R.I., Mackie R.I.* Evolution and ecology of antibiotic resistance genes // FEMS Microbiol Lett. 2007. V. 271(2). P. 147–161.

Center for disease control and prevention // Antibiotic resistance threats in the United States, 2013.

*Fair J.R., Tor Y.* Antibiotics and bacterial resistance in the 21th century // Perspectives in medicinal chemistry. 2014. V. 6. P. 25–64.

*Hamilton W.L., Wenlock R.* Antimicrobial resistance: a major threat to public health // Cambrige Med J. 2016: doi:10.7244/cmj.2016.01.001.

*Hughes D., Lindgren P.K.* Mutation rate and evolution of fluoroquinolone resistance in *Escherichia coli* isolates from patients with urinary tract infections // Antimicrob. Agents Chemother. 2003. V. 47:3222. doi:10.1128/AAC.47.10.3222

*Lewis K.* Platforms for antibiotic discovery // Nat. Rev. Drug Discov. 2013. V. 12(5). P. 371–387.

*Shlaes D.M.* Antibiotics: the perfect storm. New York: Springer. 2010. P. 1–7.

The bacterial challenge: time to react // European Centre for Disease Prevention and Control, 2009. 54 p.


*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә.*

***Миңнуллина Ләйлә Фәрваз кызы,***
*Казан федераль университеты аспиранты, Фундаменталь медицина һәм биология институтының кече гыйльми хезмәткәре*

***Шәйдуллина Эльвира Расил кызы,***
*Казан федераль университеты магистранты, Фундаменталь медицина һәм биология институтының техник-проектчысы*

УДК 579

***Л.Ф. Миңнуллина, А.М. Мәрданова***

# MORGANELLA MORGANII БАКТЕРИЯЛӘРНЕҢ ГЕМОЛИТИК АКТИВЛЫГЫ

Статья посвящена сравнительному анализу гемолитической активности клинических изолятов *Morganella morganii*, выделенных из мочи амбулаторных больных с инфекциями мочевыводящих путей. Показано, что разные изоляты *M. morganii* различаются по степени гемолитической активности. Выявлено влияние состава питательной среды на синтез гемолизинов и изучена динамика их накопления в среде культивирования.

**Ключевые слова:** *Morganella morganii,* инфекции мочевыводящих путей, факторы вирулентности, гемолиз.

*Enterobacteriaceae* семьялыгына караучы *Morganella morganii* бактерияләре кешеләр һәм имезүче хайваннарның юан эчәклегендә очрый [Kim *et al.,* 2007]. Әмма, шул ук вакытта, әлеге микроорганизмнар киң спектрдагы оппортунистик инфекцияләр сәбәпчесе дә булырга мөмкин [Williams *et al.,* 1983; Atalay *et al.,* 2010]. Оппортунистик инфекцияләр дип шартлы патоген микроорганизмнар китереп чыгарган авыруларны атыйлар. *M. morganii* иммун системасы зәгыйфьләнгән кешеләрдә бәвел юллары, сепсис, яра инфекцияләре һәм башка төрле авырулар китереп чыгарырга сәләтле [Tucci, Isenberg, 1981; Chen *et al.,* 2012]. Шуңа да карамастан, *M. morganii* бактерияләренең вирулентлык факторлары әлеге көнгәчә җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән.

Шартлы патоген бактерияләрнең инфекция кузгата алу сәләте турыдан-туры вирулентлык факторларына бәйле. Әлеге факторларга эукариотик организмда исән калырга һәм үрчергә ярдәм итүче матдәләрне кертәләр (токсиннар, адгезиннар, эукариотик күзәнәккә үтеп керергә һәм иммун системасыннан «качарга» ярдәм итүче матдәләр) [Бухарин и др., 2005]. Статистика мәгълүматларына караганда, *M. morganii* клиник изолятларының яртысыннан артыгы гемолитик активлыкка ия, ягъни эритроцитларны таркатырга сәләтле [Chen et al., 2012]. Гемолитик активлык PFT (pore-forming toxins) төркеменә караган экзотоксиннар (гемолизиннар) синтезы белән бәйле. PFTларның төп функциясе булып эукариотик күзәнәк мембраналарын җәрәхәтләү тора: плазматик мембранасы җәрәхәтләнгән күзәнәк тиз арада туклыклы матдәләр һәм ионнарын югалта, һәм үлемгә дучар була. Моннан тыш, PFTларның эшчәнлеге бактериаль аксымнарның эукариотик күзәнәккә үтеп керүен һәм фагосомаларга эләккән бактерияләрнең цитоплазмага чыгуын тәэмин итә ала [Linhartová *et al.,* 2010], ә цитоплазмага чыккан бактерияләр

исә, үрчеп, соңрак күзәнәкнең үлеменә китерә. Фәнни әдәбият мәгълүматларына караганда, PFT геннарында мутацияләр булган бактерияләр өлешчә яисә тулысынча вирулентлыкларын югалта, шунлыктан әлеге аксымнар антибактериаль терапия өчен яңа мишень буларак каралырга мөмкин [Los et al., 2013]. Безнең эшебез исә Казан шәһәрендә бүлеп алынган *M. morganii* клиник изолятларының гемолитик активлыгын тикшерүгә багышланды.

Тикшеренү эшендә кулланылган *M. morganii* изолятлары Казан шәһәренең «Биомед» дәвалау-диагностика үзәге тарафыннан амбулатор авыруларның бәвеленнән бүлеп алынды. Сайланган изолятларның гемолизиннар синтезына сәләтен билгеләү өчен канлы агар (*малай* желе) тирәлеге кулланылды. Әлеге тирәлектә үскәндә, *M. morganii* 4 һәм *M. morganii* 190 штаммнарының колонияләре тирәсендә тирәлекнең төссезләнүе күзәтелде (β- яки чын гемолиз), бу аларның гемолизиннар синтезына сәләтле икәнлеге турында сөйли (1 нче рәс.). Шул ук вакытта, *M. morganii* 1 колонияләре тирәсендә төссезләнү күренеше күзәтелмәде, ләкин тирәлек яшькелт төскә керде. Әлеге күренеш эритроцит мембраналарының структурасы бераз бозылып, гемоглобинның бер өлеше генә тирәлеккә чыгуы белән аңлатыла һәм α- яки тулы булмаган гемолиз дип йөртелә.

Шулай да, канлы агар тирәлеге бактерияләрнең гемолизиннарны күпме күләмдә бүлеп чыгарулары турында мәгълүмат бирә алмый. Әлеге проблеманы чишәр өчен түбәндәге методика кулланыла [Senior, Hughes, 1987]: бактерияләрнең культураль сыекчасын (бактериаль суспензияне центрифугада әйләндергәннән соң утырма өстендә кала торган сыекча; әлеге сыекча секрецияләнә торган бөтен матдәләрне туплый) 1:9 чагыштырмасында 2% лы кеше эритроцитлары суспензиясе белән кушалар һәм 30 мин дәвамында 37 °С температурада тоталар. Центрифугада әйләндерү таркалган эритроцит калдыкларын пробирка төбенә утырырга мәҗбүр итә, ә тирәлеккә чыккан гемоглобин исә өстәге сыекчада кала. Әлеге сыекчаның 540 нм дулкын озынлыгындагы оптик тыгызлыгын (OD, optic




1 нче рәсем. Канлы агар тирәлегендә *M. morganii* изолятларының гемолитик активлыгын билгеләү.

density) үлчәү, бактерияләрнең ни күләмдә гемолизиннар бүлеп чыгаруы турында мәгълүмат бирә ала. Моның өчен түбәндәге махсус формула кулланыла:

**Гемолитик активлык (бер./мл) = $OD_{540}$/(0,01×реакция вакыты (мин)×гемолизин күләме (мл))**

*M. morganii* бактерияләренең гемолизиннарны үсешнең кайсы фазасында синтезлавын билгеләү өчен, LB тирәлегендә үстерелгән төрле сәгатьлек культураларның культураль сыекчасы тикшерелде. Алынган нәтиҗәләргә карағанда, барлык штаммнарның да максималь гемолитик активлыгы үсешнең 2нче сәгатенә туры килә (2 нче рәс.). Әмма синтезланган гемолизиннарның күләме буенча штаммнар арасында аермалар шактый зур. Әйтик, *M. morganii* 190 штаммының гемолитик активлыгы 1 мл сыекчага 40 берәмлек тәшкил итсә, *M. morganii* 4 өчен бу күрсәткеч 2 тапкырга кимрәк, ә *M. morganii* 1 штаммының активлыгы гомумән 2 берәмлеккә генә җитә. Рәсемнән күренгәнчә, *M. morganii* 1 штаммы гемолизиннарны үсешнең 2 нче сәгатендә генә бүлеп чыгара, әлеге факт канлы агар тирәлегендә алынган нәтиҗәләр белән яраша һәм штаммның гемолитик активлыгы гаять түбән дәрәҗәдә икәнен күрсәтә. Калган ике штаммнан аермалы буларак, *M. morganii* 190 штаммының гемолитик активлыгы бик әкрен кими, һәм үсешнең 11нче сәгатенә генә билгеләнми башлый.

Әүвәл *M. morganii* 1 һәм *M. morganii* 4 штаммнарының HeLa аналык карциномасы күзәнәкләренә (HeLa күзәнәкләре кеше организмына нинди дә булса факторларның тәэсирен өйрәнгәндә модель объект буларак




2 нче рәсем. *M. morganii* штаммнарының төрле үсеш сәгатьләрендә чагыштырма гемолитик активлыгы.

кулланыла) тәэсире өйрәнелгән иде. Алынган нәтиҗәләргә караганда, 10% лы сыер яралгысы сүле (телячья эмбриональная сыворотка)кушылган DMEM тирәлегендә (Dulbecco's Modified Eagle's medium – эукариотик күзәнәкләр үстерүдә кулланыла торган туклыклы тирәлек; аның составына органик булмаган тозлар, аминокислоталар, витаминнар һәм глюкоза керә) үскән *M. organii* 4 бактерияләре HeLa күзәнәкләре катлавының структурасын бозарга сәләтле (мәгълүмат китерелми). Билгеле булганча, эукариотик күзәнәкләр гаять нәзберек, шунлыктан аларны лаборатория шартларында үстерү өчен туклыклы матдәләргә бик бай, организм эчендәге шартларны (*in vivo*) имитацияләргә сәләтле тирәлекләр кулланырга кирәк. Сыер яралгысы сүле бу таләпләргә туры килә, шунлыктан аны төп тирәлеккә өстәмә буларак кулланалар.

*M. morganii* 4 бактерияләренең төрле тирәлектә үскәндә гемолизиннар синтезлауга сәләте өйрәнелде. Тәҗрибәдә LB, DMEM һәм 10% сыер яралгысы сүле кушылган DMEM тирәлекләре файдаланылды. Бактерияләр 24 сәгать дәвамында, эукариотик күзәнәкләр белән үстергәндәге кебек, 37°C температурада стационар шартларда үстерелде. Сәгать саен һәр варианттан культураль сыекча алынды, соңрак андагы гемолитик активлык билгеләнде. 3 нче рәсемнән күренгәнчә, *M. morganii* 4 бактерияләре гемолизиннарны иң күп сүл кушылган DMEM тирәлегендә, үсешнең 6нчы сәгатендә синтезлый: әлеге ноктада гемолитик активлык якынча 1 мл-га 83 берәмлек тәшкил итә. LB тирәлегендә мак-




3 нче рәсем. *M. morganii* 4 бактерияләренең төрле тирәлекләрдә үсеш дәверендә чагыштырма гемолитик активлыгы.

сималь активлык, алда билгеләнгәнчә, үсешенең 2 сәгатендә күзәтелә, һәм 28 берәмлеккә җитә. Шул ук вакытта, өстәмәләрсез DMEM тирәлегендә гемолитик активлык бөтен үсеш дәверендә 2–4 берәмлектән артмый.

Әлеге нәтиҗәләр сыер ялангысы сүленең гемолизиннар синтезын арттырырга сәләтле булуы турында сөйли. Алда әйтеп киткәнчә, әлеге кушылма *in vivo* шартларын имитацияли, димәк макрорганизм эчендәге шартлар үзләре үк бактерияләрнең вирулентлыклары, аерым алганда, гемолитик активлыклары артуга китерә. Бу бигрәк тә гемолитик бактерияләр кан юлларына эләккәндә җитди проблемалар тудырырга мөмкин.

Шул рәвешле, бәвел үрнәкләреннән бүленгән *M. morganii* бактерияләренең гемолизиннар синтезына сәләте тикшерелде. Алынган нәтиҗәләргә караганда, *M. morganii* клиник изолятларының *in vitro* шартларында күзәтелгән максималь гемолитик активлыгы үсешнең 2 нче сәгатенә туры килә, һәм бу факт фәнни әдәбият мәгълүматлары белән дә яраша [Eberspächer *et al.*, 1990]. Шулай ук, макроорганизм шартларын имитицияләүче факторларның гемолизиннар синтезен арттыруга сәләте күрсәтелде. Бу исә, авыру тудыручы гемолитик бактерияләр белән көрәштә гемолизиннар синтезен яисә эшчәнлеген тоткарлаучы матдәләр куллану перспективасын күрсәтә.

## Әдәбият

*Бухарин О.В. Гинцбург А.Л., Романова Ю.М.* и др. Механизмы выживания бактерий // М.: Медицина, 2005. 367 с.

*Atalay H., Güney I., Solak Y., Almaz E.* First case of CAPD-related peritonitis caused by *Morganella morganii* // Petit Dial Int. 2010. V. 30 (1). P. 119–121.

*Chen Y.T., Peng H.L., Shia W.C., Hsu F.R., Ken C.F., Tsao Y.M., Chen C.H., Liu C.E., Hsieh M.F., Chen H.C., Tang C.Y., Ku T.H.* Whole-genome sequencing and identification of *Morganella morganii* KT pathogenicity-related genes // BMC Genomics. 2012. V. 13. 13 (Suppl 7): S. 4.

*Eberspächer B., Hugo F., Pohl M., Bhakdi S.* Functional similarity between the haemolysins of *Escherichia coli* and *Morganella morganii* // J. Med. Microbiol. 1990. V. 33. P. 165–170.

*Kim J.H., Cho C.R., Um T.H., Rhu J.Y., Kim E.S., Jeong J.W., Lee H.R. Morganella morganii* sepsis with massive hemolysis // J. Korean Med. Sci. 2007. V. 22 P. 1082–1084.

*Linhartová I., Bumba L., Mašín J., Basler M., Osička R., Kamanová J., Procházková K., Adkins I., Hejnová-Holubová J., Sadílková L., Morová J., Sebo P.* RTX proteins: a highly diverse family secreted by a common mechanism // FEMS Microbiol. Rev. 2010. V. 34, No. 6. P. 1076–1112.

*Los F.C., Randis T.M., Aroian R.V., Ratner A.J.* Role of pore-forming toxins in bacterial infectious diseases // Microbiol. Mol. Biol. Rev. 2013. V. 77, No. 2. . 173–207.

*Senior B.W., Hughes C.* Production and properties of haemolysins from clinical isolates of the *Proteeae* // J. Med. Microbiol. 1987. V. 24. P. 17–25.

*Tucci V., Isenberg H.D.* Hospital cluster epidemic with *Morganella morganii* // J. Clin. Microbiol. 1981. V. 14, No. 5. P. 563–566.

*Williams E.W., Hawkey P.M., Penner J.L., Senior B.W., Barton L.J.* Serious nosocomial infection caused by *Morganella morganii* and *Proteus mirabilis* in a cardiac surgery unit // J. Clin. Microbiol. 1983. V. 18, No. 1. P. 5–9.

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә.*

***Миңнуллина Ләйлә Фәрваз кызы**,*
*Казан федераль университеты аспиранты, Фундаменталь медицина һәм биология институтының кече гыйльми хезмәткәре*

***Мәрданова Айслу Миркасыйм кызы**,*
*биология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының Фундаменталь медицина һәм биология институты доценты*

УДК 929

***Н.Җ. Айдаров***

# ҖӘҮДӘТ АЙДАРОВНЫҢ БЛОКАДА ЭПОПЕЯСЫ
## Шәһәр-фронттан хатлар

В статье представлены архивные документы Жавдета Айдарова – участника легендарного исполнения Седьмой симфонии Д.Д. Шостаковича в блокадном Ленинграде. Сообщается о творческой жизни музыканта, эпизодах его жизни в осажденном городе, работе К.И. Элиасберга с оркестром Ленинградского радио. Впервые публикуются письма Айдарова военных лет.

**Ключевые слова:** блокада Ленинграда, письма, К.И. Элиасберг, Д.Д. Шостакович, Ж.К. Айдаров, Седьмая симфония.

*«После невыносимо трудной блокады и после первого исполнения Седьмой симфонии Шостаковича прошло несколько десятилетий. Я все еще с большим изумлением думаю: как человек силен! Как он вынослив! Мне самому, участнику исполнения Седьмой симфонии, не верится, что в таких нечеловеческих условиях возможно исполнение музыки, возможна творческая деятельность симфонического оркестра. Я твержу: это невероятно, но очевидно. Это действительно было»*[1].

Җәүдәт Кәрәмәтулла улы Айдаровның (1918–2000) студентлар белән очрашуда әйткән бу сүзләре аның хәтерендә Ленинград блокадасы эпопеясының авыр мизгелләрен яңартып җибәрә. Аңа бу темага әйләнеп кайту җиңел түгел иде, чөнки анда күргәннәре әйтеп, аңлатып бетерерлек кенә булмый. Шулай да ул ленинградлыларның – сәнгать эшлеклеләренең батырлыгы, легендар шәһәр-фронт, Д.Д. Шостаковичның Җиденче симфониясен башкару турында сөйләүне үзенең бурычы дип саный...

Җ.К. Айдаровның тормыш юлында көтелмәгән борылышлар күп була. Музыкаль башлангычы аңа башта бернәрсә дә вәгъдә итми. Ул буыннан буынга күчеп килгән руханилар гаиләсендә туа, аның бабалары Идел буе һәм Урал якларында танылган дин эшлеклеләре булалар. Әтисе – Кәрәмәтулла Әхмәт улы Айдаров Пермьдә дәрәҗәле мулла була, инкыйлабтан соң, репрессияләрдән куркып, гаиләсе белән Урта Азиягә күчеп китә. Күченеп килүчеләрнең матди хәле авыр булу сәбәпле ата кеше улын интернатка бирә. Шулай итеп ун яшьлек Җәүдәт Ташкенттагы балалар йортларының берсендә тәрбияләнүчегә әверелә, һәм анда язмыш ихтыяры белән үзенең сәләтенә тәңгәл профессиясен таба. Малайның музыкаль сәләтен абайлап, аны шунда ук балалар йорты каршында оештырылган тынлы уен кораллары оркестрына билгелиләр. Уңыш озак көттерми. 12 яшендә инде Айдаров Ташкент артиллерия полкы музыкаль взводына килеп эләгә, хәрби маневрларның

берсе вакытында атаклы полководецлар С.М. Буденный белән О.И. Городовиков каршында кавалерия сигналларын уйнауда катнаша. Әмма очраклы рәвештә җәрәхәтләнүе сәбәпле (су коенганда иренен ерттыра), аңа трубасын һәм башка тынлы уен коралларын бәрмә инструментка алыштырырга туры килә.

Үзенең укытучысы һәм остазы Анатолий Тольский ярдәме белән Айдаров Ташкентта яңа гына ачылган Опера һәм балет театры оркестрында эшли башлый. Бер елдан ул оркестрант буларак Горький һәм Киев театрларында заманының күренекле дирижерлары җитәкчелегендә чыгышлар ясый. Музыкантның осталыгы арта, һәм аның 1937 елда Ленинградтагы Киров исем. (хәзер Мария) театрында уйный башлавы да (конкурсны уңышлы узып) очраклы түгел. Ә аннан бер ел элек ул М.П. Мусоргский исемендәге музыкаль көллияттә (А.И. Чулюкинның бәрмә инструментлар классында) белем ала башлаган була.

Җәүдәт Айдаровның Ленинградтагы беренче айлары катлаулы була. Алар хакында ул болай дип яза:

«Когда я поступил в музыкальное училище, мне сказали, что общежития нет. Около двух недель я ночевал на вокзале, однажды уснул прямо на занятиях. Мой педагог спрашивает: „А ты, случайно, не выпил?” Я, чуть не плача, рассказал ему, что учиться страшно хочется, но, наверное, придется бросить, потому что больше не выдержу. Через несколько дней меня поселили в общежитие, где жили композиторы. Рядом со мной – Георгий Свиридов, много других интересных музыкантов. Часто к моим новым знакомым приходил Шостакович. Это был необычайно скромный человек, мне все время казалось, что, говоря, он боится обидеть собеседника. Выглядел он очень моложаво» [Мамаева].

Җ.К. Айдаров күренекле замандашлары арасына әнә шулай килеп эләгә.

Бөек Ватан сугышы башланганда Җ.К. Айдаров Ленинград хәрби округының Үрнәк оркестрында армия хезмәтен үти, ул анда гади музыкант була. Камалышта калган Ленинград халкы белән бергә ул да шәһәрне саклап калуда катнаша: ныгытмалар төзелешендә эшли, һава һөҗүменә каршы оештырылган командада экспедитор вазифасын башкара. Аның 1941 елның 16 июлендә әнисенә язган хатында мондый юллар бар: «После объявления войны работаем как комендантская команда. Насчет отправки на фронт ничего не слышно пока». Бу тема шулай ачык хәлдә кала – аны алгы сызыкка җибәрмиләр, ул «музыкаль фронт сугышчысы» бурычын үтәвен дәвам итә.

1942 елның язында Җ. Айдаров тормышында истәлекле вакыйга була. Радиодан К.И. Элиасберг җитәкчелегендә Д.Д. Шостаковичның Җиденче симфониясе премьерасы әзерләүне һәм аның өчен оркестрга музыкантлар чакырылуын хәбәр итәләр. Җ.К. Айдаров та, хәрби оркестрдагы хезмәттәшләре В.М. Орловский (тромбончы),

П.К. Орехов (валторначы) һәм Г.З. Еремкин (фаготчы) белән бергә, командировка кәгазе алып, «Радиокомитет башлыгы карамагына» күчәләр[2].

Симфония премьерасына әзерлекнең катлаулы этабы башлана. Җ.К. Айдаров аның хакында болай дип исенә төшерә: «Собранные с фронта молодые музыканты и ветераны, еще помнящие оркестровую яму императорской оперы, приступили к долгим репетициям, в которые вкрапливались борьба с „зажигалками", голодные обмороки и смерть. Пунктуальный Элиасберг (его истощенного иногда приводили на сцену под руки) не делал никаких скидок» [Айдаров, 1992].

«Блестящий знаток оркестра, Карл Ильич требовал от музыкантов безупречного строя, четкого, как метроном, ритма, гармонично сбалансированного звучания. Ради этого он до седьмого пота работал сам и заставлял продуктивно работать музыкантов. Причем делал это не как диктатор, выжимающий из исполнителя все, что считал необходимым, а именно убеждал в своей интерпретации той или иной фразы. Первоклассные музыканты, знавшие назубок многие симфонии и после нескольких повторов ворчавшие себе под нос что-то о педантичности, о невозможности другого прочтения „злополучного" фрагмента, в душе все-таки соглашались с Карлом Ильичем. Тогда-то и наступало то слияние оркестра с дирижером, о котором сейчас мечтают многие» [Макаров].

«Первые репетиции были короткими: мы играли по 20–30 минут – не более, часто прерывались из-за бомбежек и обстрелов, но постепенно вошли в работу. Как будто сама музыка придавала нам силы. Я был самым молодым среди музыкантов-ударников, мне поручили соло на барабане. Тот самый страшный ритм, на фоне которого звучит так называемая тема фашистского нашествия»[3].

«У меня от волнения дрожали руки. Палочки опускались на кожу барабана невпопад. Элиасберг снова и снова просил повторить каждую фразу» [Надеинский].

«Истощенный физически, он оставался непреклонен и крепок духом, неистов в своей любви к музыке, был отличным организатором музыкантов. [...] Железной дисциплине и суровой требовательности дирижера обязана значительной доле своего успеха грандиозная работа над Седьмой симфонией»[4].

Җ.К. Айдаров үзен үлемнән коткарып калган күренекле дирижер каршында бик нык дулкынлана. Ул чактагы вакыйга музыкант өчен блокада чорындагы хәтеренә иң нык сеңгән, иң фаҗигале мизгелләрнең берсе булып тора.

«Во время одной репетиции, я голодный, обессиленный, упал в обморок. Очевидно, меня приняли умершим и отнесли в соседнюю со студией комнату (туда относили умерших)»[5].

«Элиасбергу сообщили, что я умер, и он зашел в комнату, где я лежал без признаков жизни.

Вдруг чуткое ухо дирижера уловило еще слышный звук дыхания „Да ведь он жив! – воскликнул Карл Ильич. – Слышите, – он дышит!"» [Крюков, с. 43].

Яшь музыкантны сафка (стройга) кайтаралар. Өстәмә бер телем икмәк аңа көч өсти. Ул оркестрантлар арасында кала...

* * *

1942 елның 9 августында Д.Д. Шостаковичның Җиденче симфониясен башкаруда катнашуы һәм Ленинград блокадасы көннәре турында Җ.К. Айдаровның кульъязма хатирәләре берничә ел элек басылып чыга [Айдаров, 2012]. Югарыда китерелгән өзекләр дә шунда кергән. Аның истәлекләре сугыш чорының һәм үз биографиясендәге һәр аерым мөһим вакыйганың автор күңелендә һичкайчан онытылмавын дәлилли. Инде олыгаеп барган, Идел буенда зур танылу яулаган музыкантның һәм педагогның[6] моннан 40 ел элек язган истәлекләре киң катлау укучыларга, тыңлаучыларга, барыннан да бигрәк, яшьләргә юлланган.

Җәүдәт Айдаровның Ленинград камалышы көннәрендә әти-әнисенә язган хатлары бөтенләй башкача кабул ителә[7]. Аларда сүз яшь кешенең язмыш ихтыяры белән камалышта калган шәһәрдәге коточкыч шартларга дучар ителүе хакында. Бер үк вакытта шул дәвердәге тарихи кызыксыну уятырдай вакыйганың ачык шаһите дә ул хатлар.

Хатларның төп темасы – ачлык. Аларны укыганда шундый тәэсир туа, әйтерсең башка бөтен проблемалар да арткы планда калган. Һәм бу очраклы гына түгел: чынбарлыкны кабул итү акценты алышына. Туры мәгънәсендә әйткәндә, яшәү өчен аеруча мөһим мәсьәләләр җанга көчлерәк тәэсир итә. Музыкант та үзенең оркестрдагы эшчәнлеге турында сүз барышлый гына әйтеп уза. Җ.К. Айдаровның, блокададагы коточкыч хәлләр турында язып, әти-әнисен борчыйсы килми. Барлык хатларында да диярлек «все в порядке», «жив и здоров» фразалары кабатлана, ә бит чынлыкта хәлләр чиктән тыш авыр була. Ә хатларда тынычландыра торган сүзләр генә, шәһәр тормышында гомуми мәгълүматлар гына әйтелә, чөнки корреспонденцияләр хәрби цензура аша уза (барлык хатларны да аның мөһере «бизи»). Шулай да 1942 елның 15 маенда язылган хатта чынбарлыкны чагылдырган җөмлә дә сакланып кала: «В Ленинграде идет почти нормальная жизнь, ходят трамваи, работают радио, телефоны. Вчера и сегодня был большой артиллерийский обстрел города». Куркыныч вакыйгалар гадәти хәлгә әйләнә. Аларның күбесе хакында музыкант сугыш тәмамланганнан соң гына сөйли...

Җ.К. Айдаровның биредә китерелгән хатларында[8] аның үзенең стиле саклана, юл һәм баш хәрефләрнең бирелеше генә хәзерге кагыйдәләргә туры китерелде. Кыскартылган сүзләр тулыландырылды, аерым сүзләрдәге хаталар һәм тыныш билгеләре махсус рәвештә төзәтелмәде.

### 1. Ж.К. АЙДАРОВ – Л.Д.ДИНМӨХӘММӘТОВАГА

16 июль, 1941 ел

«Дорогая Мама!

Я тебе послал письмо, но до сих пор нет ответа. Не знаю почему, может быть транспорт плохо работает. Сегодня получил от Брата письмо, чему я очень обрадовался. Давно от него не было писем.

Сам я пока жив и здоров. После объявления войны работаем как комендантская команда. Насчет отправки на фронт ничего не слышно пока.

Как сама живешь, как здоровье? Пиши почаще письма. От отца тоже давно не получал письма, вообще в такое время хочется больше писем от родных, а то как то скучно и вообще чувствуешь себя оторванным. Ну мамочка писать больше нечего. Жду от тебя писем.

Крепко, крепко тебя целую
твой сын *Ж. К. Айдаров.*
16.7.41 года.»

### 2. Ж.К. АЙДАРОВ – Л.Д. ДИНМӨХӘММӘТОВАГА

11 декабрь, 1941 ел

«Привет из Ленинграда

Здравствуй дорогая моя мама! Как твоя жизнь и твое здоровье. Я пока жив и здоров. Твой перевод в 40 рублей получил, за что большое спасибо, ибо я расплатился с долгами. Брату написал еще два письма, а ответ увы уже как пятый месяц жду, все нет и нет.

Мама. Я тебя еще попрошу выслать мне денег, мне нужно выкупить фотокарточки, которые я тебе могу послать. Деньги ужасно быстро расходуются. Ничего мама, я расплачусь после войны, если буду жив и здоров. Пока что получаю 10 рублей, которые уходят в фонд обороны. Твое письмо получил, которое шло ровно два месяца и шесть дней. Мама пиши как теперь в Ташкенте жизнь. Не очень дорогая и все ли есть. Мама если будут принимать посылки, то пришли побольше сухарей, хоть черных и масла или сала посоли, чтоб они дорогой не испортились.

Пока писать особенного нечего, желаю тебе здоровья. Крепко-крепко тебя целую твой сын
Ж.К. Айдаров
11 /XII 41 года.»

### 3. Ж.К. АЙДАРОВ – Л.Д. ДИНМӨХӘММӘТОВАГА

17 гыйнвар, 1942 ел

«Дорогая Мама!

От тебя недавно получил письмо, на которое уже ответил. Как жива и здорова дорогая мама, как с работой и я очень был рад прочитав твое письмо в котором ты пишешь что твое здоровье лучше. Для меня это очень и очень обрадовало. Я сам пока жив и здоров. В каком положении находится Ленинград ты наверно знаешь из газет. Ну Мамочка до свидания, крепко-крепко тебя целую и обнимаю твой сын Ж. Айдаров

17.I.42 года.»

### 4. Ж.К. АЙДАРОВ – Л.Д. ДИНМӨХӘММӘТОВАГА

31 гыйнвар, 1942 ел

«Привет из Ленинграда!

Дорогая Мама!

Письмо твое получил, за что большое спасибо. Когда от

тебя получаешь письмо у меня на душе целый праздник. Я пока жив и здоров, надеюсь что и ты также. Я очень был обеспокоен, когда узнал что в Ташкенте очень все дорого, хлеб выдается по карточкам. Это верно или нет, и как ты живешь, это уже не 33-й год*. Мама пиши только всю правду как твое здоровье и как протекает твоя жизнь. Одновременно в один и то же день письмо получил и от отца. От брата не получал. Ну ладно писать пока больше нечего, крепко-крепко тебя целую твой сын:

Ж.К. Айдаров

31/142 года, город Ленинград»

* 1932–33 елларда бөтен илне колачлаган ачлыктан кырылу фаҗигасе искә алына.

## 5. Җ.К. АЙДАРОВ – Л.Д. ДИНМӨХӘММӘТОВАГА

1 февраль, 1942 ел

«Привет из Ленинграда
Дорогая Мама!

Согласно моему решению, я тебе почти каждый день пишу письмо или открытку, чтоб ты обо мне не беспокоилась. Вчера тебе послал открытку. Мама пиши, как ты, получаешь мои письма или нет и через сколько времени они до тебя доходят. Я пока сам жив и здоров. Дорогая Мама береги свое здоровье. Пиши какая жизнь в Ташкенте на сегодняшний день. Я слышал, что все продукты питания стали очень дорогие. Это правда или нет. Как работаешь, устаешь или нет. От брата до сих пор, кроме одного письма во время войны не получал. Если ты от него получаешь часто, пиши что он пишет. Недавно получил письмо от отца. [...]

Ну, мамочка писать больше пока нечего, пиши как здоровье, как жизнь. Крепко, крепко тебя целую. Твой сын: Ж. К. Айдаров

1/II 41 года. Город Ленинград»

## 6. Җ.К. АЙДАРОВ – Л.Д. ДИНМӨХӘММӘТОВАГА

5 февраль, 1942 ел

«Привет из Ленинграда
Дорогая Мама!

Как твое здоровье и жизнь дорогая. Я сам пока жив и здоров и надеюсь что и ты также здорова.

Недавно получил от тебя письмо, на которое сразу же отправил ответ. Отцу пишу регулярно, почти через день как и тебе. Мама пиши письма чаще и длиннее, пиши обо всем. Как ты живешь, как с работой, какая жизнь в Ташкенте. От брата нет писем, это я тебе пишу в каждом письме.

Что с ним такое, я же от него всегда письма получал регулярно, может быть он больной или с ним еще что-нибудь случилось. В крайнем случае, если он тебе пишет регулярно, напиши, как он живет и где он теперь находится. Напиши мне его адрес самый последний.

Мама береги свое здоровье, здоровье это теперь все. Как только заболеешь чуть-чуть, надо обратиться к доктору и себя не переутомлять работой. Как мама я по тебе соскучился и как хочется видеть тебя, если бы я увидел тебя и поцеловал, я бы был самый счастливый человек на Земле.

Я теперь убедился, что мать – это самое близкое и самое родное существо у человека, и тот самый счастливый человек, который

имеет мать, не считая какая она не есть.

Пока мамочка писать больше нечего, ожидаю письма от тебя. Крепко-крепко тебя целую.

Твой сын: Ж. К. Айдаров

5/11 42 года. Город Ленинград.

Передай привет тем, кого я знаю».

## 7. Җ.К. АЙДАРОВ – К.Ә. АЙДАРОВКА

5 февраль,1942 ел

«Привет из Ленинграда

Дорогой Отец!

Недавно тебе отправил письмо, как только получил от тебя. Папа пиши письма чаще, так как когда получаешь из дома письма, не так чувствуешь себя оторванным от семьи, и когда получаешь письма, то на душе становится праздничное настроение.

Как дорогой папа твое здоровье, как твоя жизнь. Береги свое здоровье, здоровье это все. Я пока сам жив и здоров, но чувствую себя утомленным ввиду некоторого недоедания и недостатка жиров, то есть ввиду блокады Ленинграда. Ты сам, наверное, ежедневно читаешь газеты и слушаешь сообщения совинформбюро. Матери пишу регулярно почти через день как и тебе. Только жаль, что от брата не получаю писем, это я уже пишу тебе в каждом письме. Папуля пиши какая жизнь в Самарканде, какая погода и какой был урожай фруктов в прошлом году. Этим интересуется один лейтенант, он в Самарканд эвакуировал семью и до сих пор не имеет известий от них.

Ну пока писать пока нечего, ожидаю много писем от тебя. Крепко, крепко тебя целую и обнимаю

Твой сын Ж. К. Айдаров

5/II 42 года. Город Ленинград 11.

почтовый ящик 604а

Образцовый Оркестр

Ленинградского Военного Округа

Красноармейцу Ж. К. Айдарову»

## 8. Җ.К. АЙДАРОВ – Л.Д. ДИНМӨХӘММӘТОВАГА

11 февраль, 1942 ел

«Привет из Ленинграда

Дорогая, милая Мама!

Чего-то нет от тебя писем в эти дни, уже не больна ли ты. От отца вчера получил письмо от 15/X 41 года. Удивительно долго шло письмо. От брата писем до сих пор увы все нет и нет, ну да ладно если будем, будем живы и здоровы мы с ним увидимся и поговорим.

Сегодня у нас радостный день, почти праздник! Сегодня прибавили хлеба двести граммов итого мы теперь получаем шестьсот грамм*. Я просто хотел поделиться моей радостью с тобой. Сегодня позавтракал с двумястами граммами хлеба, набил полный рот хлеба и ощущал, что я ем хлеб. Я сам пока жив и здоров.

Мамочка пиши как твое здоровье, какая жизнь в Ташкенте, много ли эвакуированных в городе. В Ленинграде жизнь налаживается, к первому марта, думаю, что Ленинград будут обеспечивать продовольствием вполне нормально. Ну ладно, перемелется все, мука будет.

Ну, мамочка писать больше нечего, и не стану тебя затруднять

читкой моих длинных писем. Мамочка пиши больше и чаще. Крепко, крепко тебя целую. Твой сын Ж. К. Айдаров

11 /II 42 год. Город Ленинград

Передай привет всем моим знакомым, кого я знаю.

Пиши, много ли было фруктов в прошлом году в Ташкенте».

*Ленинградлыларны азык-төлек белән тәэмин итүдәге үзгәрешләр турында А.В. Буров болай дип белдерә: «11 февраля, среда. Сегодня всеобщая радость: объявлена третья прибавка хлеба! Рабочие и инженерно-технические работники получают теперь по 500 граммов хлеба в день (рабочие горячих цехов – даже по 700), служащие – по 400, дети и иждивенцы – по 300. Кроме того, с этого дня для всех питающихся в столовой введен так называемый льготный пятидесятипроцентный зачет по крупе. Проще говоря, рабочие будут получать в месяц дополнительно по два килограмма крупы, служащие – по полтора, дети – по кило двести, иждивенцы – по килограмму. В условиях Ленинграда прибавка весьма существенная» [Буров, с. 140].

## 9. Җ.К. АЙДАРОВ – К.Ә. АЙДАРОВКА

17 февраль? 1942 ел

«Привет из Ленинграда

Дорогой отец!

Недавно, то есть недели две тому назад от тебя получил письмо, на которое уже давно написал ответ. Но в эти дни ни от тебя ни от матери нет писем, не говоря уже о брате. Я сам пока жив и здоров, себя начал чувствовать немножко лучше, но некоторая слабость организма еще осталась, тяжело с ногами, очень трудно ходить и ноги быстро устают, это конечно от недостатка жиров в организме. Надеемся на лучшее, когда будут выдавать больше жиров. Теперь я убедился, что никакой роскоши для Человека не нужно, что самое ценное это питание. Теперь если буду я жив и здоров, и жизнь будет такой же хорошей, как до войны, то буду все свои деньги, все-все-все тратить на питание. Строю такие кулинарные планы, какая моя крупа больше разваривается, с какой крупы каша делается больше и какая более выгодная. Ты конечно не смейся, может быть если бы ты был на моем месте, то рассуждал бы точно также как я теперь. Папа! Как у вас в Самарканде дела с папиросами, у нас в Ленинграде на базаре только можно достать, и то по 75.80 рублей за пачку спекулянтов. В столовых гостям пока папирос не выдают, так что мы ходим и у друг друга клянчим.

В общем, жизнь в Ленинграде налаживается и делается все лучше и лучше.

Напиши, как живешь, как работаешь, как здоровье и семья.

Ныть и писать больше нечего. Крепко-крепко тебя целую. Остаюсь твой сын

Ж. К. Айдаров

17/ II 42 года. Город Ленинград».

## 10. Җ.К. АЙДАРОВ – Л.Д. ДИНМӨХӘММӘТОВАГА

16 апрель, 1942 ел

«Привет из Ленинграда

Дорогая Мама!

Недавно получил от тебя два письма, на которые до сих пор не успел дать ответ. Ты спрашивала, дошли ли до меня все переводы,

высланные тобою мне. Я это писал в предыдущем письме. Я получил три перевода по сто рублей. Они, конечно, пока мне не нужны, так как в Ленинграде на деньги пока ничего не купишь, в дальнейшем может быть. Я пока жив и здоров. От отца почему-то нет писем. [...]

Мама пиши, как живешь, как здоровье. Пиши насчет брата, ведь с самого начала войны я от него ничего не имею и вышли его письма, которые написаны по-русски.

Ну, мамочка! Пока писать особенного ничего нет. Желаю тебе сил, здоровье и лечиться.

Крепко, крепко тебя целую
твой сын Ж. К. Айдаров
16/IV 42 год. Город Ленинград».

### 11. Җ.К. АЙДАРОВ – К.Ә. АЙДАРОВКА

7 май, 1942 ел

«Привет из Ленинграда
Дорогой отец!

Вот уже как два месяца я от тебя не имею писем. Я пока жив и здоров, чувствую себя хорошо. Надеюсь, что ты также здоров и чувствуешь себя хорошо. От брата все по старому, нет писем, может быть, про него ты знаешь лучше. Напиши, где он теперь находится.

Праздничные дни в Ленинграде для меня прошли почти незаметно, даже праздничного настроения не было. Не знаю, почему это так, возможно, что это может и от погоды, хотя погода 1-го числа была изумительной, был солнечный теплый день, хотя вчера, то есть 6-го мая опять шел снег и сегодня чертовски холодно, или это меня кровь не греет, или это осадок голодной блокады. Как хочется теперь быть где-нибудь на юге, где тепло. Если буду жив и здоров, то после войны ни за что не буду жить в Ленинграде. Такого паршивого климата наверно нигде и не встретишь. Я по-старому нахожусь все на старом месте, но будучи музыкантом очень мало приходится заниматься по своей специальности. Работаю все время экспедитором.

Сейчас как пошли трамваи стало легче для ног: ни так уж устаешь и меньше приходится ходить. Зато летом будет хорошо тепло. Многие из моих товарищей по консерватории и музыкальному училищу находятся на фронте, то есть на передовых позициях, и многие из них кто убит кто ранен.

Еще прошлой зимой подавал докладные, чтоб отправили на передовые позиции и до сих пор не отправляют. Как то досадно, что все товарищи находились на фронте, а ты отсиживался в тылу, хотя Ленинград по существу по настоящее время можно назвать фронтом.

Ну, папа много писать не буду, пиши сам побольше. Как живешь, как здоровье и какая жизнь в Самарканде.

Крепко, крепко тебя целую твой
сын Ж. К. Айдаров
7/V 42 года. Город Ленинград»

### 12. Җ.К. АЙДАРОВ – Л.Д. ДИНМӨХӘММӘТОВАГА

15 май, 1942 ел

«Привет из Ленинграда
Дорогая Мама!

Твои два письма от 2.4.42 года и 3.4.42 года получил, чем был несказанно рад. Я пока жив и здоров, но в эти дни чувствую некоторую усталость, особенно устают

ноги, наверное, следствие нехватки жиров.

Но ничего, скорее бы кончилась война; тогда я бы приехал к тебе и мы вместе копали огород и сажали овощи, в общем, наготовили бы столько продовольствия на зиму, что нам бы хватило до следующего урожая овощей. Купили бы рису, круп разных. Ты бы варила плов. О как хочется попробовать плов, разные каши, я бы работал, в общем, голодные не сидели. Но, кажется, я размечтался о дальнейшей жизни, надо выйти из войны живым и невредимым, тогда все остальное будет, было бы здоровье и силы. Тогда и работа нипочем.

Удивительно, что от отца долго нет писем. Что такое с ним. В Ленинграде идет почти нормальная жизнь, ходят трамваи, работают радио, телефоны. Вчера и сегодня был большой артиллерийский обстрел города. В Ленинград приехала узбекская делегация*, хотел с ними повидаться, но не успел, они выехали на передовые позиции, хотел с ними тебе отправить письма и фотокарточки. Карточки шлю почти в каждом письме, это те в которых снимался до войны. Мама пиши как живешь, какая обстановка и жизнь Ташкента, как дела обстоят с продовольствием. Мама храни себя, не утомляйся особенно на своем огороде, если будет возможность, найми кого-нибудь копать огород. И еще одна последняя просьба, вышли самый последний твой фотоснимок, ведь я тебя не видел около четырех лет. И если бы ты знала как я по тебе соскучился, и как хочется увидеть тебя, Ну ладно, хватит особенно много писать. Все равно, что ты чувствуешь и еще хочешь сказать, всего на бумаге не напишешь. Ну, мамочка, будь здорова, храни себя.

Крепко, крепко тебя целую
твой сын Ж. К. Айдаров
15/V 42 года
Город Ленинград»

* 1942 елның 10 маенда камалыштагы шәһәргә Үзбәкстаннан азык-төлек эшелонын озата килгән делегация искә алына. Җ.К. Айдаров, хатыннан аңлашылганча, бу хакта якыннарына язып өлгерә алмаган, фотографияләрен дә җибәрмәгән. 13 майда делегатлар Колпино белән Красный Бор арасында сугышлар алып баручы 125 укчы дивизиянең хәрби позициясенә чыгалар [Буров, с. 184].

## 13. Җ.К. АЙДАРОВ – К.Ә. АЙДАРОВКА

27 апрель, 1942 ел

«Привет из Ленинграда
Дорогой Отец!

Поздравляю с наступающим праздником первого мая. Может быть, это письмо дойдет как раз к этому сроку. Я пока жив и здоров, чувствую себя неплохо.

В Ленинграде с 15-го апреля заходили трамваи, пока еще не все маршруты, но все же они охватывают всю центральную часть города*. После длительного перерыва трамвайного движения когда я услышал визг трамвайных колес, охватило радостное чувство, и показалось что город проснулся после долгого сна. Ленинград приводится в порядок, везде наводят чистоту в домах, во дворах и на улицах и площадях.

Недавно получил от матери два письма, на которые весьма

обрадовался. Приходится констатировать факт, что она пишет больше и чаще чем ты.

От брата конечно не получаю писем. Папа, если тебе он прислал с самым последним и точным адресом, то пришли его мне и его письма.

Пока пиши, как ты живешь, как здоровье, какая жизнь в Самарканде. Больше особенного писать нечего, крепко тебя целую твой сын

Ж. К. Айдаров
27/V»

* 15 апрельдә ленинградлылар өчен сөенечле вакыйга була. 4 айга сузылган өзеклектән соң шәһәрдә биш маршрут (№№ 3, 7, 9, 10, 12) буенча трамвайлар хәрәкәте торгызыла [Линд, с. 67].

## 14. Җ.К. АЙДАРОВ – К.Ә. АЙДАРОВУ

29 июль, 1942 ел

«Привет из Ленинграда
Дорогой Отец!

Вчера письмо твое получил очень коротенькое. Узнав, что ты болен желудком, очень огорчился. Я сам знаю, что такое желудочная болезнь. Я пока жив и здоров, чувствую себя хорошо.

От матери вот уже около месяца не получаю писем. От брата тем более. Дорогой отец! Если ты знаешь про него что-нибудь, напиши, пожалуйста, его судьба меня очень беспокоит.

Ну пока всего хорошего, желаю скорее поправится от болезни. Крепко целую твой сын Ж. Айдаров

город Ленинград
29/VII 42 года».

## 15. Җ.К. АЙДАРОВ – Л.Д. ДИНМӨХӘММӘТОВАГА

8 сентябрь, 1942 ел

«Дорогая Мама!

Давно от тебя не получаю письма. Я пока жив и здоров. Очень беспокоюсь за тебя. Многим моим товарищам пишут из Ташкента, куда их родственники эвакуированы, что все там дорого. И поэтому мне кажется, что у тебя не такая блестящая жизнь в Ташкенте. Мама, пиши, как живешь и как твое материальное положение, как вас снабжают продуктами питания. Очень хочется видеть тебя. Как кончится война, сразу приеду в Ташкент к тебе, если, конечно, буду живи здоров. От отца тоже также как и от тебя нет писем. От брата также нет писем, что меня и огорчает. Ну, пока всего хорошего. Писать об особенно радостном пока нечего. Ну, будь здорова. Береги себя. Крепко целую. Твой сын.

Жавдет
8.9.42 года. Город Ленинград»

## 16. Җ.К. АЙДАРОВ – Л.Д. ДИНМӨХӘММӘТОВАГА

18 май, 1943 ел

«Привет из Ленинграда
Дорогая мама!

Сейчас 12 часов 15 минут ночи. Объявили воздушную тревогу*.

Решил, пока есть время во время тревоги, написать тебе письмо. Зенитные батареи открыли такой ураганный огонь из батарей, как будто налетели тысячи неприятельских самолетов. Огонь батарей утих, но отбоя тревоги нет. Я пока жив и здоров. Жизнь моя пока идет все по старому, без изменений.

Вчера тебе отправил письмо вместе с открытками. От тебя получил сразу два письма, от 2-го и 3-го апреля, что было для меня большим праздником. Мама пиши чаще и больше. Сама знаешь, что у меня кроме тебя нет никого на свете, который мог бы побеспокоиться обо мне. Так что мама, твои письма для меня большой праздник и утешение.

Ну, мамочка будь здорова.

Сейчас по радио объявили отбой воздушной тревоги.

Крепко, крепко тебя целую.
Твой любящий сын Ж.К. Айдаров
18/V 43 года.

Город Ленинград. 2 часа ночи.

Иду спать, подъем в шесть утра».

*1943 елның 18 маеннан 19 ына каршы төндә Ленинград шәһәре берничә мәртәбә артиллерия утына һәм һөҗүмгә дучар ителә. А.В. Буров бу хакта үзенең хроникасына түбәндәгеләрне терки: «19 мая, среда. Сегодня фашистская дальнобойная артиллерия начала обстрел города на рассвете, в 4 часа 55 минут. Все снаряды разорвались за Невской заставой» [Буров, с. 351].

## 17. Җ.К. АЙДАРОВ – Л.Д. ДИНМӨХӘММӘТОВАГА

Гыйнвар, 1944 ел

«Привет из Ленинграда
Дорогая Мама!

Спешу написать тебе радость всех Ленинградцев с их освобождением от вражеской блокады, в которой Ленинград находился 15 месяцев. Когда сообщили о прорыве блокады, то не было конца ликованию Ленинградцев. Люди плакали от радости, целовали друг друга.

Я сам пока жив и здоров, работаю все еще на новом месте, то есть на радио.

Мама! Письма пиши по старому адресу.

Все равно если напишешь на почтовый ящик 604а или в военную часть 898, они все равно дойдут. Мамочка, пиши как твое здоровье и как ты живешь. Справку тебе я выслал. Думаю что ты уже ее получила. Письма тебе все время пишу, но только не знаю почему ты не получаешь их. Мамочка напиши какая жизнь в Ташкенте.

Ну мамочка будь здорова.

Извини что так плохо написал, очень торопился. Писал на репетиции. Подробно напишу следующим письмом.

Крепко тебя целую твой Жавдет

Передай привет всем моим знакомым.

До свидания Дорогая Мамочка»*.

* Бу хат 1944 елның 27 гыйнварында, Ленинград дошман камалышыннан азат ителгән көнне язылган булса кирәк. Шушы уңай белән К.И. Элиасберг җитәкчелегендә оркестрның концерт бирүе, аның радио аша трансляцияләнүе хакында мәгълүматлар сакланган. А.Н. Крюков болай дип яза: «Вечером ленинградцы услышали долгожданную, выстраданную весть: город полностью освобожден от блокадного кольца. Прогремели залпы праздничного салюта. К. Элиасберг, сказав краткое приветственное слово, провел праздничный концерт. В первом отделении прозвучала увертюра „1812 год" Чайковского. Во втором – увертюры к «Руслану и Людмиле» Глинки, к «Кармен» Бизе, танцы из балетов и опер Чайковского, «Малагуэнья» Мошковского, «Сказки Венского леса» Штрауса. В. Легков спел куплеты тореадора, Г. Скопа-Ро-

дионова – «Весенние голоса» Штрауса, И. Нечаев (в сопровождении фортепиано) – песенку Герцога из «Риголетто» Верди и арию певца из оперы Аренского „Рафаэль”. Ряд пьес был дан в записи (Торжественная увертюра Глазунова, «Славься» Глинки и другие). Концерт закончился поздним вечером, вернее, ночью. Радуясь и плача, город вступал в новый, свободный, но все же военный день» [Ковальчук, с. 495].

**Искәрмәләр**

[1] Җ.К. Айдаровның 1982 елның 11 гыйнварында сөйләгән чыгышыннан. Биредә китерелгән һәм алда биреләчәк материаллар Айдаровлар гаиләсенең шәхси архивында саклана.

[2] Җ.К. Айдаров Радиокомитет оркестры штатына рәсми рәвештә 1943 елда гына күчерелә.

[3] Радиотапшыруларның Җ.К. Айдаровка багышланган стенограмма текстыннан. 1987 елның 17 июне белән даталанган, машинкада басылган.

[4] Җ.К. Айдаровның 1982 ел, 11 гыйнварда ясаган чыгышыннан.

[5] Җ.К. Айдаровның 1982 ел, 11 гыйнварда ясаган чыгышыннан.

[6] Җ.К. Айдаров 1951 елда Ленинград консерваториясенең (А.В. Михайлов классында) дирижер-хор бүлеген тәмамлый, Чита радиокомитетында халык уен кораллары оркестры дирижеры (1951–1952), Ижор заводы Эшчеләр хор капелласының художество җитәкчесе (1954–1958), Карелия «Кантеле» ансамбле хормейстеры һәм Мәскәүдә уздырылган Карелия сәнгате декадасы вакытында баш хормейстер (1958–1958), Татарстан Республикасы җыр-бию ансамленең художство җитәкчесе (1959–1965), Казан консерваториясе халык уен кораллары кафедрасы доценты (1965–1975), Казан консерваториясе каршындагы махсус музыкаль мәктәп директоры (1969–1973), Казан музыкаль көллияте укытучысы (1975–1998) була.

[7] Җ.К. Айдаровның шәхси архивында аның этисе – Кәрәмәтулла Айдаров (1879–1949) белән әнисе – Латифа Айдарова-Динмөхәммәтовага (1898–1980) фәкать блокададан язган хатлары гына сакланган.

[8] Хатлардан китерелгән өзекләр «Человек из оркестра. Блокадный дневник Льва Маргулиса» дигән китаптан алынды [Человек из оркестра, с. 158–161].

**Әдәбият**

*Айдаров Н.* Служение музыке: страницы воспоминаний Ж.К. Айдарова // Musicus. 2012. № 1 (29). С. 42–48.

*Айдаров Д.* «Ленинградская» – навсегда останется симфонией подвига // Вечерняя Казань. 1992. № 176 (436). 18 декабря.

*Буров А. В.* Блокада день за днем. Л.: Лениздат, 1979. 480 с.

*Ковальчук В.М.* 900 дней блокады. Ленинград 1941–1944. СПб.: Дмитрий Буланин, 2005. 234 с.

*Крюков А.Н.* Музыка в дни блокады: хроника. СПб.: Композитор, 2002. 542 с.

*Линд Е.* Седьмая... СПб.: Гуманистика, 2005. 240 с.

*Макаров Е.* Объединяла не только музыка // Вечерняя Казань. 1988. № 299. 30 декабря.

*Мамаева Т.* День победы среди войны // Известия Татарстана. 1992. № 187 (204). 26 сентября.

*Надеинский Е.* Симфония подвига // Красная звезда. 1982. 30 января.

Человек из оркестра. Блокадный дневник Льва Маргулиса / ред. Н.Е. Соколовская; комм. А.Н. Крюкова и А.С. Романова. СПб.: Лениздат, 2013. 320 с.

***Айдаров Нәдим Җәүдәт улы,***
***Россия** сәнгать тарихы институты фәнни хезмәткәре*
*e-mail: n.aidarov@yandex.ru*

УДК 929

*Габдрахман Сәгъди*

# ЗУР ӘДИПЛӘРЕБЕЗДӘН БЕРСЕ
## (анын 20 еллык хезмәте уңае белән)

Статья известного ученого-литературоведа Габдрахмана Сагди (1889–1956) была написана к 20-летию литературной и научной деятельности писателя Г. Ибрагимова, где кратко исследуется основные направления его творчества, вклад в развитие татарской культуры. Статья была опубликована 25 октября 1927 года в газете «Кызыл Татарстан», № 245.

**Ключевые слова**: Г. Ибрагимов, творчество, литература, литературная критика, грамматика татарского языка.

Зур көчләр озак заман танылалалар. Аларның зурлыклары да шул үзләренең озак заманга сузыла алуларында була.

Бу турыда дөньяның әдәбият һәм фән тарихы безгә күп фактлар бирә.

Татарда да үз үлчәвендә, үз мәдәни мөмкинлеге эчендә мондый көчләр юк түгел.

Шундый зур әдәби талантларыбызның берсе Галимҗан Ибраһимов булып, шушы елның октябрендә аның беренче әдәби иҗат адымын башлавына егерме ел тулды. Татарда яшь фикернең иске фикергә каршы көрәшен тасвир иткән: «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» («Әлислах», сан 2, 1907 ел, 10 октябрь) дигән әсәре аның әнә шул адымы иде.

Авыр шартлар, күп иҗтимагый тартышлар, көрәшләр эчендә армый-талмый төн-көн өзлексез эшләп килүче, шуның белән бергә, заманында үз өстенә гаять мәсъүлиятле зур тарихи эшләр йөкләп баручы бер эшче – әдәбият һәм мәдәният эшчесе өчен егерме ел аз бер заман түгел.

Галимҗан Ибраһимов, 1907 елдан кулына каләм алган сәгатеннән башлап, армады, талмады; көн эшләде, төн эшләде; гыйльми һәм әдәби күп иҗатлар бирде. Ләкин ул татарның эшче-крестьян гаммәсе өчен 20 ел буенча иҗтимагый-мәдәни, гыйльми, әдәби әллә никадәр зур хезмәтләр юлында чиксез зур көчләр түккәне хәлдә, аның фикере, рухи куәте югалмады, кимемәде, йомшамады, бәлки бу як анда артканнан-арта, көчәя барды. Энергия анда һаман тулып таша торды.

Ләкин бу зур әдипнең үпкәсе, аның мие, фикере, йөрәге дәрәҗәсендә ныклык күрсәтә алудан гаҗиз иде.

Хезмәтенең егерменче елында аны аяктан егып, дәвалану, хәл җыю, көч кайтару өчен Кырымга озаттырды.

Бу урында хәзергә Галимҗан иптәш Ибраһимовның бөек хезмәтенең әллә ничаклы катлауларына, тармакларына тәфсилле

рәвештә тукталып тору, шуларга канәгатьләнерлек бер анализ ясау – ашыгыч язылган бу мәкаләдә мөмкин түгел.

Шулай да хезмәтенә 20 ел тулу уңае белән бик кыска һәм бер җыйнама рәвешендә генә аның хезмәтенең кайбер иң әһәмиятле нокталарын искә алып үтәргә тиешмен.

Галимҗан Ибраһимовның шушы егерме ел эчендәге хезмәтләрен без түбәндәге рәвештә берничә төп тармакка аерылганын күрәбез:

1) Татар сүз сәнгатендәге иҗатлары.

2) Татар теленең грамматикасы, әдәбият белеме, әдәбият тарихы һәм әдәби тәнкыйть юлындагы оригиналь иҗади хезмәтләре.

3) Татарның иҗтимагый һәм революцион хәрәкәте тарихына, аның мәгълүм бер гыйльми система алып, ул бабта аерым нәрсәләр тудырыла башлау юлына каратылган хезмәте.

4) Мөгаллимлек хезмәте. (Татар теле һәм әдәбияты, шулай ук татар иҗтимагый-революцион хәрәкәте тарихы мөгаллиме булуы).

5) Дәүләт кешесе булуы, дәүләт идарәләрендә, аппаратта эшләве.

Галимҗанның сүз сәнгатендәге иҗатлары үзләренең мөндәриҗә (*эчтәлеге*) һәм типлары ягыннан күп өлешендә татар эшче-крестьян тормышының сурәтләреннән гыйбарәт. Әдәбишигъри әсәрләренең теле-өслүбе, тәгъбиргә байлыгы, матурлыгы ягыннан янә алар шул ук киң тирән бер хәзинәнең беренче зур өлеше.

Октябрьдән элек татар крестьян тормышын, аның батрагын, ярлысын, «Ялчы»сын, «Көтүче»сен, башкасын эчке-тышкы бөтен киңлеге белән нәфис әдәбият дөньябызга ул күтәреп чыкты. Нәфис әдәбиятыбызның мөндәриҗәсен, типларын, тел-өслүб якларын бу яктан башлап ул эшләде, ул баетты.

Югарыда әйтелгән әсәрләреннән тыш, аның бу юлдагы әдәби иҗатларыннан «Табигать балалары», «Яшь йөрәкләр», «Йөз ел элек» һәм башкалары – шундый әсәрләренннән.

Галимҗан Ибраһимов крестьян тормышының революциядән элекке тыныч вакытындагы хәлен тасвир белән генә калмады, шуның өстенә ул бу киң тормышның революция (февраль-октябрь) дулкыннары эчендәге бөек кузгалышын, андагы төрле иҗаби (*уңай*), сәлби (*кире, тискәре*) күренешләр һәм типларны да үзе алган мәүзугъларында (*темаларында*) тулы, нәфис итеп эшләп бирә алды («Кызыл чәчәкләр», «Адәмнәр»).

Галимҗанның әдәби әсәрләрендә күбрәк крестьян яшьләр хәрәкәте, аларның тулы яшьлек һәвәсләре, яшьлек дәртләре эчендәге көрәш-тартышлары, ирек, иркен тормыш өчен омтылулары тасвир ителде.

1905 елгы революция хәрәкәтен, куркыныч реакция көннәрен, аның бөтен татар дөньясына, гавамына, крестьянына, эшчесенә, укымышлысына, шәкертенә, зыялысына, студент-студенткасына, иренә-хатынына тәэсирен, аларның шуңар ничек катышу һәм катышмауларын күп тулылыгы

белән беренче мәртәбә татар нәфис әдәбият дөньясында яшәтеп калдыручының беренчесе дә Галимҗан Ибраһимов булды («Безнең көннәр» һәм шул ук «Кызыл чәчәкләр»).

Галимҗанның бөтен әдәби әсәрләрен аерым санап, һәммәсенә анализ ясап үтүгә монда имкян (*мөмкинлек*) юк. Шулай да аның сәнгатьчә эшләнүдә иң югары бер дәрәҗәгә барып җитә алган әсәрләре рәтеннән «Казакъ кызы»н әйтеп үтмичә ярамый. Бу әсәрне татар нәфис әдәбиятында иң кыйммәтле бер әсәр дип санарга кирәк.

Татар әдәбияты беренче зур романнарны да аның каләме аркылы башлап күрә алды («Яшь йөрәкләр», «Безнең көннәр»).

Галимҗан Ибраһимовның әдәби иҗатлары, әдәбилеге турында без боларны түгел, бер мәгълүмат, тулы бер анализ бирү эшендә язмыйбыз, болар аның әдәби иҗатларына тик өстән-өстән сикерә генә бер караш ясап чыгудан гыйбарәт.

Чынында Галимҗан әле бездә ныклап тикшерелергә башланмаган тирән һәм гаять катлаулы бер сәнгать хәзинәсе булып тора. Аның шушы 20 еллык хезмәтен искә алу сәгатьләре аны инде ныклап һәм тирәннән тикшерә башларга вакыт җиткәнен, яшь әдипләр өчен аннан өйрәнүне нәүбәткә куяр чакның да бик якынайганын күңелләргә нык утыртып калдырырга тиеш булыр.

Галимҗан Ибраһимов хезмәтләренең башка тармакларына килгәндә, бу урында әнә кыскача гына шуны әйтә алабыз:

Ул татар теленең грамматикасын яңа нигезгә утырту, татар теленең үз табигатенә муафикъ итеп эшләү юлында беренче адымны салды («Татар сарыфы», «Татар нәхүе».) Әдәбият белемен нигезләндерү, киңәйтү юлында вакытында зур хезмәт куйды («Әдәбият кануннары»). Татарның әдәбият тарихы өчен күп кыйммәтле материаллар бирде («Аң» һәм «Безнең юл» һәм «Каюм Насыйри мәҗмугасы»ндагы мәкаләләре). Татар теленең методикасын эшләште («Татар телен ничек укытырга?»). Татар әдәбиятының методологиясенә беренче нигез салышты («Безнең юл»дагы мәкаләләре).

Шулар өстенә күп кенә әдәби тәнкыйтьләр бирде («Татар шагыйрьләре»)...

Татарның иҗтимагый һәм революцион хәрәкәтенең тарихын язды («Татарлар арасында революция хәрәкәтләре», «Мулланур Вахидов» мәҗмугасындагы мәкаләсе).

Галимҗан әдип булды, язды гына түгел, шуның белән бергә, ул укытты да. Ул гомеренең моңарчы булган күп өлешен укытучылык, мөдәррислек белән үткәрде. Татар мәктәпләренә башлап әдәбият кертүче беренче әдәбият мөгаллимнәренең берсе ул иде. Вакытында «Галия»гә татар әдәбияты аның белән керде.

Галимҗан Ибраһимовның 20 еллык хезмәтенең соңгы 10 елы аның дәүләт юлындагы, совет аппаратларындагы хезмәтен эченә аладыр, ягъни ул Октябрьдән соң һәм Октябрьнең

шушы беренче ун елы эчендә сәяси эшләрдә, дәүләт аппаратларында да нык эшләде.

Шушы көн үзенең киң иҗтимагый-әдәби хезмәтенә 20 ел тулган бу әдипнең, татар сүз сәнгате дөньясындагы бу зур талантның шушы мөддәт эчендәге хезмәтләренә кыска гына, өстән генә бер анализ ясап үткәндә әнә шул югарыдагы җыйнамаларны күрәбез.

*Мәкалә 1927 елда «Кызыл Татарстан» газетасының 245 нче санында (25 октябрьдә) басылып чыккан.*

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре Л.Ш. Гарипова әзерләде.*

УДК 929

***Галимҗан Нигъмәти***

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ӘДӘБИ ХЕЗМӘТЕНЕҢ ЕГЕРМЕ ЕЛЫ

Статья известного татарского литературоведа и критика Г. Нигмати (1897–1941) посвящена к 20-летнему научному и творческому юбилею татарского писателя Галимджана Ибрагимова, отмечавшемуся в 1928 году. Автор статьи на примере произведений Г. Ибрагимова прослеживает идейную и творческую эволюцию писателя. Статья была опубликована в 1928 году пятом номере журнале «Җитәкче».

**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, Галимджан Нигмати, татарская литература, революционное движение начала XX в., литературоведение, литературная критика.

«Татар яшьләре социализмга революция дулкыны белән килеп кергәннәр. Моның да башы Казанда, Казанның да “Учительская школа”сы тирәсендә булган, татар пролетариатының беренче дуслары шуннан чыкканнар. Башта һәммәсе бергә иде. Син – с.д. (*социал-демократ*), мин – эсер, теге большевик, бу меньшевик, яки уң, урта, сул эсер дип аерылулар сизелми иде.

Бара-бара төрле партия кешеләре үз сызыкларын бүлә төшеп, араларында аерылу башлана: “Баштагы аерылу үзара талашуда гына булса да, бара торгач тирәнәйде, төпләнде, һәр ике як үзләренең гомуми партияләре белән берләшеп, организация өчен, гәзитә чыгару, матбугат тарату өчен партиядән акча алдылар».

«Эсерлар Идел, Кама буен, бигрәк тә Казанны; эсдеклар *(социал-демократлар)* Уралны, бигрәк тә Оренбурны мәркәз итеп аерым оештылар, аерым эшли башладылар. Арада урыслардагы кебек кызу талаш юк, һәр икесе башлыча көчләрен истибдадка *(абсолютизмга),* буржуазиягә, бигрәк тә «Иттифакы мөслимин» партиясенә юнәлдерәләр». Әдип Галимҗан Ибраһимов үзенең 1912–1913 нче елларда язып та, патша цензуры рөхсәт бирмәгәнлектән, ул заман бастыра алмаган, тик Октябрь революциясеннән соң гына бастырып чыгарган «Безнең көннәр» романында бишенче ел революциясе дәверендә татар революционерлары күпчелекнең йөзен әнә шулай күрсәтә. Шөбһәләнми әйтергә була: әдип үзе дә шулар арасында кайнаган, шулар дәрте белән янган типлардан берсе һәм югарыда әйтелгән тип революционерлардан үзенең соңгы елларда яхшы гына – марксизмга, коммунистлыкка таба үсүе, үсеп өлгерүе белән аерылган берсе. Әдипнең әдәби-иҗтимагый эш гомерен тикшереп күздән кичерсәң, без югарыда әйткән бу фикерләребезнең дөреслеген ачык күрәбез. Галимҗан Ибраһимов бишенче

ел дулкыны белән күтәрелгән кеше. Аның тарихы мәдрәсә чуалышларына барып бәйләнә. Ул «Безнең көннәр»дәге каһарманы Давыд Урманов әйтмешли, иҗтимагый үсешендә безнең картрак революционер – зыялыларның күпкенәсенә уртак сыйфат булган дүрт үсү баскычын кичергән: башта кадимче, аннан җәдидче реформатор, соңра татар милләтчесе һәм ахыр килеп – революционер социалист. Әгәр дә без әдипнең тәрҗемәи хәленә карасак, аның бу дүрт баскычны бишенче елларда ук кичереп, Октябрьдән соң инде аның җиң сызганып пролетариат көрәше сафында эшләвен күрәбез.

Галимҗан Ибраһимовны әдәбилек, тел-әдәбият теориячесе, җәмәгать – совет эшчесе булу якларыннан карап, бу өлкәләрдә аның күп хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин. Ләкин шул хезмәтләр арасында аны хәзерге атаклы Галимҗан итеп таныткан ягы, аның иҗтимагый хезмәтендә зур урын тоткан эше аның әдиплеге булып, бу ягы белән ул безнең әдәбиятта югары урынларның берсен һәм мактаулысын ала.

Үзенә карата язылып яткан әдәби йөзе булган, әдиплек ягыннан коелып чыккан, танылган һәр язучының үзенә хас күбрәк яза торган мөндәриҗә *(бу очракта: бирелеш тәртибе)* һәм типлары була. Бу сыйфат, әлбәттә, ул әдипнең нинди иҗтимагый мохиттән чыгып, нинди сыйныф идеяләре астында тәрбияләнеп җитешүенә, аның иҗтимагый аңына нык бәйләнгән була. Мәсәлән, урыс язучыларыннан Максим Горький ни белән күтәрелгән, ни белән танылган дигән сорауга аның әсәрләрен укыган һәр кеше – үзенең босяклары, тормыш төбеннән алып язылган типлары белән танылды дияр. Шушы сорау белән Г. Ибраһимов иҗатын тикшерүгә килсәк, менә ни күрәбез: аның бөтен әдәби әсәрләре авыл һәм авылдан чыккан кешеләр тормышыннан алып язылган. Аның «Безнең көннәр» романында гына берничә эшче тибы һәм шәһәр кешеләре тормышы күрсәтелсә дә, болар әдип иҗатында төп мотив урынын тотмыйлар.

Икенчедән, Г. Ибраһимов каһарманнарының иң зур күпчелеге яшьләр, күбесенчә авылдан чыккан зыялылар, муллалар, крестьян малайлары.

Өченчедән, Г. Ибраһимов әсәрләрендәге каһарманнар, яшьләр искелеккә, иске тормышка, иске көнкүрешкә һәм, ахыр килеп, иске идарәгә каршы көрәшүчеләр.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә беренче урынны авыл һәм авылдан чыккан каһарманнар тоткан кебек, аның әсәрләренең теле-өслүбе, тасвирлары – авыл тел-өслүбе, табигать күренешләренә нык бәйләнгән тасвирлар.

Югарыдагы карашларыбызның күпме дөреслеген күрер өчен аның әсәрләренә әз генә аерым рәвештә күз салып китик. Г. Ибраһимовның беренче әсәре «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемендәге хикәя булып, ул 1907 елның искечә 10 нчы октябрендә «Әл-Ислах» газетасында басыла башлый һәм шул газетаның берничә номеры буенча басыла барып тәмам

була. Шуннан соң аның «Татар хатыны ниләр күрми», «Яшьләр хәятеннән бер ләүхә» исемле хикәяләре чыга. Бу өч хикәянең өчесендә дә әле үзенең бөтен ваклыклары, түбәнлекләре белән иске мәдрәсә тормышы һәм шул тормышның үз эчендәге кечкенә генә бер уяну хәрәкәтен дә бастыру күренешләре, ләкин, шуңа карамастан, әнә шул караңгылык ояларында да яңалык фикерләре тамыр җәя, үрчи баруы күрсәтелә. Бу әсәрләрдәге каһарманнар, «Татар хатыны ниләр күрми» дигән хикәядәге Гөлбануны бер читкә алып куйганда, һәммәсе дә шул заман тормышының реаль типлары, алар һәммәсе дә тормыштан алынып, табигый һәм дөрес итеп күрсәтелгәннәр. Тик Гөлбану гына аерым тора: крестьян кызы Гөлбану башта үзе сөймәгән берәүгә кияүгә бирелә, соңра аннан качып киткәч, бер башкортка өченче хатынлыкка сатыла, ул үтерелгәч, каенатасына көчләп хатынлыкка алына, соңра моннан да качып, ирләр кыяфәтенә кереп, бер байда хезмәтче, соңра саллар агызу эшендә эшче булып йөри. Мойкаларда эшли, сезонлы эш беткәч, көзен тагын бер авыл баена кучер булып яллана. Шул рәвешчә, ул үз башыннан әллә нинди кызыклар кичерә. Менә бу типның язылуы әдипнең көнчыгыш әдәбияты, шуның «Әлфе ләйлә», тагын нәрсәләрен укуы тәэсирендә эшләнгән булса кирәк. Һәрхәлдә, бу тип Г. Ибраһимов әсәрләрендә очраклы тип булып, әдип күрсәткән каһарманнарның бик күбесе аның башка күп әсәрләрендә икенче калыпта һәм үсештә кабатланган шикелле, бу типның яңадан бер кат та тәкрарланмавы да аның очраклы тип икәнен күрсәтә.

Г. Ибраһимовның сугыш елларына хәтле үк язып өлгерткән ике зур романы «Яшь йөрәкләр» һәм «Безнең көннәр»ендә, Октябрьдән соң басылып чыккан матур озын хикәясе «Кызыл чәчәкләр»ендә шул ук яшьләр тормышы, аларның көрәше язылa.

Әлбәттә, әдипнең иҗаты югарыда әйтелгән схемадагы әсәрләр белән генә чикләнми. Бәлки шулар янына аның «Ялчы карт», «Диңгездә», «Сөю – сәгадәт», «Карак мулла», «Адәмнәр», «Казакъ кызы» кебек тормышның төрле катлавын күрсәткән әсәрләре дә бар.

Г. Ибраһимов иҗатының кыйммәте аның авыл һәм яшьләр тормышын оста бирә белүендә генә түгел, бәлки шуның өстенә аның бишенче һәм унҗиденче елларның революция көрәшләрен, революция көрәшчеләре тормышын да язуында. Бу ягы белән ул революциядән элеккеге татар әдәбиятлары арасында аерым урынны тота. Чөнки ул вакыт, Г. Коләхмәтовның «Яшь гомер»е, З. Бәшири һәм тагын бу ике шагыйрьнең кызгылт шигырьләре һәм берничә тәрҗемә кисәкләреннән башка, безнең әдәбиятта революция хәрәкәтләрен чагылдырып язган әсәрләр юк иде.

Г. Ибраһимов үзенең «Безнең көннәр»е белән әнә шул юклыкны тутырырга адым атлады, тик патша цензурының рөхсәт бирмәве сәбәбле генә, «Безнең көннәр» ике табагы басылган көйгә типографиядә басылудан

туктатылып, вакытында дөньяга чыгарылмый калды.

Бераз романтика катнаштырылып язылган «Яшь йөрәкләр» янында «Безнең көннәр» романы бөтенләй күрекле урыннардан берсен тота. Бердән, күләме белән ул революциягә хәтле һәм аннан соң да татар әдәбиятында булган әсәрләр арасында иң зурысы, шуның белән бергә алган мәүзугы *(темасы),* бишенче еллардагы татарның мәдрәсә, приказчик, крестьян хәрәкәтләрен, төрле катлаудан чыккан, төрле тип татар революционерларының эш һәм тормышларын күрсәтүе ягыннан иң кыйммәтлесе. Урыны белән бу әсәрдә бишенче елның татар арасындагы революция күренешләре тарихы копия диярлек тапкырлык һәм җентекләү белән күрсәтелгән җирләре бар.

Әмма Октябрь революциясеннән соң чыккан «Кызыл чәчәкләр», «Яңа кешеләр» (пьеса) һәм «Адәмнәр» хикәяләре пролетариат революциясендә кайнаган Галимҗанның каләме белән язылган әсәрләр булып, боларда әдип пролетариат революциясенең тормышта нинди алмашынулар кертүен, кемнәрне кемнәргә дошман итеп көрәшкә китереп бастыруын, тормышның түбән катлауларыннан – ярлы, урта хәлле крестьяннар, батраклар арасыннан аның ничек итеп революция көрәшчеләрен җитештереп чыгаруын матур тел, оста каләм белән күрсәтеп биргән.

«Кызыл чәчәкләр»дә бер авылның бишесе биш төрле гаиләдә тәрбияләнеп үскән, хезмәт һәм көрәш мәйданына атылган егетләр тормышы хикәя ителә. Бу егетләрдән өчесе – Шаһбаз, Солтан, Гыйлаҗи (ярлы, урта хәлле, батрак) – революциянең беренче көннәреннән алып эшче-крестьяннар ягыннан торып көрәшкә чыксалар; икенчесе – Фазыл һәм Гали (мулла малае белән бай малае) – пролетариат революциясе көннәреннән көрәшнең эшче-крестьянга каршы як лагерында була. Тик ахырда Фазыл гына пролетариат көрәшчеләре ягына чыгып, актив эшкә тотына. «Яңа кешеләр»дә дә шундыйрак тип көрәшчеләр алына һәм анда аерым рәвештә авыл кулаклары, байларның революциягә каршы көрәшләре, революция юлында эшләүчеләргә террор куллану рәвешләре (мөгаллимә Камәрне үтерү) күрсәтелә. «Адәмнәр» хикәясендә 1921 елның Волга буе ачлыгы үзенең бөтен куркынычы һәм авыру ягы белән сурәтләндерелеп бирелә.

Г. Ибраһимовның революция темаларына язган әсәрләренең күзгә күренгән бер сыйфаты бар: аларда эшчеләр тормышы һәм эшчеләрдән чыккан революционерларның көрәше бик әз күрсәтелә; әмма крестьян һәм төрле зыялы катлаудан чыккан революционерларның эшләре бөтен җентекле яклары белән оста итеп бирелгән. Бу тип каһарманнарны тасвир кылуда әдип әлегәчә безнең татар әдәбиятында ияреләмәслек бер оста художник ролен уйнады дисәң дә, яңлыш булмас. Шуның белән бергә әдипнең үзенең фикере, иҗтимагый үсүе, үзгәрешләр кичерүе аның әсәрләрендә дә күренеп бара. Аның «Безнең көннәр»е белән «Кызыл чәчәкләр»ен янәшә китереп

куйсаң, бу үзгәрешне яхшы күреп була: беренчедә эсер һәм бераз татар милләтчесе әдип каләме сизелгәләп торса, икенчесендә инде марксист каләме үзенең кызыл эзләрен сыза барган. Шуңа күрә дә, мәсәлән, беренче әсәрдә Давыд Урманов кебек реакция көннәрендә рух төшенкелегенә бирелгән, индивидуалист типлар артыграк идеаллаштырылган булса, икенчесендә инде шундый типлардан берәү Фазыйл мәгъзум пролетариат революциясе шартлары астына куелып, аек рәвештә көчле әдиплек тәнкыйте астыннан үткәрелә. Беренчедә татар крестьяннар хәрәкәтен әдип томанлы рәвештә һәм нинди сыйнфый мотивларда булганы ачып җиткерелмәстән биргән булса, икенчедә инде авылның сыйныф көрәше ачык һәм үткер тасвир кылынган һәм башкалар.

Бик кыска, бик өстән генә карап чыкканда, әдипнең шушы егерме ел эчендәге иҗаты әнә шул рәвештә үсеп җитеште. Әнә шул өстән генә карауда безгә аның ни чаклы зур әдәби хезмәтләр күрсәткәнен, татар әдәбиятын оста эшләнгән һәм революция мөндәриҗәле *(эчтәлекле)* әсәрләр белән баетуга ни чаклы күп көч биргәнен яхшы күрсәтәләр.

*Мәкалә 1928 елда «Җитәкче» журналының 5 нче санында басылып чыккан.*

*Текстны басмага Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре Г.М. Ханнанова әзерләде*

УДК 745.51

*А.Р. Москвина*

# ӘСТЕРХАН ТАТАРЛАРЫ АВЫЛ ӨЙЛӘРЕНЕҢ ДЕКОРАТИВ БИЗӘЛЕШЕ

*(Әстерхан өлкәсенең Идел буе районына оештырылган экспедиция материаллары буенча)*

В статье на основании сравнительно-сопоставительного анализа рассматриваются основные приемы и формы декоративного оформления татарского сельского жилища астраханских и поволжских (казанских) татар. Выделяются характерные черты организации интерьерного и экстерьерного пространств.

**Ключевые слова:** деревянная резьба, интерьер, экстерьер, фронтон, наличники, астраханские татары.

2013 елның июнендә ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Әстерхан өлкәсенең Идел буе районына фәнни экспедиция оештырылган иде. Милләттәшләребез тыгыз булып урнашкан бу районда без җирле татар халкының фольклоры, мәдәнияте, көнкүреш йолалары һәм сәнгате белән таныштык, аларны туплап кайттык. Экспедиция барышында шушы районның Келәче, Җәмәле, Ярлы Түбә, Кызан, Мәйле күл, Каргалык һәм Нариман районының Каңга авылларында булдык.

Әстерхан татарларының декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләре фотографияләреннән бай материал җыелды. Бу мәкаләдә сүз әлеге өлкәнең Идел буе районында яшәүче милләттәшләребезнең авыл өйләрен ничек итеп бизәүләре турында барачак. Алар буенча материалларны без этнографик ысуллар – визуаль күзәтүләр, рәсемнәрен ясау, җирле халыктан сорашып белү ярдәмендә тупладык. Тикшеренүләрнең нигезен Идел буеның башка өлкәләрендә ( аерым алганда, Казанда) һәм Әстерханда яшәүче татарларда авыл өйләренең декоратив бизәлешен чагыштырма планда өйрәнү тәшкил итте. Тикшереп өйрәнү объектларының күбесе XX гасырның 40–90 нчы елларына карый.

Иделнең түбән агымында яшәүче төрки халыклар арасында татарлар үзләренең һәрьяклап алга китеше белән аерылып торалар. Әстерханда татарларның этник төркемнәреннән юрт татарлары, кундра татарлары һәм карагашлар яши. Юрт татарлары турында, беренче булып, XVI гасырда инглиз сәяхәтчесе Христоферр Берроу язмаларында әйтелә. Аның мәгълүматлары Әстерхан кремле дивары янында янгын чыгу белән бәйләп язылган [Викторин, с. 12]. XVIII–XIX гасыр тарихчыларыннан В.Н. Татищев, С.Г. Гмелин, П.И. Небольсин Әстерхан татарларының тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән шөгыльләнгәннәр.

XX гасыр галимнәрен, нугайлар гына түгел, җирле

этнотерриториаль төркемнәргә бүленмәгән хәлдәге Әстерхан татарлары кызыксындыра. Этнограф, педагог, крайны өйрәнүче галим В.М. Викториннның Әстерхан авылларындагы көнкүрешне, йола-гадәтләрне, фольклорны тикшереп өйрәнүе аерым игътибарга лаек. Шулай ук филологлардан Л.Ш. Арсланов, Ф.С. Баязитова, Ф.Х. Җәүһәрова, музыка белгечләреннән М.Н. Нигъмәтҗанов, А.Р. Усманова, Д.И. Үмәровларның фәнни эшләрендә дә шушы объектлар яктыртыла.

Әстерхан татарларының сәнгати мәдәнияте алар яшәгән территориянең географик урнашуы, табигый ресурслары һәм сәүдә бәйләнешләре белән билгеләнә. Борынгы чорлардан ук авыл кешесе сарык, ат асраучылык, яшелчәчелек, бакчачылык (кавын-карбыз үстерү) белән шөгыльләнгән. Шулай да төп кәсепләре балык тоту булган. Ирләр балта, агач эшенә, ә хатын-кызлар тегү-чигүгә осталыклары белән аерылып торганнар.

Авылларда торак йортларның бик борынгы формалары да сакланган. Әйтик, саман кирпечтән эшләнгән (Җәмәледә), камыш һәм пластина түбәле өйләр очрый. Камышны балчык белән сылап җәйге аш өйләре, мунчалар төзегәннәр. Өлкәннәр сүзенә караганда, аларда җылы бура өйләрдәгегә караганда яхшырак сакланган. Киләчедә күпчелек гаиләләр идәненә һәм түбәсенә камыш түшәлгән землянкаларда яшәгән. Балчык өйләр һәм землянкалар Ярлы Түбә авылында киң таралган. Ишегалдында терлек абзарлары, мунча, туалет булган. Хәзер боларга теплицалар өстәлгән.

Өй интерьерының төп атрибутын камыш белән ягыла торган мич тәшкил иткән, мичнең бер ягына җайлап казан урнаштырылган, анда аш-су әзерләгәннәр. Өй эчендәге тагын бер элемент – ул сәке (тохтамбит), аннан XX гасырның 70 нче елларына кадәр файдаланганнар. Ә инде камыр җәю өчен кулланыла торган куна өстәле әле дә бар. Такта киштәләрнең төрле формаларын, сандыкларны һәр өйдә диярлек очратасың. Өй эчен (интерьерны) бизәү өчен келәмнәр, паласлар, чаршаулар, тәрәзә пәрдәләре, чигелгән сөлгеләр, чыбылдыклар кулланылган. Тик хәзер инде бу әйберләрдән файдаланмыйлар, алар фәкать авыл өлкәннәренең сандыкларында гына сакланалар.

Әстерхан татарларында авыл өенең тышкы бизәлеше күп гасырлардан сакланып килгән традицияләрне һәм халык осталарының тәҗрибәсен чагылдырган декоратив формаларның күптөрлелеге белән аерылып тора. Өй, кеше өчен, кечкенә бер галәмне тәшкил иткән, шуңа күрә аның бизәлеше дә халыкның әйләнә-тирә дөнья, аның гармониясе һәм гүзәллеге турындагы белемнәренә нигезләнгән. Агачтан кисеп эшләнгән үзенчәлекле өлгеләр тәрәзә йөзлекләрендә, өй каршындагы бакча коймаларында, капкаларда, өй кыегының фасад ягында гәүдәләнеш тапканнар.

Өйләр нигездә урам читенә салынган, ә кайберләрен урамнан 3–4 метрга түр бакча аерып тора. Анда агач-куаклар, күбрәк чәчәкләр үстерәләр. Бу традиция

Татарстанның Мамадыш һәм Балтач районнары авылларында да күзәтелә. Сәнгать белгече, фәннәр докторы Фуат Вәлиев үзенең «Архитектурно-декоративное искусство казанских татар» дигән хезмәтендә Октябрь инкыйлабы алды елларында торак йортларны урам яктагы коймадан 6–8 метрга эчкәрәк кертеп салуларын, хәзер исә урамга якынрак итеп, урам як коймасыннан 2–4 метр гына ара калдырып урнаштыруларын билгеләп үтә [Валеев, с. 55].

Йортның тышкы бизәлешендә өй кыегының урам якка караган, өчпочмакланып торган өлеше (фасад фронтоны) аеруча өстенлекле урын били, ул узып баручыларның игътибарын үзенә җәлеп итә. Шуңа күрә җирле халык аны матур итеп бизәргә тырыша.

Фронтонны бизәүнең төп вариантлары такта белән тышлау һәм буяу ярдәмендә тормышка ашырыла. Нәтиҗәдә фронтон фасад яссылыгында бик нык аерылып тора. Анда түгәрәк рәвешендәге чорма тәрәзәсе урнаштырыла, сирәк кенә, бернинди тишемсез эшләнгән «тоташ» фронтон да очрый. Тышлауның да төрле вариантлары бар. Аның иң киң таралганы – чыршы ботагын хәтерләтеп эшләнгәне, ромб тибындагысы да еш очрый. Фронтонның үзәгенә кисеп эшләү техникасы ярдәмендә башкарылган бизәк детальләре ябыштыру киң кулланыла.

Җирле халык, еш кына, чормада күгәрченнәр асраган (әле хәзер дә моңа мисаллар бар), шуңа күрә чорма тәрәзәсе йөзлекләре бизәлешендә пар күгәрченнәр сурәте очрату һич гаҗәп түгел. Өлкәннәр сөйләве буенча, тәрәзәдән күгәрчен очып керсә, аны яхшыга юраганнар. Әле узган гасырның 80–90 нчы елларында да өй кыегының урам ягын кош сурәтләре белән бизәү кулланылган, ул вакытта аларны калайдан ясаганнар.

XIX гасырда Казан татарлары өчен характерлы булганча (XX гасырда инде кулланылмаган), фасад фронтонына тирән итеп ясалган уемнар Әстерхан өлкәсендә бөтенләй очрамады. Уемны чорма тәрәзәсе белән алыштыру ТРның Мамадыш районы авылларына хас, һәм аларны Әстерхан өлкәсенең Идел буе районында да очраттык. Анда чорма тәрәзәләре тактадан кисеп эшләнгән бизәкләргә аеруча бай.

Тәрәзә йөзлекләренә үсемлекләр орнаментлары һәм геометрик фигуралар төшерелгән. Бизәкләр тематикасы буенча Әстерхан ягы Татарстанның Мамадыш районындагыдан шактый калыша. Тәрәзә йөзлекләре, тышкы бизәлешне баету белән бергә, өйнең стенасы һәм тәрәзә борыслары арасындагы тишекярыкларны томалау ягыннан да файдалы функция үтиләр.

Өй аллары, еш кына,тоташ, әмма тәрәзә йөзлекләренең һәм фасад фронтонының бизәкләрен каплап тормаслык итеп, тәбәнәк койма белән әйләндереп алынган. Олы капка һәм янкапка тактадан кисеп эшләнгән розетка, ромб һәм төрле варианттагы соляр символлар ябыштырып бизәлгән.

Капканы матур итеп бизәүгә дә зур игътибар бирелә. Аның бизәлеше йортның фасад ягы

стенасы бизәлеше белән композицион бердәйлек тәшкил итә. Монда шуны искәртеп үтү урынлы булыр: өйнең фронтоны, капкага караганда, баерак итеп бизәлә. Капка баганасының өске өлешенә гадәттә розетка урнаштырыла, аннан багана нигезенә таба ишмә баусыман бизәк юнәлдерелә. Шулай ук «рус капкалары» стилендәге үрнәкләр дә саклана. Әмма алар бик сирәк. Агач капкаларны бизәкләү өчен розетка, ромб, өчпочмаклык рәвешендә агачтан кисеп эшләнгән үрнәкләр файдаланыла.

Әстерхан якларында тәрәзәгә капкачлар кую гадәткә кергән, тик аларны бизәкләмиләр. Өлкәннәр тәрәзәләрне капкачлы итеп эшләүне климатик шартлар, аеруча кояшның чамасыз нык кыздыруы белән бәйләп аңлаталар.

Авыл өйләрен мозаика рәвешендә тышлауның файдалы ягы шунда, ул бураны дымланудан һәм башка табигый катаклизмнардан саклый. Материаллар туплау вакытында безгә аерым элементлары (мәсәлән, фасад ягындагы тәрәзәләрнең йөзлекләре, чорма тәрәзәсе) гына буялган йортларны да очратырга туры килде. Шуны искәртеп үтәргә кирәк, буялган йортларның сәнгати тәэсире көчлерәк кабул ителә.

Җирле халык, кыйммәткәрәк төшсә дә, өйнең фасад өлешен яхшы сыйфатлы майлы буяу белән буйый. Өлкәннәр әйтүенчә, соңгы елларда моңа игътибар аеруча арткан. Ә инде без өйрәнеп тикшергән авыллар Әстерхан шәһәренә якын урнашканлыктан, анда яшәүчеләргә буяу табу кыен түгел.

Өйләрнең тышкы ягын матурлау өчен, нигездә, зәңгәрсу һәм ак төстәге буяулар киң кулланыла. Күзәтүләрдән мәгълүм булганча, аерым детальләрне буяганда төп фонга контраст төсләрне сайлау принцибы өстенлек итә. Шулай ук өйнең тышкы ягына тоташ яшел фон бирү һәм аерым детальләне ак төсләр белән бизәү дә киң таралган.

Йортның тышкы ягын агарту алымы сирәк очрады.

Агачны кисеп, уеп бизәкләүгә аерым тукталып үтәсе килә. Авыл торагының экстерьеры бизәлешен нәкъ менә агачны кисеп, уеп эшләнгән орнаментлар тәшкил итә. Әстерхан төбәгендә өйләрнең тышкы ягын, капкаларны яссы тактадан кисеп эшләнгән орнаментлар һәм сурәтләр (мәсәлән, кош) ябыштырып бизәкләү киң кулланылган. Бу эшнең осталары авыл торакларын матурлый торган гаҗәеп нәкышлар иҗат иткәннәр. Алар йортларның фронтоны, тәрәзә йөзлекләре, балкон, түбә сыртының фасад ягындагы атчык (конек), болдыр, койма һәм капка баганалары кебек конструктив элементларына игътибарны ныграк җәлеп итү өчен эшләнә. Бу якларда скульптура дәрәҗәсендәге зур күләмле агач бизәкләр очрамады.

Әстерхан өлкәсенең без булган авылларында осталар бизәк орнаментларын 2–2,5 см калынлыктагы юкә, нарат такталарыннан кисеп алып эшләгәннәр. Эш кораллары итеп алар лобзик, өтерге һәм борау кулланалар. Тактага башта бизәкнең рәсемен төшерәләр, һәм аны кисеп алып,

өслегән шомартып, тигезләп эшкәртәләр.

Тактадан кисеп бизәкләр эшләү өчен халык сәнгатенең башка төрләрендә (чигүдә, рәсем төшерү, челтәр бәйләү һәм аппликациядә) кулланыла торган сюжетлар, образлар, алымнар да файдаланыла. Андый бизәкләрдә, кагыйдә буларак, сурәтләрнең киң мәгънәлелеген тоясың.

Йортның тышкы ягын бизәүдә үсемлекләрнең тактадан кисеп алынган орнаментлары киң кулланыла.Ул орнаментлар элементлары кабатланып, буй-буй итеп һәм гирляндалар хасил иткән яфраклар, чәчәкләре һәм яфраклары чиратлаштырылган спиральсыман бормалар рәвешендә урнаштырыла. Андый бизәкләр фасад ягы тәрәзә йөзлекләрен, фронтоннарны, койма-капкаларны бизәүдә кулланыла.

Геометрик орнаментлар да, түгәрәкне, кояшны хәтерләткән сурәтләр дә һәркайда таралу алган. Кояшка охшатып эшләнгән розетка сурәте кояшка табынган борынгы мәҗүсиләрдән үк сакланып калган булса кирәк.

Геометрик орнаментлар ритмлы итеп һәм һәр өлеше үзара туры китереп урнаштырылган түгәрәкләрдән, спиральләрдән һәм тәре сурәтеннән, зигзаглардан, почмаклыклардан, дулкынсыман фигуралардан гыйбарәт.

Соляр тамгалар – Тәңренең символик сурәтеннән стильләштерелгән. Мәсәлән, түгәрәк, стильләштерелгән чәчәк розеткасы кояшны хәтерләтә. Бу да киң кулланылыш алган.

Совет чорында халык осталары йортларның тышкы ягын бизәүдә заман рухына тәңгәл символикалардан (аларның иң күп таралганы биш канатлы йолдыз иде; урак, чүкеч, сирәк кенә очракта бодай башагы) да файдаландылар.

Өйләрнең кыегын челтәр кәрниз белән бизәү хәзер сирәк күренеш.

Әстерхан өлкәсендә күргәннәргә нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә, биредә этномәдәни традицияләрнең формалашуына XVII гасырда Әстерхан губернасына Идел – Урал буйларыннан (нигездә Казаннан) күчеп килгән татарларның йогынтысы зур булган. Бу тенденция авыл өйләренең эчке бизәлешендә дә, тышкы бизәлешендә дә күзәтелә.

Совет елларында Әстерхан өлкәсендә яшәүче татарларның традицион мәдәнияте дә, җитештерү хуҗалыгы да зур үзгәрешләр кичерә. 1930 еллардан башлап, урбанизация күренеше көчәю нәтиҗәсендә, декоратив-гамәли сәнгать әйберләренә ихтыяҗ бетә. Без бер генә авылда да һөнәри балта осталарын очратмадык. Борынгыдан ук милли сәнгать төре саналган кәсеп – агачтан кисеп бизәкләр эшләү бетүгә йөз тота. Осталарның үз тәҗрибәләрен яшьләргә өйрәтеп калдыра алмаулары бик кызганыч әлбәттә.

Шунысы мөһим, авыл йортларын декоратив бизәүдә осталар бердәм стиль башлангычын саклап калуга зур игътибар бирәләр. Агачтан кисеп сәнгатьчә эшләнгән һәр фрагмент тоташ буялган яки тышланган йортның гомум фоны белән уңышлы гармонияләшә. Агачтан кисеп

эшләнгән бизәкләрнең купшылыгы, сәнгати эчтәлеге күңелне җылыта, бәйрәм рухы өсти, шуңа күрә дә ул көнкүрешнең аерылгысыз атрибуты булып санала, кешеләрнең көндәлек тормышын җанландыра. Һәр йорт үз хуҗасының эстетик зәвыгын чагылдыра.

**Әдәбият**


*Викторин В.М.* Кто мы астраханцы? У этнической карты области // Астраханские известия. 1994. № 10. С. 10–13.

*Валеев Ф.Х.* Архитектурно-декоративное искусство казанских татар. Сельское жилище. Йошкар-Ола: Марийское книжное издательство, 1975. С. 93.

*Викторин В.М.* Славяно-иудейские тенденции в переселениях и этноконфессиоконтактах по границам Астраханского края (конец XVIII – XX вв.) // Астрахан. краевед. чтения. Сб. ст. Вып. I. Мат. межрегион. научн. конф. (г. Астрахань, 18–19 мая 2009 г.) / отв. ред. доц. А.А. Курапов. Астрахань, 2009. С. 179–185.

*Викторин В.М.* Лиманское «иудеянство» («приклонники к Закону Моисееву, вере Земли Сионской») // Астраханские краеведческие чтения. Сб. ст. Вып. II. Материалы межрегион. научн. конф. (г. Астрахань, 18–19 мая 2010 г.) / отв. ред. доц. А.А. Курапов. Астрахань: Изд-во Ром.Вас. Сорокина [и Мин. культ. Астр. обл., ОГУК «Астр. гос. объед. музей-заповедник», НИИ Касп. моря]. 2010. С. 270–276.

*Бусыгин Е.П., Зорин Н.В., Токсубаева Л.С.* Декоративное оформление сельского жилища в Казанском Поволжье. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. С. 127.



***Москвина Альбина Ринат кызы,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*

## ТУКАЙ ФӘНЕ ТАНТАНАСЫ

Теге яки бу халыкның фән үсешендәге казанышларны билгели торган күрсәткечләренең төрлесе булырга мөмкин. Шулай да иң күзгә күренеп торганы, шушы биеклекне аеруча калку итеп күрсәтүчесе, сүз дә юк, аның төп энциклопедиясе булу, шулай ук яшәешенең төрле тармаклары буенча да шундый ук сүзлекләрнең эшләнүе. Бу, бердән, әлеге халыкның шундый киң колачлы хезмәтләрдә күрсәтерлек үткәне булуы, шул казанышларны туплап дөньяга тәкъдим итәрлек зур әзерлекле һәм әлеге эшләрне изге гамәл итеп санаган фидакарь зыялылары булуы белән бәйле. Әлбәттә, рәсми хакимиятләр хупламаган һәм башкарып чыгу өчен тиешле шартлар тудырмаган очракта мондый омтылышлар хыял гына булып калырга мөмкин. Ник дигәндә, үткәнебездә аерым шәхесләребез тарафыннан мондый талпынулар ясап каралды, ләкин алар тормышка гына аша алмады. Татар халкы хәзерге шартларда боларның өчесеннән дә мәхрүм түгел. Әйе, боларны башкарып чыгу өчен, аерым затларыбызның гына дәртләнүе җитми иде. Узган гасырның туксанынчы еллары башында барлыкка килгән вазгыять тәэсирендә үз хокукларыбызны торгыза башлаудагы беренче адымнарыбыз гомуммилли үзаңның уяна башлавына да китерде.

Хөкүмәтебезнең Татарстан Фәннәр академиясен төзүе, аның бер тармагы булган Энциклопедия институты булдырылу әлеге киң колачлы эшне чын-чынлап гамәлгә куюның ышанычлы нигезен тәшкил итте. Күп кенә зыялыларыбызның энциклопедиябезне төзү гамәленә хәл кадәренчә өлеш кертергә алынуы гомуми омтылышлы мохит барлыкка китерде. Ил кузгалса, җил кузгала, дигәндәй, нибары ун-унбиш ел дәвамында тау кадәр эш башкарылды. Хәзерге вакытта рус телендә аның алты томы замандашларыбыз кулына килеп керде. Алай гына да түгел, күпләребезнең эш өстәлендә даими урын алды. Татар телендәгеләре дә якын елларда басылып бетәр дигән өмет белән яшибез. Әлеге казаныш фәнебезнең башка тармаклары буенча да шундый күпсыйдырышлы, эзлекле, мантыйклы, хакыйкатькә туры килә торган хезмәтләр барлыкка китерү бурычын көн тәртибенә куйды. Әйе, һич шикләнмичә әйтергә кирәк, шушы зур хезмәтебездән башка әле быелгы елга аяк баскач кулыбызга килеп кергән «Габдулла Тукай энциклопедиясе» дә пәйда була алмас иде. Югыйсә, аны төзү кирәклеген моннан утыз тугыз ел элек (1978) күренекле галимнәребез Нил Юзиев белән Әбрар Кәримуллин күтәреп чыкканнар иде. Идея генә булып калмасын өчен, Н. Юзиев әлеге сүзлекнең һәм эчтәлеге, һәм төзелеше нинди булырга тиешлеген дә ачыклый, моннан егерме еллар элек, шул күзаллауларын тирән уйланып эшләнгән документ рәвешендә коллегалары өстәленә дә сала. Кызганыч, 1996 елда бакыйлыкка китеп баруы сәбәпле, ул бу

эшкә алга таба җитәкчелек итә алмады. Аның каравы хезмәттәшләре арасыннан Нил Гафур улы Юзиевның башлангычын алга таба чынлыкка әверелдерү максаты белән янучылар табылды. Тукай энциклопедиясен төзүгә җитәкчелек итү эстафетасын икенче бер галимебез, филология фәннәре докторы Зөфәр Рәмиев үз кулына алды. Тынгысыз табигатьле, кешеләрне уртак эшкә оештыруда зур тәҗрибәсе булган бу галим, чыннан да, йөкне урыныннан кузгатып кына калмады, аны алга таба да шактый кызу адымнар белән алып китте. Ниһаять, ике ел дигәндә әлеге энциклопедиянең сүзлеге әзерләнде, академик Мансур Хәсәнов җитәкләгән әдәбият белеме советы хуплаганнан соң, гамәли эш җәелдерелеп җибәрелде. Биредә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 2006 елдан директоры, профессор Ким Миңнуллинның кайгыртучанлыгын һәм ярдәмен дә тиешенчә бәяләп үтү зарур.

Халкыбыз, бөек шагыйребезне янәшә тоеп, егерменче гасырны тулысынча, инде яңа йөзьеллыкның да дистә ярым елын яшәде. Г. Тукайны белмәгән, җанында аның йогынтысын сизмәгән татар кешесен табу кыен. Хәтта туган телебезне белмәгән, әмма рухы белән милләтебез вәкиле булып калырга теләгән кардәшләребез дә аның шигырьләре, фикерләре белән күңелләрен баетырга омтылалар. Хәзерге вакытта Г. Тукайның мирасыннан башка чын мәгънәсендә татар рухлы булу мөмкин дә түгелдер. Шуңа күрә иң зур бурыч – сүзлекнең Г. Тукайга кагылышлы төп аспектларын ачыклау иде. ТӘҺСИдә 2014 елда төзелгән тукайчылар төркеме, безнең карашыбызча, бөек шагыйребезнең шәхесен һәм иҗатын төрле яклап ачарга һәм күрсәтеп бирергә мөмкинлек бирердәй бик мөһим сигез юнәлеш буенча (алар 1998 елгы лөгатьлектә билгеләнгән иде) эш иткәннәр. Алар: шагыйрьнең мәгълүм булган барлык әсәрләрен тәфтишләү; аның иҗатыннан килеп чыга торган әдәби һәм нәзари мәсьәләләрне билгеләү; шагыйрь белән замандашлары мөнәсәбәтен өйрәнү, аларның иҗади эшчәнлегендәге чагылышын бәян итү; Г. Тукай иҗатын әдәбиятыбыз һәм вакытлы матбугат белән бәйләнештә карау; шагыйрь иҗатын илебез һәм дөнья әдәбиятлары бәйләнешендә күрсәтү; Г. Тукай шәхесенең һәм иҗатының сәнгатьнең башка тармакларында чагылышы; шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты белән бәйле урыннарга кагылышлы мәгълүматлар; Г. Тукайны өйрәнү юлында хезмәт куйган галимнәр, әдәбият-сәнгать әһелләре эшчәнлеген яктырту.

Бу тармакларга караган барлык мәкаләләрне фәнни яктан редакцияләү эшен А. Әхмәдуллин, Т. Галиуллин, Н. Йосыпова, З. Шәйхелисламов, Д. Заһидуллина, Т. Гыйләҗев, Д. Абдуллина, В. Гарифуллин, Л. Галиева, Х. Миңнегулов, М. Арсланов, Ф. Арсланова, Р. Солтанова, Р. Исламов, Р. Харрасова кебек, Г. Тукай әйтмешли, фәндә «ат уйнаткан» күренекле галимнәребез башкарып чыкканнар. Әлбәттә,

әлеге сигез «дилбегәле» эшне үз кулында З. Рәмиев тотты. Аның яхшы мәгънәдәге үҗәтлеге, таләпчәнлеге һәм зур шәхси эшчәнлеге булмаса, бу хезмәтнең шулай уңышлы тәмамлануы тәэмин ителер идеме икән? Без бүген бу эштә катнашкан тагын 130 га якын башка авторларга да рәхмәт әйтергә тиешбез. Энциклопедиягә күпсанлы фотографияләр, портретлар, рәсемнәр, сызымнар урнаштырылу да аның танып-белү әһәмиятен, фәннилеген, күрсәтмәлелек дәрәҗәсен арттыра.

Шулай ук бу хезмәтнең татар телендә аерым бер шәхескә багышланган тәүге энциклопедия икәнлеген дә бәяләргә кирәк. Бездә, шөкер, андый хезмәткә лаек бөек шәхесләребез тагын да бар. Халкыбызда үз-үзебезгә хөрмәт белән карау хисе елдан-ел арта барган заманда әкренләп аларга багышланганнарының да барлыкка киләчәгенә өмет юк түгел. Бөек шәхесләребезне чор һәм тулаем иҗтимагый, әдәби мохиттә шулай бер ноктага туплап күрсәтү бер үк вакытта халкыбызның олылыгын күрсәтү икәнлеген дә һич онытырга ярамый.

Хәер, иң әүвәл моның шулай икәнлеген Г. Тукай үзе да аңлаган. Үләренә ике атна калганда, ягъни 1913 елның 14 мартында, «Уянгач беренче эшем» дигән язмасында ул болай дигән иде: «Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен һәм шәхси тормышын энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле». Киң күңелле Г. Тукай, күргәнебезчә, болай дигәндә, үзен күздә тотмый, «һәр язучының», ди. Шул ук вакытта үз-үзенә тукайча туры, хакыйкый бәя бирә: «бәхетсез халыкның бәхетсез угылы, бәхетсез почмактагы әсир былбылы». Авыруыннан, тормыш тарафыннан кысылган рухы аның каләменнән шундый сүзләр төшерә. Әмма, бәхеткә, шагыйрьнең тереклеге вакытында башланып калган егерменче гасыр барышында, бигрәк тә аның соңгы унъеллыкларында татар үзенең башын югарырак күтәрде, иңбашын турайта төште, шушы гамәлләрендә Г. Тукайны үзенә рухи юлдаш итеп әверелдерде. Аның әле генә китерелгән сүзләре язылганнан соң йөз ел үткәч, Г. Тукайга мөнәсәбәттә менә шушы гаять олы эш башкарылып чыгылды. Шагыйрь күрергә теләгән «энәсеннән җебенә кадәр» үк булмаса да (олуг шәхес һәм аның иҗаты турында барысын да берьюлы әйтеп бетерү мөмкин дә түгел), әлеге энциклопедиядән һәрхәлдә Г. Тукай турында шактый ук тулы күзаллау барлыкка китерү мөмкинлеге бар.

Әле энциклопедия үзе чыкканчы ук, аның «алхәбәрләре», ягъни олы хезмәтнең аерым өлешләре басыла торды. Әйтик, Р. Ганиеваның «Шагыйрьнең рухи дөньясы», З. Рәмиевнең «Тукай һәм замандаш әдипләр», Н. Хисамовның «Тукайны төшенү юлында», коллектив тарафыннан язылган «Габдулла Тукай әсәрләре (сүзлек-белешмәлек)» дигән китапларны шул җөмләдән карыйбыз. Алар шагыйребезне укучыларга бүгенге бурычлар яктылыгында тәкъдим итүдә әһәмиятле бер баскыч хезмәтен үтәделәр. Шуларга

тагын З. Мансуровның «Тукай белән әңгәмәләр» дигән китабы да өстәлү, шагыйрь әсәрләренең академик басмасы нәшер ителү соңгы елларда халык шагыйренә булган игътибарның бик зур икәнлеген күрсәтә. Бу шулай булырга тиеш тә. Чорыбыз бик тә катлаулы, каршылыклы. Мондый хәлдә Тукайга сыенмыйча, кемгә мөрәҗәгать итик?

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә тәкъдир итү көнендә, бу затлы китапны кулга алып, кош тоткан кебек сөенеп, аның сәхифәләре белән танышканда, янәшәдәге берәү әйтеп куйды:

– Мондый хезмәт берничә дистә ел элегрәк чыкканда тагын да яхшырак булган булыр иде дә...

Моңа беребез дә каршы булмас иде әлбәттә. Әмма Г. Тукай әйткән бит:

– Вәләкин шарты бар: ул – алма, мөддәте тулганда пешкәч, кызаргач һәм матур булгач, җитешкәч». Ягъни вакыты җиткәч, ди.

Чыкмаган икән, димәк, әлеге энциклопедияне барлыкка китерү мәсьәләсе ул елларда әле өлгермәгән булган. Ничек өлгерсен? Егерменче-утызынчы елларда «буржуа шагыйре» дип тамга сугылган Г. Тукай турында шуңа охшаш хезмәт булдыру ихтыяҗы рәсми даирәләрдә бөтенләй юк иде. Әдәбиятыбызның төп баганалары кайсы-кая тибәрелгән, яки утызынчы елларда тоткынлыкта газапланып юк ителгән вакытта Тукай исеме дә кадерсезгә әйләнде. Гомумән, энциклопедия егерменче йөзнең туксанынчы елларына кадәр төзелсә дә, ул тулы хакыйкатьне яктыртудан гаҗиз булыр иде. Әлеге җәһәттән Г. Исхакыйга мөнәсәбәтле хәл-әхвәлне генә игътибарга алганда гына да моның шулай икәнлеге ачык күренеп тора. Бу классигыбызның гамәлләре искә алынмаган очракта гына да бирәдә бәян ителгәннәрдә күпме хилафлык булыр иде. Г. Исхакыйның исеме һәм мирасы әйләнеп кайтуының әдәбиятыбыз тарихына күпме төгәллекләр кертүе бүген барыбызга да билгеле. Коммунистлар фиркасе хакимлек иткән елларда Г. Тукайның өлкәнрәк чордашы Г. Исхакыйга багышлап «Кем ул?», «Мөхәрриргә», «Даһигә» исемле шигырьләр язган булуын, аны милләт өчен көрәшче итеп зурлавын әйтү мөмкин булмаган эш иде. «Кем ул?» шигыре, гомумән, күптомлыкларына кертелмәде дә. «Мөхәрриргә» исемле шигыренең Г. Исхакыйга атап язылганы турында мәгълүмат бирмәү дә шул ук сәясәтнең нәтиҗәсе. Бу соңгысы уңаеннан Әмирхан ага Еники болай дип язган иде: «Гаҗәеп шигырь! Нинди тирән хөрмәт һәм өмет булган Тукайда Гаяз Исхакыйга карата!.. Хәзер инде бу исбат ителгән бәхәссез хакыйкать» (Казан утлары. 1992. № 4. Б. 156). Әлеге әсәрдә Г. Тукай милләтебезнең бәхете өчен көрәшчене бирегә – туган халкы янына чакыра: «Кайт әле монда ватанга, кайт әле саргайтмәле!» дип эндәшә. «Даһигә» әсәренең кемгә багышланганын әйтү дә ул унъеллыкларда искиткеч каты җинаять буларак бәяләнер иде. Чөнки нәкъ менә Гаяз Исхакыйны шагыйребез «Даһи» дип атый.

Бу бөек замандашын, идеалына бәрабәр утын яктырту өчен, «чын сөбатлә (ныклык белән. – *Ф.Г.*) алга барды, бакмый уңга-сулга» дип бәяли. Әмма ул ут артта түгел, бары тик алда гына, шуның өчен:

Артка бакма, даһием, идеал һаман
да алда ул;
Алга барганнарга тик табыла
табылса – Алла ул, –

дигән теләген җиткерә. Димәк, Г. Тукай Г. Исхакыйның максатларын ихлас бүлешә, аны «мәңге төн» булган дөньяны нурландыру бурычын изге итеп санаган фикер иясе һәм каһарман итеп саный.

Әйтик, җитмешенче-сиксәненче елларда дөнья күргән очракта энциклопедия шул ук Г. Исхакыйның Г. Тукайны «җәмәгатьче шагыйрь», «динле, чын татар угълы татар», «Һәр үткән көн Тукайны зур итәчәк, үстерәчәк», «Тукай яңа мәдәни-милли тормышыбызның иң зур нигезе» дигән бәяләреннән башка гына укучыга барып җитәр иде. Хәзер, егерме беренче гасырның икенче унъеллыгы урталарында, без болар турында ничек булса, шулай яза һәм әйтә алабыз. Шуңа күрә бу олы хезмәтне Г. Тукай турында хакыйкать тупланган хәзинә дип бәяли алабыз.

Үз заманында Тукай даирәсендә булган, аның шәхесенә һәм иҗатына мөнәсәбәтле затлар турындагы мәгълүматлар, биредә аларның фоторәсемнәре белән бирелә. Шактый бай иллюстрацияләр урнаштырылу да әлеге китапны баета, мәгълүмат бирү ягыннан бик әһәмиятле бурыч үти, алар тәкъдим ителгән мәкаләләргә, сәхифәләргә күрсәтмәле өстәмә булып тора. Аларны барлауга, туплауга шулай ук зур хезмәт куелган. Китапханәләрдә, архивларда, аерым кешеләрнең кулларында гына булган сирәк китапларның тышлык рәсемнәре бирелү дә укучыга күп нәрсәләрне күз алдына китерергә ярдәм итә. Әле кырыгынчы елларда чит ил матбугатында Г. Тукайны «бөек шагыйрь һәм философ», «зур әдип» дип язып чыккан Гали Акыш, безнең көннәрдә Җаекта Г. Тукайның истәлеген саклау, шәхесенә игътибар туплау мәсьәләләрен хәл итүгә күп көч куйган Рәззак Әбүзәров, бу юнәлешләрдә төрле җирлекләрдә хезмәт куйган башка күп кенә затларыбызны танытуга да әлеге томда зур әһәмият бирелгән. Тукайның нәсел-нәсәбе дә шактый тулы тәкъдим ителә. Әнисенең энесе Кәшфелкәбирнең фотосурәте, ятимне тәрбиягә алган Сәгъди абзый белән кечкенә Габдулланың рәссам Л. Фәттахов ясаган рәсеме урнаштырылу, сүз дә юк, хуплана торган гамәлләр. Аларны байтак санарга мөмкин.

Шулай да нәкъ менә шушы җәһәттән кайбер җитешсезлекләр дә бар. Г. Тукай иҗатын татар, рус, дөнья укучыларына ирештергән, аның шәхесенә һәм иҗатына зур бәя биргән китаплар, монографияләр, картиналар язган күренекле шәхесләрнең фотосурәтләренә йөз елларга бер чыгарыла торган әлеге энциклопедиядә урын табылмавы күңелне борчый. Әйтик, шагыйрьне Сембер губернасына кунакка чакырып хөрмәт иткән Хәсән

Акчурин, талантлы эшләнгән картиналар иҗат иткән Байназар Әлминов, Г. Тукай белән Петербургта нык аралашкан, аны башкаладан җылы караш белән озатуда турыдан-туры катнашкан Кәбир Бәкер, атаклы «Кечкенә Тукай» картинасын язган Хаҗиморат Казаков, «Тукайның шигъри осталыгы» китабы авторы Әхмәт Исхак, «Үлемсез Тукай» дип язган Мостай Кәрим, дистәләрчә шигырьләрен рус теленә уңышлы тәрҗемә иткән Рувим Моран (16 шигырен рус укучысына тәкъдим иткән Павел Радимовныкы бар бит), шагыйрьнең рус әдәбияты белән бәйләнешләрен күрсәтеп хезмәтләр язган Рөстәм Башкуров, Иван Пехтелев, шагыйрь белән шәхсән очрашкан һәм аралашкан Хуҗа Бәдигый һәм башкаларның рәсемнәре булу китапны тагын да баетыр иде.

Шулай да портретлары бирелмәгән шәхесләр арасыннан Рашат Гайнанов турында аерым әйтәсе килә. Ул Тукай әсәрләрен текстология җәһәтеннән өйрәнүгә зур өлеш кертте. Шагыйрьнең дүртомлык һәм биштомлыкларын төзегәндә (бигрәк тә соңгысын) нәкъ менә ул Г. Тукайга мөнәсәбәтле бихисап мәгълүмат туплады. Әгәр 1975–77 елларда басылган дүрттомлык ун елдан биш том булып чыккан икән, бу – әлеге фидакаребез табышлары нәтиҗәсе. Кулыбыздагы энциклопедиядәге күп кенә мәгълүматларның нигезендә дә ул кулланылышка керткән фактлар да ята. Моның шулай икәнлеген раслау бер дә мәшәкать тудырмый. «Билгесезлектән – яңа томга» дигән мәкаләсендә Р. Гайнанов бу хакта үзе дә язган иде (Совет Татарстаны. 1976. 20 май).

Мондый зур хезмәт җитешсезлекләрсез булмый да торгандыр. Алга таба алып барылачак тикшеренүләрдә алар төзәтелер, төгәлсезлекләр бетерелер. Иң мөһиме – Тукаебыз турында шактый тулы мәгълүматлы хезмәт барлыкка килүе, шагыйребезнең яңа заман укучысына тагын да аңлаешлырак булып әверелүе. Шушы хезмәтне тудыруга өлеш керткән замандашларыбызның һәммәсенә Тукаебызның рухы рәхмәтле булгандыр дип уйларга кирәк. Татарның чын мәгънәдә бәхетле булуын күрергә теләгән, шул юлда ялкынланып янып бик яшьли бакыйлыкка күчкән Тукаебыз рухын шушы юнәлештәге эшләребез белән алга таба да сөендереп яшәргә насыйп булсын.

***Фоат Галимуллин,***
*Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры*

# МУСА АКЪЕГЕТЗАДӘ ҺӘМ ЙОСЫФ АКЧУРА ХЕЗМӘТЛӘРЕНЕҢ ТӨРЕКЧӘ ЯҢА БАСМАЛАРЫ

**1. Musa Akyiğitzade. İlm-i Servet Veyahud İlm-i İktisat. Haz. G. Coşkun Albayrak, H. Genç, S. Çağrı Kocakaplan. İstanbul, Dergah yayın. 2016.**
**2. Yusuf Akçura. Sürgünden İstanbul'a. Darülhilafet Mektupları. Haz. İ. Türkoğlu. İstanbul, Ötüken, 2016.**
**3.Yusuf Akçura. Suriye ve Filistin Mektupları. Haz. İ. Türkoğlu. İstanbul, Ötüken, 2016.**

Төркия тарихында әһәмиятле эз калдырган Казан татар халкының күренекле вәкилләре хакында төрек телендә чыккан яңа язмаларны даими рәвештә күзәтеп барырга тырышам. Шул уңайдан татар җәмәгатьчелегенә узган 2016 елда төрекчә басылган өч кыйммәтле хезмәт турында хәбәр итүне кирәк санадым, чөнки болар – Төркиядә яшәп, шунда вафат булган ике зур шәхесебез Муса Акъегетзадә (1865–1923) һәм Йосыф Акчураның (1876–1935) бүгенге хәрефләр белән татарча яки русча басылып чыкмаган әсәрләре.

Беренче китапта Муса Акъегетзадәнең икътисад гыйлеме буенча язылган ике фәнни хезмәте урын алган. Үзе «милли роман яки хикәя» дип атаган «Хисаметдин менла» (1887) әсәре белән татар әдәбияты тарихында повесть жанрының беренче үрнәген язып калдырган әдип Муса Акъегетзадәне, ни гаҗәп, Төркиядә госманлы икътисад белеменә нигез салган хезмәтләр авторы буларак беләләр. Тумышы белән Пенза өязе Чембар (Белинск) шәһәреннән булган Муса әфәнде, рус гимназиясен тәмамлаганнан соң, Казан университетына кереп карый, ләкин, гайре-рус халыкларга ул вакытта югары уку йортларына юл ябык булганлыктан, уңышка ирешә алмый. Белем алу теләге белән ул 1888 елда Төркиягә китә һәм Истанбулда дәүләт хезмәткәрләрен әзерли торган Мөлкия югары мәктәбендә укый. 1891 елда бик яхшы билгеләренә генә укуын тәмамлагач, укытучылык хезмәтенә керешә, Хәрбия мәктәбендә чит тел (рус теле) укытучысы буларак хезмәт юлын башлап җибәрә. 1892 елдан аңа тагын бер өстәмә эш – Истанбулдагы Галата таможнясына килгән китапларны инспекцияләү вазифасы йөкләнә. 1896 елда ул «*Икьтисад яхуд гыйльме сәрвәт: азадеги тиҗарәт вә ысуле химая*» (*Икьтисад яки капитал гыйлеме: ирекле сәүдә һәм химая ысулы*)[1], 1897 елда *«Аурупа мәдәниятенең әсасына бер назар» (Аурупа мәдәнияте нигезләренә бер караш)*[2], 1899 елда «*Гыйльме сәрвәт вә яхуд гыйльме икьтисад: кавагыйде мөһиммә-и икътисадийәйи хави» (Капитал гыйлеме яки икьтисад гыйлеме: икьтисадның мөһим эчке кагыйдәләре*) исемле хезмәтләрен бастыра. Соңгы китабы өчен дүртенче дәрәҗәдәге солтан нишанына (медаленә) лаек була.

Муса әфәнденең икътисад фәне белән бәйле госманлыча язылган бу хезмәтләре бүгенге көнгә кадәр төрек теленә күчерелми торган иде, менә, ниһаять, Гөкчән Чошкун Албайрак, Хәмди Гәнч, Саим Чагры Кожакаплан тарафыннан әзерләнеп, «Дәргяһ» нәшриятында «Госманлының заманча икътисады эзеннән» исемле сериянең икенче китабы буларак басылып чыкты. Дулкынланып кулыма алган китапны ачу белән бераз уфтанып куйдым, чөнки М. Акъегетзадәнең хезмәте госманлы теленнән хәзерге төрек теленә тулы дәрәҗәдә тәрҗемә ителмәгән, а бары тик гарәп графикасыннан латин әлифбасына күчерелгән генә булып чыкты. Китап башында бирелгән матур гына кереш сүз һәм аңлатма язуы бер кадәр күңелне күтәрсә дә, сүз дә юк, гади төрек укучысына бу китапны үзләштерү бер дә ансат булмаячак, чөнки гарәп-фарсыдан кергән сүзләр һәм грамматик формалар, бүгенге халыкара икътисади терминнардан ерак торган «иске» атамалар – барысы да текстны җайлы гына укып аңларга мөмкинлек бирми. Кызганыч, бүгенге төрек фәнендә госманлыча текстларны шушылай сүзлекчәсез, тәрҗемәсез латин хәрефләре белән нәшер итү – киң таралган күренеш.

Китапның баш өлешендә Муса Акъегетзадәнең архивта саклана торган «сиҗил вәракасы»[3] бирелгән. Архивта саклanучы бу әһәмиятле документ та госманлы теленнән транскрипция булып, анда Муса әфәнденең Төркиядә нинди рәсми урыннарда эшләве һәм күпме хезмәт хакы алуы турында хәбәрләр бар. Мәсәлән, аның Истанбулда гына түгел, Госманлы империясенең Ван, Айдын, Хомус кебек төрле шәһәр һәм өлкәләрендә дәүләт чиновнигы каймакам (район/поселок башлыгы) булып эшләве минем өчен бер яңалык булды. 1908 елның августыннан башлап, Муса әфәнде «Мәтин» исемле көндәлек сәяси һәм гыйльми газета чыгара башлый, тик ул 1910 елда, «Иттихад вә тәраккый» партиясе белән фикер аерымлыклары булу сәбәпле, ябыла. Китапта ул газетаның бер санынннан һәм госманлыча басылган әлеге хезмәтләрнең тышлык битләре дә бирелгән.

*«Гыйльме сәрвәт вә яхуд гыйльме икътисад»* китабы шул заманда Госманлы империясендә икътисад буенча чыккан башка хезмәтләрдән берникадәр аерылып тора. Әйтик, бу китапта Муса әфәнде дөнья икътисад белемендә билгеле булган төрле агымнарны, методларны анализлый, икътисад фәненең теоретик нигезләрен барлый, кыйммәтле чыганакларын күрсәтә, китапка кушымта өлешендә шул дәвердәге акча берәмлекләренең төрек корышына (куруш) карата курсын бирә. Муса әфәнде Көнчыгыш һәм Көнбатышның атаклы икътисадчыларының идеяләрен пассив рәвештә генә үзләштермәгән, ә бәлки аларны госманлы җирлегенә яраклаштыру максатында үз хезмәтендә кулланган. Кереш сүз авторлары билгертүенчә, Госманлы Төркиясендә Манчестер икътисад доктринасын практикага кертүнең

илдәге икътисади вазгыятькә зарар бирүен иң беренчеләрдән булып нәкъ менә Муса Акъегетзадә искәрткән. Мөлкия мәктәбендә бирелгән белемнәрнең Көнбатыш гыйлеменә карата тәнкыйди караш формалаштырырлык дәрәҗәдә киң булмавын искә алып, төрек галимнәре Муса әфәнденең икътисад өлкәсендәге фикерләренең тирәнлеген һәм күпкырлылыгын аның русча чыганаклардан иркен файдалануы белән бәйләп аңлаталар. Төрек икътисадчылары исә ул вакытта бу мөмкинлектән мәхрүм иделәр.

Цивилизацияләрнең үсешенә сәнгатьме, фәнме ныграк тәэсир итә, дигән сорауга Муса Акъегетзадә «фән» дип җавап бирә һәм үз фикерен Имам Газали, Бэкон, Ибне Батута әсәрләренә таянып дәлилли. Икътисад буенча язган ике хезмәтендә дә Муса әфәнде милли керемне арттыру өчен кайсы юл яхшырак: икътисади тормышны үз агымына куяргамы, әллә аңа ярдәм (химая) итәргәме, дигән проблемага туктала. Ике юлның да үзенчәлекләрен җентекле итеп анализлаганнан соң, Госманлы империясендә аеруча популярлык казанган иреклe сәүдә идеясен тәнкыйди күзлектән кичерә һәм ирекле базар шартларында икьтисадны үстерү процессында аерым секторларга химаячелек итүнең әһәмиятенә басым ясый.

Авыл хуҗалыгы һәм сәнәгатьнең икътисади тормыштагы роленә махсус бүлек багышлаган галим бу ике өлкәнең тигез дәрәҗәдә үсүе мөһим икәнен әйтә, җитештерелгән товарларның импорты һәм экспорты турында үз фикерләрен китерә, авыл хуҗалыгына, аеруча игенчелеккә генә таянган икьтисадның кимчелекле булуын дәлилли һәм мондый берьяклылыктан котылу юлларын күрсәтә.

Бүгенге көн төрек икьтисадчылары югары бәяләгән Муса Акъегетзадәнең бу китаплары мөселман икътисады белән кызыксынучылар өчен әһәмиятле чыганак булып хезмәт итәр дип өметләнергә кирәк.

Шулай ук узган ел Йосыф Акчураның мәкалә-очерклар циклыннан ике китабы басылып чыкты. Профессор Исмаил Төрекоглу Й. Акчураның 1908–1913 елларда татар вакытлы матбугатында чыккан язмаларын туплап, төрек теленә тәрҗемә итте. Исмаил бәй кыска гына язган кереш сүзендә Акчураның Төркиядә җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәвен искәртә. Бу фикерне яңа гына чыккан башка бер фәнни мәкалә дә исбатлый: Ниязи Бәркәс исемле күренекле галим Акчураны «Онытылган кеше» дип атый һәм бу «онытылу»ның сәбәпләрен Төркия Җөмһүриятендәге тарихи, сәяси вакыйгалар, туранчылык, милләтчелек, госманчылык кебек идеологик агымнар белән бәйләп аңлата[4].

Беренче китапка Акчураның Дар әл-хәлифәттән, ягъни барлык мөселманнарның хәлифе – төрек солтаны яшәгән өлкәдән, Госманлы империясеннән торып язган һәм «Тәрҗеман», «Вакыт» газеталарында, «Шура» журналында 1908–1912 елларда басылган очерклары кергән. Язмаларның кайберләре «Сафәс» псевдонимы белән, кайберләре

үз исеме белән, кайберләре исә «ЙА» инициалы белән чыккан. Аларда, нигездә, Россия, Төркия, Англия, Македония, Германия, Испания һәм Европаның башка өлкәләрендәге сәяси халәт анализлана, төрек, рус һәм татар халыкларының тормыш-көнкүреше турында авторның күзәтүләре бирелә. Күп кенә мәкаләләрнең (бигрәк тә «Истанбул мәктүпләре» исеме астында чыкканнарының) «Вакыт» газетасы баш мөхәррире Фатих Кәрими кушуы яки соравы буенча язылганлыгы күренә. 1909 елның язында мәйданга килгән һәм төрек тарихында «31 март вакыйгасы» дип йөртелә торган гаскәри-дини фетнә вакытында Йосыф Акчура Истанбулда була һәм андагы хәлләрне үз күзләре белән күрә, төрле халык вәкилләренең бу вакыйгаларга мөнәсәбәтен һәм үз кичерешләрен бер циклда тасвир итә.

1911–1912 елларда төрек-итальян сугышы хакында да Йосыф Акчурадан татар укучыларына үз заманы өчен кызыклы гына фикерләр җиткерелә. Истанбул урамнарында йөргән вакытта «эх, шушында бер татар рестораны булса, үзебезчә бер утырып ашар идек» дип хыялланган Йосыф әфәнде, төрек башкаласын яһүди һәм гайремөслим Европа сәүдәгәрләренең басып китүенә уфтана, шул уңайдан сәүдә эшендә җитез һәм актив Касыйм татарларын Истанбулга килеп эшмәкәрлек итәргә, мөселман ризыклары пешерә торган ашханәләр ачарга чакыра.

1913 елда исә Йосыф Акчура Сүриягә һәм Филистингә сәяхәт итә, хәтта шул арада Хиҗазга барып, хаҗ да кылып кайта. Бу сәяхәттә күргәннәрен дә ул Оренбургка «Вакыт» газетасына язып бара. Исмаил Төрекоглу әзерләп бастырган икенче китап әлеге сәфәрдән язылган хатлардан гыйбарәт, аңа Сүрия белән Филистиннең икесеннән дә унберәр, Иерусалимнан исә сигез хат, җәмгысы утыз очерк кергән. Боларда Й. Акчура борынгы цивилизация җирләре булган Сүрия һәм Филистиннең тарихына кагыла. Дөнья диннәренең барчасы да диярлек бу туфракларда туган, иудаизм, христиан һәм ислам диннәре монда үскән, агач боталары кебек тармакланып киткән, ди автор. Ул вакытларда әле Госманлы империясе территориясендә булган Сүрия һәм Филистин гарәпләре, Балкан илләренең төрек хакимлегенә каршы баш күтәреп, мөстәкыйльлек яулап алуыннан соң, сәяси хәрәкәтләрен көчәйттеләр һәм инде төрек солтанына буйсынырга теләмиләр, ди.

Бәйрүт шәһәрен гизеп йөргән вакытта Акчура чит ил (америкАн, инглиз, француз, алман) христиан-миссионер мәктәпләренең гаять күплегенә игътибар итә, сүриялеләрнең акча-байлыкны бик яратуын күрә, килгән кунакларны төрлечә алдау-талау белән мавыгуларын хәтта үз тәҗрибәсендә дә сыный.

Зур тиражлы төрек газеталарының Сүриядә ник бер мөхбире булсын, дип уфтана автор, ә бит тиздән империя каршында гарәп проблемасы бөтен авырлыгы белән килеп басачак, димәк, Македония һәм Албания вакыйгалары төрекләргә бер сабак та

бирмәгән икән, дип тәнкыйть сүзләрен җиткерә. Бәйрүтнең зур газетачылары белән күрешеп, Сүриядәге реформа темасына сөйләшә.

Иерусалим манзаралары, рус христан хаҗиларының бу шәһәрдә үз-үзләрен тотышлары, изге урыннар һ.б. турында язганнарын укыганда, Акчураның җор теллелеген дә сиземләми мөмкин түгел. Мәсәлән, төрле скандалларны яратучы газета мөхәбирләрен ул микробларга охшата: кайда авыру булса, шунда тупланалар, үрчиләр, ди. Икенче бер урында исә, мин ике хайваннан гел чирканам, ди: берсе – черкиләр, икенчесе – рәһбәрләр (экскурсоводлар), дип, гарәп илләрендә тарихи урыннарны карарга килгән чит ил кешеләренә юл күрсәтүче булырга теләгән бәйләнчек «һәвәскәр гид»ларны тәнкыйть итә.

Пасха бәйрәме өчен Көдүскә килгән Йосыф Акчура, һич уйламаганда, бер мөселман бәйрәменә туры килә: «Нәби Муса бәйрәме». Бу бәйрәм бары тик шушы мохиткә генә хас, бары Иерусалим шәһәре чикләрендә үткәрелә торган дини чара булып, җомга намазыннан соң Муса пәйгамбәрнең каберен зиярәт итү белән башланып китә икән.

Ике китап булып басылып чыккан әлеге язмаларда тагын күп кенә кызыклы темалар күтәрелә, тарихи вакыйгалар сурәтләнә, болар барысы да Йосыф Акчураның шәхсиятен, кешелек дөньясын, дини, милли, сәяси карашларын тулырак аңларга ярдәм итәчәгендә шигем юк. Төрек укучысына Йосыф Акчура, Ризаэддин Фәхретдин, Муса Акъегетзадә, Габдерәшит Ибраһимов кебек татарның олуг затларын таныта, яраттыра торган хезмәтләр иҗат итүче Исмаил Төрекоглуга исә рәхмәт хисләремне җиткерәм һәм бу өлкәдә яңадан-яңа уңышлары белән безне сөендерүен телим.

## Искәрмәләр

[1] Сәрвәт – капитал; азагеди – ирекле; тиҗарәт – сәүдә; химая – опека, ярдәм.

[2] Бу хезмәт, Сәлчук Уйсал тарафыннан гадиләштерелеп, 1996 елда «Аурупа мәдәниятенә бер назар» исеме белән Анкарада басылып чыккан иде.

[3] Сиҗил вәракасы – шәхес турында рәсми белешмә, русча әйткәндә, «личное дело».

[4] Çalen, Mehmet Kaan. Niyazi Berkes'e Göre Yusuf Akçura Niçin Unutuldu? // Tarih Okulu Dergisi (TOD) Journal of History School (JOHS) Aralık 2016 December 2016 Yıl 9, Sayı XXVIII, ss. 327–346.

***Сибгатуллина Әлфинә Таһир кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.*
*alfina2003@yandex.ru*

## ГАЙНЕТДИНОВ АЙДАР.
## АРЧА РАЙОНЫ ЭПИГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Күптән түгел яшь галим Айдар Гайнетдиновның «Арча районы эпиграфик истәлекләре» исемле хезмәте дөнья күрде. Ул татар төбәк тарихын, тарихи-мәдәни мирасыбызны өйрәнүче галимнәргә, мөгаллимнәргә, аспирантларга, гомумән, татар халкы тарихы белән кызыксынучы укучыларга тәкъдим ителгән. Бабаларыбыздан калган рухи хәзинәне туплаган әлеге хезмәт татар эпиграфика фәнендә лаеклы бәясен алыр дип ышанабыз.

Гарәп графикасында язылган борынгы кабер ташлары бихисап күп. Шуларны истә тотып, ТР Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты аларны җентекләп өйрәнү эшенә керешкән. Арча районы Татарстан Республикасының иң атаклы һәм данлыклы төбәге булып санала, чөнки аннан күп кенә мәгърифәтчеләребез, әдипләребез чыккан. Эпиграфик истәлекләрне барлау һәм ачыклау эшен нәкъ менә шул төбәктән башлаулары гаҗәп түгел. Нәтиҗәдә, А.М. Гайнетдиновның «Арча районы эпиграфик истәлекләре» китабы районны тагын да үзенең күп сандагы эпиграфик истәлекләре белән танытты.

Китапта Татарстан Республикасының Арча районы территориясендә хәзерге көнгә хәтле сакланып калган гарәп язулы татар эпиграфик истәлекләренең тулы текстлары, аларның хәзерге телгә күчермәләре китерелгән. Хезмәттә урта гасырлардан алып 1939 елга хәтле куелган гарәп язулы 1300гә якын кабер ташы исәпкә алынган. Бу, әлбәттә, бер район өчен бик зур сан, чөнки Татарстанның башка районнарында (мәсәлән, Әлмәт, Әгерҗе, Кукмара, Мамадыш төбәкләрендә) 4–5 мәртәбә кимрәк ташбилге табылганы билгеле. Арча районының Яңа Кенәр авылында гына да барлыгы 154 ташъязма истәлек өйрәнелгән.

Археологлар татар эпиграфик истәлекләрне ачыклап, бик күп хезмәтләр язганнар һәм язалар, ләкин кайберләрендә ташлардагы даталар төгәл укылмаган, хаталы очраклар еш очрый. А.М. Гайнетдиновның «Арча районы эпиграфик истәлекләре» китабында шундый аерым фактларга игътибар ителеп, Казан ханлыгы чорына караган кабер ташларының кайчан һәм кемнәргә куелганлыгы күрсәтелә һәм аларның күбесе автор тарафыннан беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертелә. Шулай ук 16 ташны язу остасы ачыкланган һәм таш чыгару карьерларының урыннары да табылган. Бу да фән өчен бик мөһим.

А. Гайнетдинов тарафыннан кабер ташлары текстларын тасвирлау ысулы да дөрес дип әйтергә мөмкин. Автор искәрткәнчә, моңарчы эпиграфистлар арасында гарәп җөмләләрендәге саф гарәп сүзләрен татарчага якынлаштырып, төрлечә язу өстенлек алса, биредә аларны тәҗвид кагыйдәләренә туры китерелгән формада бирү бик отышлы булган. Чыннан да, гарәп

теленең фонетикасын бозмас өчен болай эшләү дөресрәк. Ташбилге текстларының хәзерге татар телендә бирелүе, шактый күп очраган гарәп-фарсы телендәге җөмләләр һәм сүзләрнең татар теленә тәрҗемә ителүе дә бик мөһим. Болай эшләү китапны укучылар аудиториясен киңәйтә. Шул ук вакытта белгечләр өчен ташъязманың транскрипциясе дә китерелгән һәм теләгән кеше оригинал текстларның ни рәвешле язылганнарын карый ала. Китапта кайбер «кабер ияләре» хакында кыскача мәгълүмат бирелүе һәм фәнгә билгеле булган шәҗәрәләр күрсәтелү дә хезмәтнең фәнни дәрәҗәсен күтәрә. Китапта атаклы шәхесләр, изгеләр, дин әһелләре, мөгаллимнәр, иганәчеләр һ.б.га куелган кабер ташлары хакында да мәгълүмат табарга мөмкин. Мисал өчен, Ш. Мәрҗанинең газиз ата-анасы, әби-бабасы, башка туганнары истәлегенә куелган ташбилгеләрне атап узарга мөмкин. Мәрҗанинең ата-анасы, әби-бабасының вафат булуына инде күп вакытлар узса да, эпиграфист галимнәр тарафыннан аларның ташбилгеләре, ни өчендер, өйрәнелмәгән. Тагын берничә елдан әлеге кыйммәтле тарихи чыганакларга җимерелеп юкка чыгу куркынычы яный һәм аларны саклап калу, югалтмау көнүзәк мәсьәләләрнең берсе булып торырга тиеш тә. Шунысы куандыра: яшь эпиграфист Гайнетдинов хезмәтендә, беренче мәртәбә буларак, бу ташъязма текстларының тулы укылышы тәкъдим ителгән.

«Арча районы эпиграфик истәлекләре» китабында һәр тасвирланган ташның фотосурәте бирелгән булса, хезмәтне тагы да баерак итәр иде, ләкин бу аңлашыла – һәрберсенекен тәкъдим итү хезмәтне бастырып чыгаруда зур чыгымнар таләп итә.

Бүгенге көнгә хәтле сакланган барлык ташъязма истәлекләрне кулдан килгәнчә саклап калырга тырышырга кирәк һәм бу юлда авторга уңышлар теләп калабыз.

***Сайрус Хәмидуллин,***
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*фәнни хезмәткәре*

**2017 елның 13 гыйнварында** «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы «Манеж» күргәзмәләр залында мәшһүр шагыйребез Г. Тукайның 130 еллыгына багышланган, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы һәм ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының уртак проекты – **«Тукайга сәяхәт» күргәзмәсе каталогын тәкъдим итү булды.** Күргәзмә шушы ук залда 2016 елның 24 октябреннән 2017 елның 22 гыйнварына кадәр эшләде.

Каталогны әзерләүдә, Казан һәм Санкт-Петербург күргәзмәләрен оештыруда катнашкан авторлар коллективлары: ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Россия дәүләт тарихи архивы (СПб), Россия Милли китапханәсе (СПб), Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге Фәнни китапханәсе, КФУның Н.И. Лобачевский исем. Фәнни китапханәсе кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, ТР Фәнни музее, ТР Милли архивы, ТР Милли китапханәсе.

Каталогның нигезен ТР ФАнең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгендәге шагыйрь белән бәйле гаять бай материал тәшкил итә. Алар: фотографияләр, хатларның автографлары һәм шигырьләрнең кульязмалары, әдип әсәрләренә беренче иллюстрацияләрне эшләгән Г.В. Арсланов рәсемнәре. Г. Тукайның үзе исән чагында дөнья күргән китаплары РФАнең Казан фәнни үзәге Фәнни китапханәсе фондыннан тәкъдим ителә (алар XX гасыр дәвамында Г. Ибраһимов исем ТӘҺСИ хезмәткәрләре көче белән туплана). «Документлар» бүлегендәге ТР МА фондында саклануччы гаять мөһим материаллар янәшәсендә Г. Тукайның китабына һәм аның А.А. Ахматова тарафыннан русчага тәрҗемә ителгән (басмаханәләрдә бик үк дөрес редакцияләнмәгән) 11 шигыренә җинаять эше кузгатылу хакындагы Россия дәүләт тарихи архивында (СПб) сакланган материал да урын ала. «Иллюстрацияләр» бүлегендә, Г.В. Арсланов рәсемнәре белән бергәттән, Г. Тукайның «Мәҗмугаи асаре» дип исемләнгән җыентыгы буенча Б.Э. монограммасы астына яшеренгән рәссамның 1914 елда эшләнгән иллюстрацияләренең оригиналлары да бирелә. Алар татар китаби иллюстратив графикасы үсә башлауны чагылдыралар. Каталог мәшһүр татар шагыйренең әдәби мирасын фәнни өйрәнүнең һәм аны киң җәмәгатьчелеккә җиткерүнең яңа һәм кызыклы этабын тәшкил итә.

**2017 елның 23–25 гыйнварында Казан (Идел буе) федераль университетының Лев Толстой исем. филология һәм мәдәниятара багланышлар институты «Литературоведение и эстетика в XXI веке (“Татьянин день”)» дигән темага Ундүртенче Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция уздырды.** Казан (Идел буе) федераль университеты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән бергәләп, мондый конференцияләрне ел саен оештыра. Быелгы конференция көннәрендә «Сопоставительная филология на современном этапе» темасы буенча түгәрәк өстәл артында сөйләшү булды. Анда катнашкан галимнәр, язучылар һәм мәдәният эшлеклеләре компаративистиканың актуаль бурычлары: терминология белән бәйле нәзари проблемалар, аның чорларга бүленеше, әдәбиятны чагыштырма планда өйрәнү методларын ачыклау, шулай ук әдәбиятара

процессларда әсәрләрне аңлау һәм интерпретацияләү үзенчәлекләре һәм әдәби әсәрләрне төрле телләргә тәрҗемә итү мәсьәләләре турында сөйләштеләр. Түгәрәк өстәл утырышында профессор, филология фәннәре докторы А.М. Сәяпова, доцент, филология фәннәре докторы В.Р. Әминева, доцент, филол. фән. кандидаты М.И. Ибраһимов, профессор, педаг. фән. докторы А.Ф. Галимуллина, ТР дәүләт Сынлы сәнгать музее каршындагы «Златоуст» әдәби берләшмәсе җитәкчесе, шагыйрь һәм тәрҗемәче, ТР Язучылар берлеге әгъзасы В.П. Хәмидуллина һ.б. үз фикерләре белән уртаклаштылар.

**2017 елның 7 февралендә ТР Фәннәр академиясенең Зур залында тантаналы шартларда Г. Тукай энциклопедиясе тәкъдим ителде.** Бу – Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан әзерләнгән, татар әдәбият белеме тарихында әле беренче персональ энциклопедия. Аны эшләп халыкка җиткерү проектына 1990 елларда ук нигез салынып, әдәбият галиме Нил Юзиев энциклопедиянең гомуми концепциясен һәм төзелешен эшләгән иде. Бу проектны тормышка ашыру буенча эш төркеме булдырылды һәм аның составына, нигездә, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре кертелде. 1996 елда (Н. Юзиев вафатыннан соң) басманы эшләү төркеменең җитәкчесе итеп З. Рәмиев билгеләнде. Энциклопедиягә Тукайның шәхесен һәм әдәби әсәрләрен колачлаган, аның иҗатының халык тормышы, татар сәнгатенең төрле өлкәләре белән бәйләнешен яктырткан 2358 мәкалә тупланган. Тукай феномены белән кызыксынучылар өчен алыштыргысыз фәнни чыганак буларак бәяләнүче бу басма татар гуманитар фәннәренең төрле юнәлешләре буенча гыйльми эшчәнлек алып баручы 135 авторның хезмәтен берләштерә.

Энциклопедияне тәкъдим итү тантанасында Татарстанның дәүләт эшлеклеләре, Милли музей, архивлар хезмәткәрләре, Россия төбәкләреннән килгән һәм республикабыз, шулай ук Казакъстан язучылары, рәссамнар, актерлар һәм музыкантлар катнашты.

**2017 елның 8 февралендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Фән көненә багышланган тантаналы җыелыш булды.** Анда ТР ФА Президиумы әгъзалары, Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге һәм ТР ФА академик институтлары фәнни хезмәткәрләре, югары уку йортлары ректорлары һәм фәнни җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты. Тантана шартларында фән өлкәсендә югары казанышлар яулаган галимнәргә – дәүләт бүләкләре, Татарстан фәне үсешенә лаеклы өлеш керткән яшь галимнәргә грантлар тапшырылды.

**2017 елның 13 гыйнвар – 12 февраль көннәрендә** Мәскәүнең А. Бахрушин исем. Дәүләт үзәк театр музеенда **«Афишаларда һәм плакатларда татар театры тарихы» («Истории татарского театра в афишах и плакатах») күргәзмәсе оештырылды.** Театр сәнгатенең бу төре белән кызыксынучы тамашачылар алдында Музей директоры Д. Радионов, ТР Премьер-министры урынбасары, Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының тулы вәкаләтле вәкиле Р. Әхмәтшин, «Мәскәү милләтләр йорты» җитәкчесе В. Тарасов, Г. Камал исем. Татар дәүләт академия театрының баш рәссамы

С. Скоморохов һ.б. чыгыш ясадылар. Күргәзмәнең кураторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире Р. Солтанова бу чара белән кызыксынучы мәскәүлеләргә татар театры тарихының афишаларда һәм плакатларда чагылышы хакында киңәйтелгән мәгълүмат бирде.

**2017 елның 15 февралендә герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 111 ел тулу белән бәйле шигъри митинг уздырылды.** Казан (Идел буе) федераль университетының Лев Толстой исем. Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студентлары һәм укытучылары Университетның ректорлар бакчасындагы М. Җәлил һәйкәленә чәчәкләр куйдылар һәм, бәйрәмне дәвам итеп, «Гомерем минем моңлы бер җыр иде…» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичәдә шагыйрьнең әсәрләрен укыдылар.

**24 мартта** галимнәр, профессорлар, филология фәннәре докторлары, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклеләре, Халыкара төрки академиянең хакыйкый әгъзалары **Нурмөхәммәт һәм Фәһимә Хисамовларның** 80 яшьлеге уңаеннан кичә уздырылды. Кичәне Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Мөгаллим улы Миңнуллин алып барды. Юбилярларны Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты Дания Заһидуллина котлады һәм ТР ФА Президентының Рәхмәт хатын, истәлекле бүләген тапшырды. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Халыклар дуслыгы йорты директоры Ирек Шәрипов Фәһимә Миргали кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Сәветы Рәисенең Рәхмәт хаты белән тәбрикләде. Мөхтәрәм галимнәребезне шулай ук ТФА Президенты киңәшчесе, академик Әхмәт Мазһаров, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Казан университетының Л. Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов, Татарстан китап нәшриятының әдәбият бүлеге мөдире, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Газинур Морат, «Мәдәни Җомга» газетасының баш мөхәррире, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Вахит Имамов, ТР Милли музее генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова, якташлары – Чүпрәле һәм Ютазы муниципаль районы вәкилләре котлады. Юбилей уңаеннан, Институт тарафыннан «Фәнгә багышланган гомер» дип аталган китап әзерләнде.

**30 мартта Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының яңа бинасында Татарстан Фәннәр академиясе Президиумының күчмә утырышы үткәрелде.** Әлеге утырышта Институт директоры Ким Миңнуллин «Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының татар халкының милли үзенчәлеген саклау юнәлешендәге проектлары», Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире Илһам Гомәров «Татар эпиграфика истәлекләре: өйрәнүнең торышы һәм киләчәге» дип аталган темаларга чыгыш ясады. Президиум утырышында шулай ук 2016–2017 уку елының икенче семестрына Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе стипендиатлары исемлеге расланды.

***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc. форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

— авторның фамилиясе, инициаллары

— мәкалә исеме

— аннотация (рус телендә)

— төп сүзләр (рус телендә)

— сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, әтисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата фән докторы яки фән кандидаты тарафыннан язылган рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12, 1 нче кат, 10 нчы бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Уңышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек итүебезгә өмет баглап,*
*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**
На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**
2017. № 1

Бизәлеш авторы – Э. Бәшәрова
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 31.03.2017.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,25. Тираж 500. Заказ

Журнал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20